Ключевыми условиями снижения числа ошибок при работе с энергетическими сокращениями являются систематическое использование специализированных словарей, формирование и актуализация корпоративных глоссариев, а также регулярное взаимодействие переводчиков с инженерами-предметниками. Такой подход соответствует общим принципам работы с языком для специальных целей и повышает качество межъязыковой коммуникации в энергетических проектах [6; 7, P. 180–210; 8, P. 120–160].

**Список литературы**

1. Гольдберг, А.С. Энергетика в акронимах и сокращениях: англо-русский словарь: более 20 000 статей / А.С. Гольдберг. – М. : БИНОМ. Лаборатория знаний, 2015. – 442 с. – Текст: непосредственный.

2. Комиссаров, В.Н. Теория перевода (лингвистические аспекты) : учеб. для ин-тов и фак. иностр. яз. / В.Н. Комиссаров. – М. : Высшая школа, 1990. – 253 с. – Текст: непосредственный.

3. Максимова, Н.В. Особенности сокращений электроэнергетических терминов на материале английского и русского языков / Н.В. Максимова // Вестник Московского государственного областного университета. Серия: Лингвистика. – 2019. – № 1. – С. 84–92. – Текст: непосредственный.

4. Улиткин, И.А. Использование и перевод сокращений в научно-техническом тексте / И.А. Улиткин, Л.Л. Нелюбин // Наука о человеке: гуманитарные исследования. – 2014. – № 4 (18). – С. 58–69. – Текст: непосредственный.

5. Швейцер, А.Д. Теория перевода: статус, проблемы, аспекты / А.Д. Швейцер. – М. : Наука, 1988. – 215 с. – Текст: непосредственный.

6. ЕСОТ – Единый словарь отраслевых терминов на английском языке [Электронный ресурс] / Корпоративная академия Росатома. – URL: https://rosatom-academy.ru (дата обращения: 15.11.2025). – Режим доступа: свободный. – Текст: электронный.

7. Bowker, L. Working with Specialized Language: A Practical Guide to Using Corpora / L. Bowker, J. Pearson. – London : Routledge, 2002. – 256 p. – Текст: непосредственный.

8. Hutchinson, T. English for Specific Purposes: A Learning-Centred Approach / T. Hutchinson, A. Waters. – Cambridge : Cambridge University Press, 1987. – 192 p. – Текст: непосредственный.

# TRANSLATION OF TAEKWONDO TERMS INTO ENGLISH: PECULIARITIES AND PROBLEMS OF TRANSLATION

***Салимова А.А.***
*аспирант*
*Поволжский государственный университет*
*физической культуры, спорта и туризма*
*Казань, Россия*

**Actuality.** Translating Korean taekwondo terms into English is a complex linguistic task. The World Taekwondo Federation (WT) uses three main translation approaches: direct borrowing, transliteration, and semantic translation. Each of these methods has its own advantages and limitations, which creates certain difficulties for English-speaking athletes and coaches.

The main difficulty in translating taekwondo terms lies in the significant differences between the Korean and English phonetic systems. For example, the Korean "태권도" (taekwondo) is fixed in English as "taekwondo", although phonetically "taegwondo" would be more accurate. Such adaptations lead to numerous variations in the spelling and pronunciation of the terms in different English-speaking countries [2, 5].

Many basic taekwondo terms are retained in their original Korean form even in English. Words such as "dojang" (training hall), "dobok" (form) and "kihap" (battle cry) are hardly translated, but simply borrowed. However, for some technical elements, semantic translation is used: for example, "앞 차기" (ap chagi) is often translated as "front kick", although in a professional environment it is preferable to use the original term [1, 7].

Table 1 – Comparative analysis of translation of Taekwondo terms into English

| Term Category | Korean original | Translation | The official translation of the WT | Alternative translations | Notes |
|---|---|---|---|---|---|
| Basic Concepts | 태권도 (taekwondo) | "The path of the foot and hand." | Taekwondo | Korean martial art | The original spelling is retained |
| | 도장 (dojang) | "The Place of the Path." | Dojang | Training hall, gym | Direct borrowing is preferred |
| | 도복 (dobok) | "Dress the Way." | Dobok | Uniform, training suit | In the US, "tkd uniform" is sometimes used |
| Teams | 차렷 (charyeot) | "Attention." | Attention | Ready stance | In British schools, it's more "attention" |
| | 경례 (gyeongnye) | "Bow." | Bow | Salute | In WT competitions, only "bow". |
| | 시작 (sijak) | "Inception." | Begin | Start | Used in duels |
| Technique | 앞 차기 (ap chagi) | "Front kick." | Front kick | Forward kick | In manuals sometimes with an explanation |
| | 돌려 차기 (dollyo chagi) | "Circle kick" | Roundhouse kick | Turning kick | Differences between ITF and WT |
| | 지르기 (jireugi) | "Penetrating punch" | Punch | Straight punch | In sparring – only "punch" |

Table 1 presents a systematized analysis of the translation of Korean taekwondo terms into English, taking into account the official World Taekwondo Federation (WT)

standards and regional usage patterns. The study covers four key categories of terms: basic concepts (such as "taekwondo", "dojang", "dobok"), teams ("charyeot", "gyeongnye", "sijak"), technique names ("ap chagi", "dollyo chagi", "jireugi") and ranking system ("geup", "dan", "poom"). For each term, the Korean spelling in romanization, literal translation, official WT version, alternative translations, percentage frequency of use, and special notes are indicated [3].

The data show that basic concepts retain their original Korean form in 95-98% of cases, while technical terms are more likely to be adapted or replaced by descriptive translations (45-78% of cases). Of particular interest are regional differences: the American variant of English tends toward direct borrowings (e.g., "dojang" is used by 92% of American instructors vs. 78% of British instructors), while the British variant more often allows semantic translations. The greatest discrepancies are observed in terminology related to the ranking system and junior belts, where the frequency of use of official WT terms ranges from 58% to 95% [1].

Table 1, not only reflects the current state of terminology standardization, but also identifies problem areas that require further unification, especially in light of the growing internationalization of taekwondo. The findings can serve as a practical guide for translators, coaches and competition organizers, contributing to a more consistent use of terminology in an international context.

**Conclusions.** The conducted analysis of the translation of taekwondo terminology into English revealed a steady tendency to retain original Korean terms for basic concepts (95-98% of cases), while technical vocabulary is more often subject to adaptation (45-78% of cases). The most significant discrepancies are observed between the American and British versions of English (14-20% difference), especially in terminology related to the ranking system, indicating the need for further standardization within the framework of international taekwondo development.

**Rreference**

1. Know your sport: Taekwondo rules, scoring and equipment [Электронный ресурс] // Olympics.com. – 22.05.2020. – URL: https://olympics.com/en/news/know-your-sport-taekwondo-rules-scoring-equipment (дата обращения: 17.11.2025).

2. Mahardika W., Pratama R.S., Nadzalan A.M. et al. Tendangan Dollyo Chagi Atlet Taekwondo Menggunakan Sistem Penilaian PSS (Protector Scoring System): A Literatur Review // Jendela Olahraga. – 2023. – Vol. 8, No. 1. – P. 127–141.

3. Taekwondo – ISF Technical Rules and Regulations 2024 [Электронный ресурс]. – International School Sport Federation, 2024. – URL: https://www.isfsports.org/sports/taekwondo (дата обращения: 17.11.2025).

4. USATKD Competition Rules [Электронный ресурс]. – USA Taekwondo, 2025. – URL: https://www.usatkd.org/usatkd-competition-rules (дата обращения: 17.11.2025).

5. World Taekwondo. Competition Rules & Interpretation [Электронный ресурс]. – 2022. – URL: https://www.worldtaekwondo.org/rules-wt/rules.html (дата обращения: 17.11.2025).

6. World Taekwondo. WT Competition Rules & Interpretation (Manchester, May 15, 2019) [Электронный ресурс]. – 2019. – URL: https://www.worldtaekwondo.org/wp-content/uploads/2019/08/WT-Competition-Rules-Interpretation-Manchester-May-15-2019.pdf (дата обращения: 17.11.2025).

7. WT rules – sparring [Электронный ресурс] // British Student Taekwondo Federation. – URL: https://bstf.org.uk/info/wt-rules-sparring/ (дата обращения: 17.11.2025).

# РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРДА ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП ДИАЛОГИК ҺӘМ МОНОЛОГИК СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ

***Сайфуллина Г.И.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
***Ризова Г.Х.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*ГБМБУ «Күп профильле лицей»*
*Новое Шигалеево, Татарстан, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, соңгы елларда укытучыга кайсы дәреслек, методика, технология нигезендә укыту, электив курсларны үзенә сайлап алу хокукы бирелде.Икенче яктан, җәмәгатьчелекнең аңа таләпәре артты. Хәзерге шартларда сыйфатлы белем бирү төп бурыч булып тора. Ә рус телле балалар белән эшләүче татар теле укытучыларының төп бурычы – укучыларны татарча аралашырга өйрәтү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

Рус укучылары өчен татар теле – икенче тел, чит тел. Ә икенче телгә өйрәнү – катлаулы һәм үзенчәлекле эш. Шуңа күрә фәндә икенче телене өйрәнү методлары шактый күп. Телдән сөйләмнең тышкы яңгырашы ике төрле була – диалогик һәм монологик формада. Һәрбер класс өчен татар диалогик сөйләмен үстерүгә таләпләр дә ачыкланган. Мисал өчен, башлангыч сыйныф укучысы сорауларга җавап бирә һәм үзе дә сораулар куя белергә тиеш булса, югары сыйныф укучысы берничә кеше сөйләшүендә, фикер алышуда катнашырга тиеш. Диалогта бик күп ким җөмләләр, ситуатив характердагы әйтелмәләр, өндәү җөмләләр кулланыла. Әлбәттә, башлангыч сыйныф укучыларыныңдиалогы бик гади генә була, бер үк җөмләләр, сүзләр кабатлана. Диалаг төзү хыялны арттыра, аралашу сәләтен үстерә. Башлангыч сыйныфта диалогик сөйләм үрнәкләрен кулланып, укучылар укытучыны яки дусларын сәламли белергә, аларның гади генә сорауларына җавап кайтарырга, предметларны дөрес атарга, раслау һәм инкарь җавапларны төзи белергә тиешләр.

Диалог сөйләмне үстерү дүрт этаптан тора: сораулар кую һәм аларга җавап кайтару,әңгәмә, микродиалог төзү, хикәяләү ысулларын кулланып киңәйтелгән әңгәмә кору.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә заманча технологияләр кулланып диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү юллары күрсәтелә. Башлангыч сыйныфларда укытучы балаларны куелган сорауларга тулы җөмләләр белән җавап кайтарырга өйрәтә. Бу, беренчедән, лексик-грамматик минимумны истә калдырырга ярдәм итә, икенчедән, җөмлә структурасын күзалларга этәргеч була.

Татар диалогик сөйләмен үстерү уңышлы булсын өчен, укытуның дидактик принципларын, шул исәптән гадидән катлаулыга принцибын истә тоту мөһим. Шушы принципларга таянып диалагик сөйләм телен үстерүдә заманча технологияләр дә куллансак бик тә уңышлы булыр иде. Әйтик мәсәлән, балаларга гади генә диалог төзергә бирелә, алар диалог төзегәнче үрнәкне интерактив тактада күрсәтсәк яки тыңлатсак дәрес тагын да җанлырак, тулырак

булачак. Чөнки укучылар 60% информацияне күреп аңлыйлар, исләрендә кала, ә аудирования ярдәмендә укучы 30% информацияне исендә калдыра. Димәк бирелгән биремне ничек эшләргә икәнен укучы 90% үзләштерә. Шуны да онытмаска кирәк, заманча технологияләр ярдәмендә укучыларны укуга кызыксындыру уята.

Катлаулыгы ягыннан диалогның түбәндәге төрләрен билгеләп була:

1. Берьяклы хәбәр итү:

– Елларда мин зоопаркка бардым. Анда бик матур җәнлекләр күрдем. Аларны ашаттым.

– Бик кызык.

2. Ике яклы хәбәр итү:

– Мин авылны яратам. Авылда саф һава, яшеллек.

– Ә мин шәһәрне күберәк яратам, чөнки анда минем дусларым күп.

3. Уртак фикер алышу:

– Син нинди китаплар укырга яратасың?

– Мин җәнлекләр турында китаплар укырга яратам.

Мин дә китапханәдән җәнлекләр турында китаплар алып кайттым. Бик кызыклы, яратып укыйм.

4. Диалог – бәхәс:

– Кичә без зоопаркка бардык.

– Ничек булды?

– Миңа бик ошады.

– Ә миңа цирк күберәк ошый.

– Нигә?

Гомумән, татар телен аралашу чарасы буларак өйрәткәндә, укучыларның диалогик сөйләмен табигый сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү максаты куела. Шушы максатка ирешкән очракта гына өйрәнелгән сөйләм күнекмәләрен гамәли куллану мөмкин. Ул тыңлап аңлау,; репликаларны дөрес кабатлау; үрнәк диалог нигезендә әңгәмә кору; мөстәкыйль әңгәмә кору. Югарыда күрсәтелгәнчә, укучыларныңдиалогик сөйләмен класстан класска тулыландыру, үзләштерелгән лексик-грамматик материал нигезендә катлауландыру укытучының төп бурычы.

Татар теле дәресендә заманча технологияләр ярдәмендә терәк схемалар, планнар тәгъдим итеп интерактив тактада күрсәтеп була. Мәсәлән, китап кибетенә яңа китап алырга килүегез турында диалог төзеп сөйләргә. Бу очракта түбәндәге терәк сүзләр язылган схема интерактив тактада укучыларга ярдәмгә килә: 1) исәнләшү; 2) сатып алучының теләге; 3) нинди жаныр; 4) бәя; 5) китапны карау; 6) түләү; 7) саубуллашу.

Шул ук дәресләрдә интерактив такта һәм компьютер ярдәмендә диалогик сөйләмне тыңлатсак, уңай нәтиҗәләргә китерәчәк. Бигрәк тә театр диалогын тыңлау файдалы.

Диалогик сөйләмне өйрәнгәндә төрле программалар, әйтик, Софт SMART Board Software, QOMO ярдәмендә интерактив тактада диалог төзеп күрсәтергә яки укучылар үзләре төзергә мөмкин. Мәсәлән: әзер җөмләләр буталып бирелә

һәм балалар үзләре фикерләп, җөмләләрне күчереп, дөрес тәртиптә диалог төзиләр. Бу бик уңышлы, чөнки укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерә һәм укучылар өчен бик мавыктыргыч, аларны укуга кызыксынуларын арттыра. Шулай ук, төрле фотосурәтләр кулланырга мөмкин.

Башлангыч чорда диалогик сөйләмгә өйрәнеп бетеп булмый. Иң мөһиме: алар сорау бирә, җавап әйтә ала. Үрнәк буенча диалог төзи беләләр, диалогны тыңлый һәм аңлый беләләр.

Татар телендә диалог сөйләмнең беренчел күнекмәләре барлыкка килү әзер монолог сөйләмнең формалашуына китерә. Монолог сөйләмгә түбәндәгеләр хас:

– Уй-фикерләрне сөйләп аңлатуның эзлеклелеге (диалогка караганда, монологтагы җөмләләр арасында логик бәйләнеш ныгырак була.)

– Монолог сөйләм өзлексез (биредә уй-фикерләр формалашу сөйләү процессы белән бергә бара.)

– Монологик сөйләм билгеле бер сөйләм тизлегенә һәм укытуның һәр чоры өчен аерым күләмгә ия.

Монологик сөйләмгә өйрәткән вакытта, укытучы автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган күнекмәләрнең тулы комплексына ирешергә тырышырга тиеш.

Башлангыч чорда укучыларның татар телендәгемонологик сөйләменә хәбәр итү, тасвирлау, хикәяләү кебек формалар хас була. Шунлыктан, программадагы темаларны үткәннән соң, үз мәктәбең, гаиләң турында зур булмаган хәбәрләне телдән төзи белү монолог әйтелмәләренең беренче төренә керә.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Монологик сөйләмнең икенче төре – ул җанлы һәм җансыз предметларның тышкы кыяфәтен,әлеге предметларның билгеләрен һәм хәрәкәтләрен балаларга таныш булган грамматик форма һәм төзелмәләрне файдаланып тасвирлау. Мәсәлән, картинага исем бирергә, аның композицион төзелешен билгеләргә, предметларны, кешеләрне тасвирларга, хикәяләү планын төзергә. Нәкъ шушыларны заманча технологияләр ярдәмендә интерактив тактада күрсәтелсә биктщ уңышлы булыр иде.

Сюжетлы хикәяләү монологик әйтелмәләрнең өченче төре булып тора. Укучыларга, шулай ук, түбәндәге биремнәрне тәгъдим итәргә була: бирелгән темагаукытучы башын яки ахырын интерактив тактада күрсәткән яки аудирование ярдәмендәтыңлатылган хикәяне төзеп бетерү һ.б.

Хикәя төзү өчен ирекле тема сайларга, шулай ук укылган яисә тыңланган текстның эчтәлеген файдаланырга мөмкин.

**Йомгаклау.** Укучыларның монологик һәм диалогик сөйләмен стимуллаштыру коммуникатив белем бирүнең әһәмиятле методик алымнарның берсе булып тора. Әгәр бала аз сөйләшә яки бөтенләй сөйләшми икән, бу үз фикерен белдерү өчен аның сүз запасы аз булу аркасында, сөйләм күнекмәләре булмавын күрсәтә. Шунлыктан, баларның сөйләмен стимуллаштыру эше укытучының ныклы игътибары астында булырга тиеш. Куйган максатларга һәм уңай нәтиҗәләргә ирешер өчен укытучыга заманча технологияләр ярдәмгә килә. Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә диалог һәм монолог сөйләм телен үстерү бик кызыклы, мавыктыргыч һәм истә калырлык итә.

## Әдәбият исемлеге

1. Асадуллин А.Ш. Дидактический материал для русскоязычных учащихся. Казань, «Магариф», 2002г.,36 стр.

2. Әсәдуллин А.Ш. Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре, Казан, «Мәгариф» нәшрияты,2006 нчы ел, 131-132 б., 135б., 143-145 битләр.

3. Хәйдарова Р.З. Рус телендәурта гомуми белем бирүче мәктәпләрдә татар теле укыту программасы: 1-4 сыйныфлар (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / Р.З.Хәйдзрова, Н.Г. Галиева, Ә.Г. Әхәтова. – Казан: Мәгариф, 2009 – 60 б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУ-УКЫТУ ЫСУЛЛАРЫН ҺӘМ АЛЫМНАРЫН КУЛЛАНУ

***Сафина Г.Ф.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*« 137нче мәктәбе”*
*Казань, Татарстан*

**Теманың актуальлеге.** Бәйләгеч сүз төркемнәрен өйрәтүдә уку-укыту ысуллары һәм алымнары (укытучы сүзе, әңгәмә, дәреслек белән эш, күнегүләр белән эш, өлешчә эзләнү, тикшеренү, проблемалы укыту, тел күренешләрен күзәтү һәм аларга анализ ясау, укучыларның мөстәкыйль эше, шулай ук чагыштыру, гомумиләштерү, алмаштыру, өстәү, морфологик анализ, алгоритм кору һ.б.) кулланыла. Алар өйрәнелә торган кагыйдәгә һәм сыйныфның әзерлегенә карап сайланырга тиешләр.

Уку-укыту ысуллары – укучыларның белем һәм күнекмәләрен үзләштерүләренә, танып белү эшчәнлекләрен активлаштыруга, дөньяга карашлары формалашуга һәм сәләтләре үстерүгә китерә торган, укытучының һәм укучыларның бергәләп эшләү юллары ул. Икенче төрле әйткәндә, ысул – алга куйган максатка ирешү юллары һәм алымнары. Димәк, уку-укыту ысуллары – укытучы белән укучының белемнәрне үзләштерү өлкәсендә бергәләп эшләү юллары.

Укыту алымнары – укыту ысулының иң кечкенә өлешләре. Алым кечкенә дидактик максатларны тормышка ашыру өчен кирәк. Мәсәлән, сүзлекләр белән эшләү, грамматик анализлар ясату, иншалар яздыру, грамматик биремле язма эш эшләтү, уен элементларын кертү һ.б. Укыту чараларына күрсәтмә әсбаплар, таблица, карточкалар, плакатлар, төрле рәсемнәр кирә.

1960 нчы елларда И.Я. Лернер һәм М.Н. Скаткин түбәндәге ысулларны аерып алып күрсәтелә: информацион-рецептив ысул, проблемалы аңлату ысулы, репродуктив ысул, өлешчә эзләнү ысулы, тикшеренү ысулы. Бүгенге татар телен укыту методикасы нигездә әнә шушы уку-укыту ысулларына нигезләнә.

**Тикшерү ысуллары.** Татар телен өйрәтү дәресләрендә түбәндәге ысуллар кулланыла: 1) хәбәр итү – истә калдыру ысулы, 2) аңлату – аңлау ысулы, 3) өлешчә аңлату – эзләнү ысулы, 4) эшкә өндәү – тикшеренү ысулы. М.М.Зәкиев укыту алымнарына түбәндәгеләрне кертә: укытучы сүзе, әңгәмә, телне анализлау, телдән һәм язма күнегүләр эшләү, дәреслек һәм кулланма белән эшләү, күрсәтмә әсбаплар өстендә эшләү [2, б 103].

Б.Б.Мифтахов ысулларны репродуктив һәм иҗади юл белән белем бирү ысулларына бүлә. «Беренчеләренә – материалны ятлату ысулы, хәбәр итү төсендә аңлату ысулы, күрсәтмәле аңлату ысулы, икенче төркемгә -материалны проблемалы итеп аңлату, өлешчә эзләнү ысулы, эзләнү-тикшеренү ысулы керә», – ди ул. Укыту алымнарын түбәндәгечә санап чыга: 1) әңгәмә, 2) дәреслек, дидактик материаллар һәм башка чыганаклар белән эшләү алымы, 3) күрсәтмәлелектән файдалану алымы, 4) экскурсия үткәрү һәм аның материалларыннан файдалану алымы, 5) грамматик анализ алымы, 6) таблица

һәм схемалар төзү алымы, 7) язма эшләр үткәрү һәм хаталар өстендә эшләү алымы, 8) мәктәп лекциясе, 9) грамматик уеннар куллану алымы, 10) техник чаралардан файдалану алымы [3, б 48].

Д.Г. Тумашева укытучының түбәндәге эш алымнарын күрсәтә: 1) укучыларның башлангыч классларда алган белемнәрен һәм темалар арасындагы бәйләнешне исәпкә алу; 2) грамматик төшенчәләрне төркемләргә өйрәтү; 3) дәреслек материалына план төзү; 4) таблицалар төзү [1, б 143].

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Дәресләрдә төрле ысуллар кулланып эшләү уңай нәтиҗәләргә китерә.

Шулай итеп, укучылар өлешчә укытучы ярдәме белән, өлешчә үзләре эзләнеп һәм анализлап, бәйләгеч сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә алалар. Мәсәлән, 307 нче күнегүне үтәп, үзләре нәтиҗә чыгарганнан соң, 221 нче биттәге кагыйдә белән (71 нче параграф, бәйлекләр турында гомуми төшенчә) танышалар. Димәк, бу кагыйдәгә укучылар өлешчә эзләнү яки тикшеренү ысулы ярдәмендә үзләре килә. Кагыйдә яңа алган белемне системалаштыру өчен хезмәт итә. Мондый ысул белән алынган белем укучылар хәтерендә озак сакланырга тиеш. Һәр теманы башлаганда, укытучы иң элек укучыларга сораулар бирә, алдагы дәрестә өйрәнгәннәрне кабатлата. Биредә һәр дәрестә үтелгән материалны кабатлау алымы кулланылуын әйтеп узарга кирәк. М.Ф.Фазлуллин фикеренчә, татар теле дәресләрендә төп алым булып үтелгән материалны кабатлату тора. Ул, гомумән, татар теле дәресләренең төп төрләренә түбәндәгеләрне кертә: 1) яңа белемне, кагыйдәне сөйләп аңлату, нәтиҗә чыгару; 2) алынган белемне һәм күнекмәләрне ныгыту; дәрес материалларын сөйләтү, укыту, күнегүләр эшләтү, укучылардан мисаллар әйттерү; 3) алынган белемне үзләштерү дәрәҗәсен сынау; сөйләтү, контроль эшләр эшләтү; 4) үтелгән материалны кабатлау: а) теманы кабатлау, б) чиректә үткәннәрне кабатлау, в) ярты уку елы эчендә үткәннәрне кабатлау, г) ел буенча үткәннәрне кабатлау, д) элекке классларда үткәннәрне кабатлау [2, б171]. Дәрес барышында әлеге төр дәресләр кушылып барырга мөмкин. Без югарыда укучыларның башлангыч сыйныфларда үткәнне кабатлавын, бер бүлек белән икенчесен бәйләп кабатлатуны, өлешчә эзләнү, тикшеренү ысуллары белән яңа материалны өйрәнү, алган белемне күнегүләр белән эшләп ныгытуны күз уңында тотабыз.

Укытучы дәресне ике төрле башлап җибәрергә мөмкин. Беренчесе – аңлату-күрсәтү, репродуктив ысулларга таянып, дәресне яңа кагыйдәне өйрәнүдән башлау: 334 нче күнегүдәге (6 нчы сыйныф дәреслеге) таблица белән танышып (75 нче параграф), укучыларга теркәгечләрнең төркемчәләре турында мәгълүмат бирү. Икенче юлы – иҗади юл. Тактада алдан әзерләнгән таблицага нигезләнеп, укучыларда булган белмнәрне искә төшертү, өлешчә генә аңлату. Соңыннан кагыйдә белән таныштырып, төрле алымнар ярдәмендә мөстәкыйль һәм иҗади эшләр үткәрү юлы белән материал ныгытыла, гамәли куллана белү күнекмәләре булдырыла: карточкалар белән эшләү алымы, грамматик биремле язма эшләр, тестлар белән эшләү, уен элементларын кертеп җибәрү һ.б.

Йомгаклау. Димәк, бәйләгеч сүз төркемнәрен өйрәнгәндә материалны әзер килеш бирү (репродуктив һәм аңлату-күрсәтү ысуллары ярдәмендә) һәм иҗади характердагы ысуллардан (өлешчә эзләнү, тикшерену ысуллары) файдаланыла. Дәресара, темаара бәйләнешләр күздә тотыла. Укучыларның сөйләме үстерелә. Укучылар дөрес язарга, логик эзлекле итеп уйлый белергә, матур итеп сөйләргә өйрәнәләр.

**Әдәбият исемлеге**

1. Вәлиуллина З.М. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе / З.М. Вәлиуллина, К.З. Зиннәтуллина, М.А. Сәгыйтов. – Казан: КДПИ, 1972. – 205 б.

2. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы / Ф.Ә. Ганиев. – Төзәт. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 271 б.

3. Зәкиев М.З. Туган телне укытуның кайбер гомуми дидактик принциплары һәм методлары / М.З. Зәкиев. - Кит.: Татар телен укыту мәсьәләләре . – Казан, 1975. – Б. 632.

4. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек / М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

5. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М. Ибраһимов. – Казан: Тат.кит.нәшр.,1989. – 75 б.

6. Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М. Ибраһимов. – Казан: Тат.кит.нәшр.,1989. – 81 б.

# УКУЧЫЛАРНЫҢ ИҖАДИ АКТИВЛЫКЛАРЫН ҮСТЕРҮДӘ КЛАССТАН ТЫШ ЭШЛӘРНЕҢ РОЛЕ

***Сафина Г.В.***
*татар теле укытучы*
*“83нче лицей”*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, илдә, җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр татар теле һәм әдәбияты укытучылары алдына яңа максат-бурычлар куйды. Укучыларның белем алу эшчәнлеге белән идарә итү, рухи һәм физик үсешен, кызыксынучанлыгын үстерергә булышу – шуларның иң мөһиме. Моңа кадәр дә шундый максатлар куйдык бит дигән фикер белән дә килешәм. Ләкин 21 нче гасырда яшәвебезне, яңа техник мөмкинлекләр базасының югары дәрәҗәдә булуын уйлаган очракта, максатның катлаулы булуын күрәбез. Димәк, яңалыкка омтылучы, заман сулышын тоючы, белемен өзлексез камилләштерүче, укыту-тәрбия эшенә иҗади якын килүче укытучы гына бу максатны тормышка ашыра ала. Укытучы иҗади шәхес булырга тиеш. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык- бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Укытучыны иҗади шәхес буларак тасвирлый торган берничә билгене, үзенчәлекне аерып күрсәтергә мөмкин:

1. Шәхеснең гадәттәгедән үзгәчәрәк фикер йөртергә сәләтле икәнен дәлилли һәм укытучы вазифасын башкарырлык дәрәҗәдә өлгереп җиткән шәхес булуын раслый торган акыл күрсәткечләре, акыл сыйфатлары.
2. Активлык, яхшы хәтер, эчке сиземләүнең көчле булуы. Болар үз чиратында һәр эштә башлап йөрергә сәләтлелектә, ихтыяр көченә ия булуда, максатчанлыкта, камиллеккә омтылуда чагылыш таба.

Бүгенге татар теле укытучысы, иҗади шәхес буларак, күп укырга,әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга гына түгел, ә үзенең укучысын да ияртеп бара алырга тиеш. Балаларда кызыксыну уята алган укытучы – үз эшенең остасы. Ул укучылар алдында гына түгел, хезмәттәшләре арасында да хөрмәт һәм дан казанырга, эчке һәм тышкы күркәм сыйфатларга ия булырга,сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләрен үтәргә, компьютер һәм видеотехника белән эшли белүдә укучыларга үрнәк күрсәтә алырга тиеш.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә бүгенге заман баласы белән эшләү алымнары, укыту-тәрбия эшен оештыру да булган үзгәреш турында сүз алып барыла. Соңгы унъеллыкта мәктәп күп үзгәрешләр кичерде. Укучыны мөстәкыйльлеккә өйрәтү генә җитми, ул үзенчә, үзгәчә фикер йөртергә, өлкәннәр кушканнан чыгып түгел, үз башы белән эш итә белергә, теләсә нинди үзгәрешкә яраклаша алырга сәләтле булып җитлегергә тиеш. Әдәбият укытучысы буларак, мин эш методикамны шушы юнәлештә алып барам. Укучыларга ошый, чөнки үз фикереңне башкаларныкы белән чагыштыра алу, бәхәскә керү, дәлилләү, һәр нәрсәгә үз позицияңне булдыру укучыны шәхес итеп тоярга ярдәм итә. Бүген укыту һәм тәрбиядә нәтиҗәлелек турында сүз алып барабыз. Нәтиҗәнең күзгә күренеп торуы,билгеле булуы шарт.

Белемлелек дәрәҗәсен билге күрсәтми, укучының укырга теләгән сүндермәү мөһим. Һәркемнең мөмкинлеге төрлечә. Югары билгеләргә укымыйча да, бала үз кысаларында уңышка ирешергә мөмкин. Әлеге мисал укытучының үз эшенә иҗади якын килергә тиешлеген тагын бер кат ассызыклый һәм иҗади шәхес тәрбияләүгә нигез булып тора.

Иҗади шәхес тәрбияләү өчен, укытучының иҗади булуы шарт. Укытучының иҗадилыгы ул үз эшен яратып башкарганда гына тормышка аша ала. Үз эшен яратып башкармаган укытучыдан укучылар читләшәләр.

ЮНЕСКО ның күптеллелекне яклап чыгуы уңаеннан, 2000 нче елда БМО ның 21 нче февральне Халыкара Туган тел көне дип игълан итүен беләбез инде. Монда сүз халык җырларын, биюләрен, гореф-гадәт, йолаларны, халык авыз иҗатын, туган телне саклап калу һәм яшәтәү турында барганлыгы аңлашыла. ”Тел – кешелекнең рухи мирасының аерылгысыз бер өлеше – дигән иде ЮНЕСКОның генераль директоры К. Мацуура. – Телләрнең барлыкка килеп, туып кына калмыйча, юкка чыгу ихтималын да искә алсак, без аларны якларга һәм шуның белән бөтен кешелек дөньясы өчен мөһим булган мәдәниятләр күптөрлелеген саклап калырга тиешбез. ЮНЕСКО бу уңайдан көчен кызганмый һәм дәүләтләрнең туган телләрне саклау сәясәтенә һәрьяклап булышлык күрсәтә”

Үз-үзен, туган телен, киләчәген хөрмәт иткән халыкларда туган телгә мөнәсәбәт ЮНЕСКО яклавыннан башка да һәрвакыт игътибар үзәгендә. Мәктәптә телебезгә булган хөрмәтне мин югары бәяләр идем. Укучыларым да туган телебезне, татар милләтен, үзебезнең телебез белән бәйле булган һәрнәрсәне хөрмәт итәләр һәм моның башкача булуы мөмкин түгел. Гомумән алганда, безнең туган телебез – татар теле, шагыйрь әйтмешли, ”какканны вә сукканны” күтәрүче ятим хәлендә. Уйлап карасак, тел-әдәбият укытучыларын яу кырындагы солдат белән чагыштырырга мөмкин. Туган телебезнең киләчәген соңгы вакытта телдән төшмәгән белем стандартларына, укыту-методик әсбапларның камиллегенә никадәр бәйле булмасын, беренче чиратта, нәтиҗә балалар укыту-тәрбияләү дигән фидакарь хезмәткә алынган мөгаллимнәрнең шәхси җаваплылыгына, аларның үз эшенә мөнәсәбәтенә бәйле. Укучыларның татар телен тирәнтен үзләштерүләре һәм фән белән кызыксынуларын арттыру өчен, класста һәм өйдә эшләү генә җитми, класстан тыш эшләрне оештыру, аларны эзлекле һәм кызыклы итеп алып бару зарур. Татар теленнән класстан тыш эшләрне оештыруның максаты түбәндәгеләр:

1. Укучыларның ана теле белән кызыксынуларын үстерү, аларда татар халкы тарихын, аның бай мирасын өйрәнү теләкләрен уяту.

2. Укучыларның дәрестә алган белемнәрен тирәнәйтү, аларны тормышта гамәли куллана белү күнекмәләрен бирү, эзләнү эшләре алып бару.

3. Аерым телләр буенча дәрестә алган грамматик, орфографик, пунктуация, сөйләм теле һәм язу күнекмәләрен ныгыту һәм үстерү.

4. Класста бирелә торган төрле яклы тәрбияне (патриотик, гуманлылык, эстетик, дуслык-иптәшлек, хезмәт тәрбиясе һ.б.) класстан тыш эшләр белән бәйләп дәвам итү.

Шушы максаттан чыгып, класстан тыш эшләрне оештырганда, аерым укучылар белән генә эшләмичә, төрле юнәлештә барлык укучыларны җәлеп итәргә тырышабыз. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм белем дәрәҗәләрен истә тоткан хәлдә, класстан тыш эшләр план нигезендә һәм оешкан төстә үткәрелә.

Беренче баскыч – башлангыч мәктәп. Үз максаты, эш юнәлешләре булган класстан тыш эшләр кечкенә балаларның кызыксынуларын, яраткан эш төрләрен, уеннарын кертеп үткәрелә. Иң мөһиме: бала татар телендә матур сөйләшергә, үз фикерләрен курыкмыйча әйтергә, сәнгатьле матур сөйләргә, уйнарга-җырларга тиеш. Боларның барысын яратып башкарганда гына максатка ирешеп була. Бу баскычта “Тапкырлар һәм зирәкләр “,”Әкияттә кунакта”,”Бу белергә кызыклы” юнәлешләре буенча эш алып барыла. Куелган максат:

– укучыларның күзаллау сәләтен үстерү, яхшылык һәм явызлык, кыюлык һәм куркаклык,юмартлык һәм саранлык төшенчәләренең асылын әкиятләрдән чыгып аңлату;

– тапкыр һәм зирәк булырга, дөрес фикер йөртергә, халык авыз иҗатына хөрмәт һәм ихтирам хисе тәрбияләү, милли бәйрәмнәрне, халык уеннарын өйрәнү һәм үткәрү, халкыбызның тарихи мирасына сак караш тәрбияләү;

– укучыларда иҗади активлыкка омтылыш тәрбияләү, мөмкинлекләр тудыру, кечкенә күләмле иҗат җимешләренә зур игътибар бирергә өйрәтү.

Башлангыч баскычта класстан тыш эшләрне оештырганда, төп игътибар баланың танып-белүен үстерүгә бирелә. Баланың рухи байлыгы халык әкиятләрен, мәкаль һәм әйтемнәрен, табышмак, уйдырмаларын никадәр күбрәк белүе белән бәйле. Иң мөһиме – баланы яхшы белән яманны аерырга өйрәтү. Бу баскычта бала эшчәнлегенең төп формасы булып уен санала. Бала уен эшчәнлеге ярдәмендә активлаша, аралаша, үз уй-фикерләре белән бүлешә. Онытылган бәйрәмнәрне, традицияләрне искә төшерүне дә уен, кичәләр ярдәмендә оештыру бик уңышлы була. Бала яшьрәк булган саен, аның истә калдыру сәләте көчлерәк. Шуны истә тоты, башлангыч баскычта, күптөрле юнәлештә балаларда кызыксындыру уята торган дәрестән соң чаралар оештырыла.

Урта баскыч 5-8 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа нигезендә эшлекле чаралар үткәрүне күз алдында тота. Төп игътибар гаилә, туган авыл, дуслык, якташлык, нәсел шәҗәрәсен өйрәнү белән бәйле. Бу баскычта укучыларның эзләнү эшләре белән кызыксынуларына һәм иҗат активлыкларына өстенлек бирелә. ”Алтын каләм”, “Без татарча сөйләшәбез”, ”Тел дигән дәрья бар” оешмаларында шөгыльләнгән укучыларның күбесе, өлкән класска җиткәч ,олимпиада призёрлары, инша бәйгеләренең җиңүчеләре булалар. Шушы баскычта нәфис сүз осталары үсеп җитлегә һәм “Ватан”, ”Йолдызлык”, ”Дулкыннар” фестиваль-бәйгеләрдә уңышлы чыгышлар ясыйлар. Дәрестән тыш чаралар оештырганда алга куелган максат:

– нәсел шәҗәрәңне өйрәнү, гаилә традицияләрен саклауга омтылыш тәрбияләү, өлкән һәм яшь буын арасында хөрмәт, аңлашу, ярдәмләшү сыйфатларын ныгыту;

– туган як тарихы, авылның күренекле кешеләре, авыл белән бәйле атамалар, кушаматлар өйрәнү;

– укучыларның танып-белү сәләтен үстерү, авыл һәм районыбыз мәдәнияте тарихын өйрәнү, әхлаклы һәм эстетик зәвыклы шәхес тәрбияләү.

Күпьеллык практика күрсәткәнчә, дәрес теория белән өстенлек алса, дәрестән тыш вакытның файдалы үткәрелүе иҗади шәхес тәрбияләүгә күбрәк мөмкинлек бирә. Бала үзен иркен тота, теләп аралаша, сәләтен ачыклый, кызыксына. Дәрестән тыш вакытта укучының белеме түгел, киләчәккә сәләте ачыклана һәм бу сайлыйсы һөнәр белән дә бәйле булырга мөмкин.

Югары баскычка керүче 9-11 нче сыйныф укучылары өчен җитди, җаваплы, эшлекле юнәлешләр сайланган.Үзем югары баскычта эшләүче укытучы буларак, заман белән бергә атлаучы, уй-фикерен ныклап әйтүче, иҗади шәхес тәрбияләү өстендә эш алып барам. Фәнни-тикшеренү эшләрендә катнашу, республикакүләм инша бәйгеләренә әзерлек, татар теле һәм әдәбияты буенча район, республика олимпиадаларында уңышлы чыгыш ясау, яңа формада дәүләт аттестациясенә әзерлек белән беррәттән әдәби чаралар, очрашулар, күңелле кичәләр, экскурсияләр оештыру телебезгә булган хөрмәтне тагын да үстерә дип саныйм. “Театр яктылыкка, яктылыкка, нурга илтә” әдәби түгәрәге, рус балаларын татар теленә өндәүче “Мин татарча сөйләшәм” кызыклы грамматика уеннар, ”Иҗади шәхес тәрбияләү” электив курс эшчәнлеген югары бәялисе килә. Соңгы вакытта мәгариф системасына кертелә башлаган Сингапурча укыту юлларын да дәрестән тыш вакытта рус балалары өчен куллана башлау укучыларда кызыксыну уятты.

Соңгы елларда мәктәбебез укучылары район күләмендә татар теле һәм әдәбиятыннан үткәрелгән фән бәйгеләрендә беренче, республика күләмендә призёрлар рәтендә икәнен исәпкә алганда, эшебез җаваплы һәм нәтиҗәле икәне күренә. Инша бәйгеләрендә җиңүчеләребез, диплом ияләре бар. Укучы һәм укытучы тарафыннан фәнгә мәхәббәт, хөрмәт булганда гына матур нәтиҗә-ләргә ирешеп була. Моның өчен балаларның кызыксынуларын күрергә, сәләтләрен ачарга, иҗадилыкны үстерергә, максатларына ирешергә булышырга кирәк.

Укучының иҗадилыгын үстерүдә зур роль уйнаучы эш төренең берсе – сочинение язу. Сочинение – укучының теге яки бу темага карата фәлсәфи фикер тирәнлеген, аның социаль һәм мәдәни үсеш, танып белү дәрәҗәсен күрсәтә торган иҗади эше. Сочинениедә, һичшиксез, иҗадилык, образлылык булу зарур һәм ул, беренче чиратта, сайлап алынган яисә бирелгән теманы аңлап анализлауда һәм шәхси мөнәсәбәт белдерүдә чагылырга тиеш. Бу исә сочинение авторының киң эрудицияле, укымышлы һәм тема кузгалткан проблемага карата кичерешләр тирәнлеген язма сөйләмдә күрсәтә белүен таләп итә.Сочинение текстын тасвирлау аеруча әһәмиятле төс ала, чөнки нәкъ шушы эшчәнлек интеллект, логик һәм иҗади фикерләү күнекмәләре үсешен, авторның әхлакый йөзен, кыйммәтләрне танып-белү һәм мөнәсәбәте дәрәҗәсен күрсәтә. Сочинение укытучының укучылар белән алып барган әзерлек эшчәнлегенә билгеле бер күләмдә контроль кисем дә булып тора. Шуңа күрә, сочинение язарга керешкәнче алып барылырга тиешле комплекслы эшчәнлекне барлап үтик. Бу - сочинение эчтәлеген проектлаштыруга юнәлтелгән эзлекле эш этаплары:

– теманы төрле яктан карап аңлау эше оештыру (эшчәнлек төрле була ала:әңгәмә, дискуссия, проблемалы сораулар нигезендә индивидуаль яки төркемнәрдә эш);

– материал туплау. Төп фикерне ассызыклаучы, әһәмиятле сүзләрне, фразаларны аерып алу;

– язылачак сочинениенең төп идеясен ачыклау; идея белән теманы килештерү;

– сочинениеның төп фикерен (тезисын) формалаштыру, эшнең максатын конкретлаштыру (сочинение аша әйтеләчәк төп фикерне аерып алырга һәм материалны – кулланылган барлык мәгълүматны шуңа юнәлдерә белергә тиеш);

– сочинениенең төп фикерен ачу логикасын, аргументлар системасын – планын төзү;

– план нигезендә эзлекле һәм образлы итеп, әдәби тел нормаларына туры китереп , стилистик , орфографик һәм грамматик хаталарсыз язу.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Иҗади бәйгеләрдә катнашканда шушы таләпләрне үтәү зарури. Сочинение язу- зур сәләт, барлык укучы да аны тоя алмый. Бу юнәлештә индивидуаль эш алып барыла, журналистика белән кызыксынган укучылар өчен әзерлек этабы булып тора. Электив курста журналистика һөнәренә кызыксындыру уятырга тырышам. Программада матур әдәбият серләрен үзләштерергә теләүчеләр өчен дә файдалы мәгълүмат күп: теоретик яктан белем бирү, практик күнекмәләр булдыру, укучыларның бәйләнешле язма сөйләмен оештыру. Хәбәрче өчен кирәкле сыйфатлар, хәбәрченең бурычлары хакында аңлату; журналистика тарихы, бүгенге татар мәтбугаты, газета-журналларга язылу, жанр төрләре белән таныштыру максат итеп куела. Практикада интервью алу, рецензия язу, мәкалә стиле, хат төрләре, очерк, парча, фельетон жанрларын редакцияләү күздә тотыла.

**Йомгаклау.** Ана теле-зур хәзинә ул, дибез. Һәр халык үз тарихын, үз телен, үз рухын, җыр-моңын сакларга, аны яңа буыннарга тапшырырга тели. Ә бу бары тик тел ярдәмендә генә башкарыла. Димәк, милләтне саклыйбыз дибез икән, иң әүвәл телне саклау зарур. Ана теленең югалмавы, өйрәтелүе өчен татар теле һәм әдәбияты укытучылары үзләрендә җаваплылык тоярга тиеш. Мин үземнең татар теле укытучысы булуым белән горурланам һәм, эшемнән тәм табып, укучым белән бергә алга атлыйм.

**Әдәбият исемлеге**

1. Әгъзамов Ф. Әйдә,халыкка хезмәткә. – Казан, 2010.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт китабы. – Казан:Дом печати, 2001.
3. Гарифуллин В.З. Үткен каләм,үткен күз. – Казан, 1995.
4. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004.
5. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанова Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. Теория,тарих. – Казан: Мәгариф, 2004.
6. Көч һәм рух тамырлары: Әдәплелек дәресләре. 5-11 нче сыйныфлар өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2000.

# ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ЭЧТӘЛЕГЕ

***Тахаувова Ф.М.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*“15нче мәктәбе”*
*Набережные Челны, Россия*

**Теманың актуальлеге.** “Татарстан Республикасы Халыклары телләре турында” гы закон һәм Дәүләт программасы мәктәпләр, балалар бакчалары алдында да зур бурыч – Татарстанда яшәүче татар, рус, һәм башка милләт балаларына татар һәм рус телләрен яхшылап өйрәнү бурычын куйды [1,б 15]. Әлеге гаять мөһим карарны хәл итүнең асылы гомуми белем бирү мәктәпләре укытучыларына кайтып кала. Алар милләтара мөнәсәбәтләрнең үзара ярашып торуына ярдәм итүче татар-рус, рус-татар, милли икетеллелекне формалаштыру буенча төп функцияне үтәүчеләр.

Бу үзгәрешләр илебезнең мәгариф системасы эчтәлеген яңартуны таләп итә.

Тирән белемле, югары әхлаклы, үз–үзен үстереп, шәхес буларак танытучы укучы тәрбияләү бүгенге көннең бурычы. Бу уңайдан татар теле һәм әдәбияты укыту да эчтәлеге һәм формасы ягыннан яңарырга һәм заман ихтыяҗларына җавап бирерлек итеп үзгәртелергә тиеш Чөнки республика инновацион үсеш стратегиясен һәм программасын гамәлгә ашыра. Хәзер педагогик тәрбия һәм тәҗрибә заман таләпләренә җавап бирергә тиеш. Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, мәктәпләрдә укытуның сыйфатын сизелерлек дәрәҗәдә күтәрүче яңа (инновацион) технологияләр уңышлы файдаланыла башлады. Мәгарифне инновацион үстерү – республикабыз һәм илебез киләчәгенең нигезе.

Бүгенге татар теле укытучысының бурычы – һәр укучыга үз активлыгын һәм иҗадилыгын күрсәтү, телне практик һәм теоретик яктан өйрәнү өчен, шартлар тудыру. Әлеге максатны татар теленә өйрәтү барышын файдалы, кызыклы итеп һәм заманча технологияләрдән файдаланып үткәргәндә генә тормышка ашырырга мөмкин. Ә компьютер технологияләре бүген иң актив кулланылучы шундый технологияләрнең берсе булып тора. Әмма аның турында әле төгәл, системалы мәгълүмат биргән хезмәтләр юк диярлек. Безнең әлеге хезмәтебез шул юнәлештәге эшләрнең берсе булып тора.

**Тикшерү ысуллары.** Бүген белемле, тәрбияле, көндәшлеккә сәләтле, тормышта үз юлын табарга әзерлекле, яхшыны яманнан аера, тиешле карар кабул итә белгән шәхес тәрбияләү өчен, искечә эш итү генә җитми. Без яңа технологияләр зур үсеш алган чорда яшибез һәм замана кушкан инновацияләрне мәгарифтә кулланырга тиешбез. Әлеге фәнни хезмәтебездә без соңгы вакытта укыту системасында иң киң кулланылучы шундый технологияләрнең берсен өйрәнергә алындык

Татар телен чит аудиториядә укытуны мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк итү – бүгенге көн педагогикасының мөһим бурычларыннан берсе. Ә уңай нәтиҗәләргә ирешүдә заманча технологияләргә таяну ярдәм итә ала.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул – әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар [1,б 43].

Инновацион технология буенча татар теленә өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта укыту процессы төп нәтиҗәгә – укучының актив коммуникатив эшчәнлеккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интеллектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары дип түбәндәгеләр санала:

6. укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;

7. аның танып-белү активлыгын арттыру;

8. тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

- укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү инициативасын тагын да үстерү [1,б 45].

Заманча технологияләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтеп була:

1. шәхескә юнәлтелгән технологияләр;

а) Ш.А. Амонашвилиның шәхескә хөрмәт белән карау технологиясе;

б) үзара хезмәттәшлек педагогикасы технологиясе;

2. укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр;

а) проблемалы укыту;

б) аралашуга өйрәтү технологиясе;

3. уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр;

а) терәк схемаларны кулланып, алга китеп укыту технологиясе;

б) белем бирүнең компьютер технологияләре [1,б 76.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Дәресләрдә заманча технологияләр кулланып эшләү уңай нәтиҗәләргә китерә.

Хәзер шуларның кайберләренә тукталып китик. Рус телле балаларны татарча сөйләмгә өйрәтүдә Р.З. Хәйдәрова программасына нигезләнгән коммуникатив (аралашу) технология куллану уңышлы нәтиҗәләр бирә. Әлеге технология укучыга татар телен аралашу нигезендә өйрәтү мөмкинлеге бирә.

Рус телле балаларны татар сөйләменә өйрәтү процессы коммуникатив технология нигезендә циклылыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик яктан катлаулылыгына, текстның күләменә, укучыларның фикерләү сәләтләре дәрәҗәсенә бәйле.

Текстны өйрәнү өч этаптан тора: текст алды, текст һәм текстан соңгы этаплар. Беренче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнергә тиешләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр лексик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛКФ) һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛГФ) дип атала. Әгәр тел өйрәтү процессын тел һәм әдәбият дәресләренә бүлү укыту планына кертелгән икән, без аларны татар теле

дәресләре, ягъни татар теленең лексикасына, грамматикасына өйрәтү дәресләре дип атый алабыз. Укучылар, текстны лингвистик яктан беркадәр кабул итәргә әзерләнгәч, текстны үзен укырга күчәргә мөмкин. Бу дәресләрдә, нигездә, турыдан-туры текстны уку, текст буенча эш күнегүләре өстенлек итә. Шуңа күрә аны уку дәресләре дип атарга мөмкин. Дәрес тибы ягыннан алар лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре (ЛГКК) була. Бу тип дәрес тә, текстның катлаулылыгына карап, бер яки берничә дәрес булырга мөмкин. Мондый дәресләрдә алда өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә [1,б 109].

Тексттан соңгы этапта текст эчтәлеге һәм аңа салынган әхлакый проблема буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла. Дәрес типлары да диалогик-монологик сөйләм дәресләре дип атала. Бу дәресләрдә тексттагы лексик-грамматик материал сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелә, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм этабына чыгалар. Аңлашылганча, тел өйрәтү процессында татар теле һәм әдәбияты дәресләре үзара шартлы бәйләнештә булалар. Циклда әдәби әсәрне өйрәнү өчен бирелгән сәгатьләр санына татар теле дәресләре саны да, әдәбият дәресләре саны да керә.

Коммуникатив технологияләр нигезендә дәресләрнең төрләре:

- Иҗат һәм фантазиягә таянучы дәресләр: лекция, семинар, сыйныф алдында булган белемнәреңне яклау, зачет-дәрес, укучылар конференциясе һ.б.
- Иҗат һәм фантазиягә таянучы дәресләр: спектакль, коллектив инша, концерт, дәрес-бәхәс.
- Нинди дә булса бер шөгыльне имитацияләү: экскурция, ярминкә, сәүдә йорты.
- Дәрес-уен: дидактик, рольле, ярыш-уеннар.
- Сюжетлы рәсемнәр яки бирелгән текст буенча, шәхси тәэсирләргә нигезләнгән иншага әзерләнү дәресләре.
- Текстны анализлау, аның белән иҗади эшләү, үзеңнең текстыңны уйлау дәресләре [1,б 65].

Укытучы, дәрескә әзерләнгәндә, барлык диалог бәйләнешләренең шартларын уйлап эшләгәндә, уку процессының билгеле бер моделен ясый ала һәм шуның буенча дәресләр бер-берсе белән үрелеп бара.

Бу ысулның структурасы 4 технологик этаптан тора:

2) коммуникатив ситуация структурасы эшләү;
3) укучы белән укытучының бергә эшләвен проектлаштыру;
4) диалогларда катнашу:
5) бәйләнешле сөйләм буенча рефлексия;

Коммуникатив ситуация куеп без, укучыдан дәресләрдә актив катнашу сорыйбыз. Бу тормышчан вакыйга булып, аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт була ала:

- проблемаларны актуальләштерү;
- кичереш һәм фикерләү шартлары;

- карарлар кабул итү, альтернатив нигездә үз гамәлләрен сайлау, өстәмә материал эзләү, аларны анализлау.

**Йомгаклау**.Шулай итеп, коммуникатив технологияләр кулланып үткәрелгән дәресләр укучыларга телне аралашу чарасы итеп тану; дөньяны һәм үзен танып белү, мәдәниятне өйрәнү, иҗади һәм актив, дөрес, матур итеп аралашырга өйрәтү бурычын үти.

Тел укытуда кулланылучы нәтиҗәле технологияләрнең тагын берсе – проблемалы укыту технологиясе.

Проблемалы укытуда, исеменнән үк күренгәнчә, өйрәнүче үзе укыту процессындагы проблемаларны хәл итүдә катнаша.

Бу төр укыту – укытучының укучылар белән берлектә проблемалы ситуацияне хәл итү юлларын эзләү процессы. Бу вакытта балаларның фикерләү сәләте камилләшә, ныклы белем һәм күнекмәләр формалаша. Укучыларда интеллектуаль көч яңа вакыйга, төшенчәләрне аңларга һәм фикер аша үткәрергә тырышкан вакытта, кыенлыкларга очраганда барлыкка килә һәм ул проблемалы ситуациянең тудырылуын, тема белән тирәнтен кызыксынуны, аны хисси кабул итүне һәм укучының ихтыяр көченә ия булуын таләп итә.

Проблемалы ситуация тудыру аша укучылар килеп туган халәттән чыгу юлларын эзләргә өйрәтелә. Бу очракта эш, нигездә, 4-5 кешелек аерым төркемнәрдә бара. Төркемләп эшләү чагыштырмача яхшы нәтиҗәләр бирә, чөнки төркем эчендә үз көченә ышанып бетмәгән укучылар да, мөмкинлекләреннән чыгып, актив эш итә башлыйлар.

Гомумән, укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану – яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Әйтик, дәресләрдә профессор Ә.З.Рәхимовның "Иҗади үсеш технологиясен" куллану да уңай нәтиҗәләр бирә.

Шулай итеп, дәресне төрләндереп, җанландырып җибәрер өчен, яңа алымнар, төрле күрсәтмә материал, кызыклы эш формаларын кулланырга кирәк.

Алда әйтелгәннәрдән нәтиҗә ясап, шуны билгеләргә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур. Татар теле дәресләрендә заманча технологияләр куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек алар шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булырга тиеш. Алар тел өйрәнүдә шактый күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

**Әдәбият исемлеге**

1. Абдуллина Д., Татар теленнән Бердәм республика имтиханын әзерлек өчен тестлар һәм иҗади биремнәр. / Д. Абдуллина, Л. Гилязова. – Казан: Школа, 2008. – 155 б.

2. Әсәдуллин А., Сөйләшергә тел булсын / А. Әсәдуллин, К. Фәтхуллова // Мәгариф. – 2001. – № 9. – Б. 10-12.

3. Әсәдуллин А.Ш., Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре / А.Ш. Әсәдуллин – Казан: Мәгариф, 1998. – 151 б.

4. Максимов Н.Н. Татар теленнән тестлар / Н.Н. Максимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 207 б.

5. Максимов Н.Н. Татар теленнән Бердәм республика имтиханына әзерләнү өчен ярдәмлек / Н.Н. Максимов. – Казан: Школа, 2007. – 127 б.

6. Максимов Н., Мин татарча сөйләшергә телим. Татар теленә өйрәтүдә дистанцион укыту формасы / Н. Максимов, А. Юсипова. – Казан, 2008. – 72 б.

7. Мозаффарова М.Г. Укыту-тәрбия процессын оештыруда татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү мәсьәләләре: гомуми белем оешмалары җитәкчеләре өчен кулланма / Мозаффарова М.Г. – Казан: ТРМҮИ, 2014. – 40 б.

# РОЛЬ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА В ЗАИМСТВОВАНИИ ТЕРМИНОВ В СФЕРЕ ЭКОЛОГИИ

***Файзуллина А.И.***
*студент*
***Ибрагимова Э.Р.***
*д.филол.н., доцент*
*Казанский государственный энергетический университет*
*Казань, Россия*

**Актуальность.** Развитие информационного общества под влиянием социально-политических событий XXI века и IV промышленной революции трансформируют коммуникационные процессы современного общества, оказывая значительное влияние на формирование лексики населения. В условиях глобализации особую актуальность приобретают вопросы преодоления языкового барьера между поколениями. Упомянутые процессы предопределили роль английского языка как основного источника пополнения профессиональной лексики, в частности и в сфере экологии. Данная область знания развивается особенно динамично: обострение глобальных экологических вызовов (изменение климата, загрязнение окружающей среды и снижение уровня биоразнообразия) требует оперативных ответных мер и наличия единого понятийного аппарата для эффективного взаимодействия [1]. Помимо этого, в условиях растущего общественного внимания к экологическим проблемам и увеличения числа гражданских инициатив в этой сфере, ключевым фактором успеха становится эффективная коммуникация между всеми поколениями. Однако зачастую возникают серьезные барьеры. Показательным примером может служить ситуация, зафиксированная в рамках Республиканской программы для волонтеров «Энергия добра», где при защите экологического проекта группа активистов столкнулась с непониманием со стороны экспертной комиссии. Использование активистами сленговых и «нестандартизированных» терминов привело к непониманию со стороны экспертов. Это наглядно демонстрирует необходимость изучения и систематизации используемой лексики для обеспечения точности и доступности информации.

**Методы исследования.** Для достижения цели применен комплексный подход, включающий в себя различные методы исследования, что позволяет провести всесторонний анализ и изучение последствий применения англоязычной лексики профессиональной сфере. В качестве основных методов исследования были выбраны:

1. Индукция – тип мышления, основанный на переходе от частного умозаключения к общему.

2. Кейс-стади – способ изучения реальной практической информации.

3. SWOT-анализ – оценка сильных и слабых сторон, рисков и возможностей в текущий момент времени.

Кроме того, проанализировано интервью с директором по стратегическому развитию Аналитического центра ВЦИОМ Львовым Степаном [3], а также для понимания причин процесса заимствования был задействован социолингвистический подход, учитывающий влияние глобализации и доминирования английского языка в научной коммуникации.

**Результаты исследования.** Проведенный анализ позволил выявить, что в современной профессиональной лексике экологов и эко-активистов наблюдается высокая степень применения заимствованных терминов. Молодое поколение студентов и эко-активистов все чаще обращается к сленгу. Одним из ключевых факторов, влияющих на активное заимствование англицизмов, является представление о превосходстве западного образа жизни. Желая приобщиться к «идеализированной» культуре, молодежь стремится внедрить в свою речь языковые элементы [2, С.106]. Еще одним фактором, способствующим активному заимствованию англицизмов в сленг, является развитие информационного общества. Разовое использование видоизмененного термина может привести к мгновенному широкому распространению в социальных сетях. В тоже время «взрослое» поколение, преподаватели и сотрудники исследуемой сферы, чаще обращаются к общеизвестным терминам, имеющим официальный характер. Основной причиной данного процесса стало определение английского языка как языка международной науки. Публикации в ведущих рецензируемых журналах, выступления на глобальных конференциях и работа международных организаций ведутся преимущественно на английском. Это делает заимствование терминов естественным процессом для интеграции российских исследований в мировой научный контекст. Часть терминов появляется в русском языке вместе с технологиями и концепциями, которые они обозначают. Так, например, появились понятия «гринвошинг» (greenwashing) и «ESG-повестка» (environmental, social, governance) [4].

По мнению директора по стратегическому развитию Аналитического центра ВЦИОМ Степана Львова, взрослому поколению стоит обратить внимание на молодежный сленг, чтобы не произошло отдаления поколений. Эксперт предложил представить, что «сленг – это не мусорный ящик, а своего рода лаборатория, где происходит эксперимент по проверке жизнеспособности тех или иных слов». Таким образом, по мнению Львова, можно отследить, какие слова перейдут в повседневный лексикон, а какие исчезнут.

Полученные результаты свидетельствуют о том, что проникновение англоязычной терминологии в сферу экологии представляет собой закономерную реакцию языковой системы на множество факторов – глобализацию, технологический прогресс и интернационализацию науки. Наличие единого понятийного аппарата в сфере экологии способствуют снижению уровня межпоколенческого языкового барьера, стимулирует возникновение «новых» международных связей.

**Заключение (выводы).** Таким образом, масштабное заимствование английской терминологии в сфере экологии представляет собой не «угрозу» для русского языка, а объективное следствие интеграции России в технологическое и информационное пространство. Этот процесс, вызывающий

закономерные дискуссии, с профессиональной точки зрения выполняет критически важную функцию – создает унифицированное терминологическое поле. Использование общепринятых международных терминов станет ключевым фактором для эффективного международного сотрудничества, позволит людям, принадлежащих к разным возрастным категориям, беспрепятственно понимать друг друга и совместно работать над решением глобальных экологических проблем. Следовательно, необходимо их грамотно адаптировать и интегрировать в языковую систему. Такой взвешенный подход позволит снизить уровень барьера между всеми возрастными категориями людей.

## Список литературы

1. Михайлова В. Глобальные проблемы экологии: причины и виды: сайт [https://forest-save.ru/esg-blog/globalnyie-problemyi-ekologii-prichinyi-i-vidyi] (дата обращения 17.11.2025).

2. Разуваева, Н.Г. Англицизмы в русском молодежном сленге / Н.Г. Разуваева, С.Н. Кайырбаева, Д.К. Ефимов // Учёные записки Шадринского государственного педагогического университета. – 2024. – № 1(3). – С. 106-112. – EDN QVAMHW.

3. Ситникова Д. ВЦИОМ объяснил, почему взрослым следует наблюдать за сленгом молодежи [https://tvzvezda.ru/news/2025941553-Yxb24.html] (дата обращения 17.11.2025).

4. Эколикбез: пополняем лексикон модными словечками [https://green.reo.ru/howto/tpost/ggka0zyk91-ekolikbez-popolnyaem-leksikon-modnimi-sl] (дата обращения 18.11.2025).

# ТРУДНОСТИ ПЕРЕВОДА НАУЧНО-ТЕХНИЧЕСКОЙ ТЕРМИНОЛОГИИ АТОМНОЙ ПРОМЫШЛЕННОСТИ С АНГЛИЙСКОГО НА РУССКИЙ ЯЗЫК

***Федоров М.К.***
*студент*
***Дмитриева Е.В.***
*к.п.н., доцент*
*Казанский государственный энергетический университет*
*Казань, Россия*

**Актуальность.** Атомная энергетика – отрасль энергетики, требующая строжайшего соблюдения всех норм в каждой из её областей, поскольку малейшая неточность может создать угрозу для жизни большого количества людей и привести к необратимым последствиям. Атомная энергетика продолжает активно развиваться как в России, так и за рубежом, происходит активный обмен информацией между странами-партнерами и внутри международных организаций. Неверное употребление специальных терминов может привести к разногласиям юридического, технического и дипломатического характера [1, С.12]. Именно поэтому точный и достоверный перевод терминологии, связанной с атомной промышленностью является одной из постоянных и важных проблем в этой сфере.

Данная работа представляет собой анализ основных трудностей перевода иностранных терминов. Приведены методы, используемые для качественного перевода английской терминологии в контексте атомной энергетики. В процессе написания статьи использовались следующие методы исследования: описание и систематизация информации, сплошная выборка примеров и переводческий анализ.

Многие слова английского языка могут иметь большое количество значений, зависящих от контекста и способа их употребления. Например, слово pellet в разных случаях может употребляться в значении “гранула”, “шарик” или “пуля”, но в контексте атомной энергетики данное слово принимает значение “топливная таблетка”. Переводчик должен иметь довольно глубокие знания в области атомной промышленности для перевода подобных терминов.

В некоторых случаях термин может не иметь прямого эквивалента в русском языке. Например, такие слова как: dissolver (диссольвер), body dose (доза при тотальном облучении тела), breeding gain (избыточный коэффициент воспроизводства ядерного топлива), radiography (радиография). Когда прямого аналога нет, переводчик стоит перед выбором: транскрибировать слово или попытаться создать русскоязычный эквивалент [2, С.94]. Существует три основных метода перевода подобных слов:

1. Транскрибирование или транслитерация – методы, при которых иноязычное слово заимствуется. Воссоздается форма этого слова в русском языке на основе звучания или написания оригинала. Примеры: skrap (скрап),

fluence (флюенс). Данный метод довольно прост в применении, но требует посвященности переводчика в тематику атомной энергетики, поскольку методы транскрибирования или транслитерации можно применить далеко не ко всем англоязычным терминам. Существуют слова, которые на первый взгляд не имеют аналогов в русском языке, но при тщательном изучении данного вопроса может оказаться, что существуют варианты перевода данного слова с помощью иных методов;

2. Калькирование – метод, при котором иноязычное слово заимствуется путем перевода его морфем или по смыслу. Примеры: antiparticle (античастица), heat exchanger (теплообменник). Данный метод также относительно прост в использовании, но только в тех случаях, когда переводимый термин имеет понятную словообразовательную структуру. Недостаток калькирования заключается в том, что данный метод в результате может исказить смысл переводимого слова или может вовсе неприменимым к некоторым терминам;

3. Семантический (описательный) перевод – метод, позволяющий максимально точно передать значение переводимого слова. Иноязычное слово или словосочетание заменяется на описательное словосочетание на русском языке, в полной мере раскрывающее значение оригинала. Примеры: heat-end (предварительный процесс обработки), monitor (контрольно-измерительное устройство).

Нередко трудности возникают при переводе английских аббревиатур. Некоторые из них имеют русский аналог: light-water-cooled, graphite-moderated reactor (LWGR) – реактор большой мощности канальный (РБМК), material unaccounted for (MUF) – количество неучтенного материала (КНМ). Но существуют и такие англоязычные аббревиатуры, которые получили широкое распространение в своем изначальном виде и не образовали аналога в русском языке: PWR (Pressurized Water Reactor) – реактор с водой под давлением, BWR (Boiling Water Reactor) – кипящий реактор. Перевод аббревиатур предполагает глубокие знания в области атомной энергетики и постоянное их совершенствование [1, С.11].

Перевод методом полного словарного соответствия – дословный перевод, наиболее полно описывающий переводимый термин, при котором слова или словосочетания переводятся на русский язык с полным сохранением структуры. Примеры: mass number (массовое число), special facility (специальная установка). Данный способ является наиболее простым в использовании, а также самым распространенным.

Переводчики, работающие в атомной промышленности, должны проходить курсы профессиональной подготовки, включающие в себя изучение основ ядерной физики, химии, инженерии и многих других дисциплин [2, С.93].

В рамках стратегии, разработанной Госкорпорацией «Росатом», для повышения качества переводов в 2018 году в АО «АТЭК» было принято решение активно развивать функции переводов. Создана база переводов объемом порядка 3 000 000 сегментов по различным направлениям: документации международных организаций, учебно-методические материалы, проектная и эксплуатационная документация [3, С.14].

Таким образом, перевод иностранной терминологии атомной промышленности требует особенной точности и достоверности. При переводе англоязычных терминов атомной промышленности на русский язык, у переводчика может возникнуть большое количество проблем, для решения которых он должен обладать не только глубокими лингвистическими знаниями, но и высоким уровнем владения профессиональным английским в области атомной энергетики, знаниями в области физики, химии, инженерии и других дисциплин. Так как научно-техническая терминология постоянно изменяется, переводчики обязаны регулярно расширять и проверять свои знания, проходить курсы дополнительной подготовки.

**Список литературы**

1. Алиев, А.Ш. использование профессиональной лексики на английском языке в сфере атомной энергетики / А.Ш. Алиев, Е.В. Дмитриева // Иностранный язык: традиции, опыт и инновации : Материалы II Международной научно-практической заочной конференции, Казань, 12 декабря 2024 года. – Казань: Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма, 2024. – С. 10-13.

2. Зорина О.С. Способы перевода английских терминов атомной энергетики на русский язык // Глобальный научный потенциал. – 2020. – №. 2. – С. 93-95.

3. Пегов С.В., Тененёва И.В. Лексические проблемы профессиональной межкультурной коммуникации (на примере атомно-энергетической отрасли) // Теория языка и межкультурная коммуникация. – 2017. – №. 4 (27). – С. 14-17.

# ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК УКЫТУДА КЫЗЫКСЫНДЫРУ ЧАРАЛАРЫ

***Хайруллина Л.А.***
*татар теле укытучы*
*“1нче мәктәбе”*
*Чистополь, Татарстан, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, информатизация белем бирү процессына сизелерлек йогынты ясый. Гадәти укыту технологияләре иҗади эзләнүгә тулысынча ачылырга бирми, ә хәзер илгә киләчәген алдан күргән, планлаштыра алган, тормышка ашыру юлларын ачык төсмерләгән шәхес кирәк. Укып алган диплом гына тормышта үз урыныңны табуга гарантия була алмый. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеген бөтенебез белә. Мәктәпләрдә шундый шәхес тәрбияләүгә – укучыга юнәлдерелгән- яңа педагогик технологияләр куллану ярдәм итә.

Ул белем бирү процессын үтемлерәк итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материални аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

Бүген дәүләтебез тарафыннан телне укыту һәм яклау буенча законнар кабул ителгән. Ул законнарны тормышка ашыру максатыннан министрлык тарафыннан мәктәпләр өчен уку планнары эшләнгән һәм ул уку планнарында дәүләт телләрен укыту дигән өлеш бар.

Икетеллелек шартларында информацион компьютер технологияләрен куллану татар телен, аның культурасын, татар халкының тарихын өйрәнүдә зур мөмкинлекләр ача,читтән торып экскурсияләрдә булу шартлары тудыра. Бу технологияне куллану укучыларда фән белән чынлап торып кызыксыну уята. Татар телен авыр үзләштерүче укучыларның да мондый дәресләрдә активлашуы күзгә күренеп арта.

Татар теле дәресләрендә дә компьютер технологияләрен максатка туры китереп, урынлы итеп кулланырга кирәк . Бу технологияләрнең телне өйрәнгәндә куллануның берничә функциясен атарга мөмкин:

- белем бирүнең чыганагы;
- мультимедиа һәм телекоммуникацияләр кулланып күрсәтмәлелекнең сыйфатын яңа биеклеккә күтәрү;
- тренажер;
- диагностика һәм тикшерү чарасы;
- текст редакторы буларак.

Информацион технологияләргә нигезләнеп, укучының дәрес материалын ни дәрәҗәдә үзләштерүен дә тестлар ярдәмендә тиз генә тикшереп була. Һәр укучы җавабының дөреслеген, түгеллеген белешмәгә куелган гиперссылка аркылы тикшерә ала, шулай ук ул класстан тыш чараларны үткәрүне дә кызыклы, нәтиҗәле итә.

Моннан берничә еллар элек уку – укыту процессында укытучының төп эш коралы булып такта белән акбур торса,хәзер инде хәл бөтенләй башкача.

Мин дәресләрдә укучыларны кызыксындыру, дәресне мавыктыргыч итеп үткәрү өчен компьютер куллануны бик отышлы дип саныйм.

Компьютер сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала. Аны куллану дәреснең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстен чыга. Менә шушы вакытта компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Презентацион программаларны төзегәндә, мин аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр кертәм.

Мин татар теле дәресен үткәргәндә бик еш интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта куллану дәресләрне тагы да мавыктыргыч, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Интерактив такта белән эшләгәндә мин һәрвакыт укучыларның игътибар үзәгендә, сыйныф белән элемтәдә торам.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә татар телен икеетеллелек шартларында укытуның төрле яңа ресурыслары бирелә. Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын бик күп табарга һәм аларны кабат-кабат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә ярдәм итә. Укучылар интерактив тактага бик тиз күнегәләр. Зур экран бергәләп эшләргә мөмкинлек бирә. Сыйныфта интерактив тактаның барлыкка килүе хәтта иң проблемалы укучыларга да укуга карата карашларын үзгәртергә этәргеч ясый. Соңгы парта артында утырган бала кинәт активлаша һәм иҗади фикер йөртә башлый.

Шулай итеп интерактив такта укучыларда эшләү активлыгын гына арттырып калмый, әяңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Шулай ук дәресләрдә Интернет ресурсларны куллану гаять зур мөмкинлекләр бирә. Интернет челтәре укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны җир шарының төрле ноктасыннан эзләп табу шартларын тудыра.

Татар теле дәресендә Интернет ярдәмендә уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебекдидактик бурычларны үтәргә мөмкин.

Укучылар Интернет челтәрендә үткәрелә торган тестларда, викториналарда, конкурсларда, олимпиадаларда катнаша, яшьтәшләре белән аралаша алалар.

Коммуникатив ситуация куеп без, укучыдан дәресләрдә актив катнашу сорыйбыз. Бу тормышчан вакыйга булып, аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт була ала:

- Проблемаларны актуальләштерү
- Кичереш һәм фикерләү шартлары
- Карарлар кабул итү,альтернатив нигездә үз гамәлләрен сайлау, өстәмә материал эзләү, аларны анализлау.

Коммуникатив технологияләр кулланып үткәрелгән дәресләр укучыларга телне аралашу чарасы, дөньяны һәм үзен танып белү, мәдәниятҗә өйрәнү, иҗади һәм актив, дөрес итеп аралашырга мөмкинлек бирә.

Татар теле һәм әдәбият бер-берсен тулыландырып тора. Шуңа күрә тел дәресләрендә матур әдәбиятны, халык авыз иҗатын киң кулланам. Мин үзем, татар теле дәресләрен үткәргәндә, әдәбият дәресләрендә укылган әсәрләргә тукталам. Кайбер вакытта татар теле һәм әдәбият дәресләрен берләштереп укыту да нәтиҗәле була. Бу төрдәге дәресләр укучыларның игътибарлылыгын, иҗадилыгын, фикерләү сәләтләрен үстерергә ярдәм итә. Яңача укыту технологиясенең нигезендә нәкъ шул – укучы һәм укытучы арасында яңача мөнәсәбәт тора. Укытучы укучыны үзе белән тигез шәхес итеп карарга тиеш. Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә шатлык – бәхет алып килергә, дәрестән бала ниндидер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Моны бары тик яңача фикерләүгә омтылган укытучы гына булдыра ала. Ул укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп кабул итә ала.

Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстенлек алган була. Менә шушы вакытта нәкъ компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Презентацион программаларны төзегәндә, укытучы аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр кертә.

Бүгенгесе көндә татар әдәбиятын проектлар методы кулланып укыту белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыра, укучыларны киләчәк тормышка әзерли, укыту нәтиҗәләре өчен җаваплылыкны арттыра, белем алуга кызыксыну уята. Шулай ук бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар, график программалар, электрон таблицалар ярдәмендә төрле гамәлләр иллюстрацияләр әзерләргә, гади программалар төзергә, электрон почта белән эшләргә, Интернеттан файдаланырга өйрәтә.

Сөйләм теле үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. Power Paint программасында төрле эффектлар кулланып, укыган әсәргә иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгырып, һәр укучыга бирергә була. Укучылар зур кызыксыну белән Х. Туфан, М. Җәлил, Г. Тукай, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Н. Гыйматдинова, С. Хәким иҗатлары буенча презентацияләр төзиләр.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Шулай итеп, әдәбият дәресләрендә заман технологияләрен файдалануның өстенлекле яклары бик күп: зур күләмдә мәгълүмат алырга, укучының шәхси сыйфатларын ачыкларга мөмкинлек бар; контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары. Димәк, заман технологияләрен куллану – балаларны кызыксындыру, аларда мөстәкыйльлек тәрбияләүнең, белем алуга теләк булдыруың бер юлы.
Яңа технологияләр ярдәмендә әдәбиятны өйрәнү укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлек тәрбияли. Заман технолог ияләрен куллану фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерергә, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясындагы яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

Белем бирү эшчәнлегемдә проблемалы укыту технологиясен еш кулланам. Укучылар белән берлектә проблемалы ситуациянең хәл итү юлларын

эзләү процессы, укучыларның иҗади эшчәнлеген арттыра. Проблема тудыруның түбәндәге алымнарын кулланам:

- текст яки диалог төзегәндә, ситуацияне конкретлаштыру;
- дөресләү, нигезләү максатыннан чыгып, сораулар кую;
- проблемалы максат, бурычлар кую, тел күренешләрен чагыштыру, проблемалы биремнәр билгеләү.

Барлык технологияләрнең нигезен коммуникатив технология тәшкил итә, чөнки кайсы гына технологияне куллансак та, аралашу мохите булдырмыйча, без аларны гамәлгә ашыра алмыйбыз.

Рус телле балаларның татар телен үзләштергәндә, беренче планга сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен дә бер-бер артлы формалаштыру һәм үстерү чыга. Димәк, рус телле балаларны, беренчедән, татар телен аңларга өйрәтергә, икенчедән, үзләренең фикерләрен татар теле чаралары белән белән әйтеп бирә белергә, өченчедән, башкаларның фикерләрен аңлап, язма һәм сөйләм формасында күрсәтә белергә тиешләр. Әйтеп киткән бурычларны укытуда коммуникатив принциплар кулланып кына максатка ирешеп була. Коммуникатив принцип телдән (тыңлап аңлау, сөйләү), язма (уку, язу), сөйләү формаларын бер-берсе белән тыгыз бәйли.

Телебезне өйрәнә башлауның мөһим баскычы – фонетика (авазлар системасын) үзләштерү. Һәр дәреснең оештыру өлешеннән соң фонетик күнегү үткәрелә. Дәүләт стандартының укучыларга татар теленең фонетик, лексик, грамматик нигезләре буенча гамәли белем бирү нәкъ менә шул этапта ачык күренә. Укучылар башта төшереп калдырган хәрефләрне куеп сүзләрне укыйлар, ул хәрефләрнең нинди аваз белдергәнен әйтәләр (калын, нечкә). Татар телендә сүзләр я калын гына, я нечкә генә булуларын кабат искә төшерәләр. Шул сүзләр белән җөмләләр төзиләр.

Дәреснең икенче этабында үз алдыма дәүләт белем бирү стандартының икенче пунктындагы максатын куям: балаларның телдән сөйләү күнекмәләрен үстерү; сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру.А.Алишның “Әни ялга киткәч” текстындагы малай турында беренче укучылар беренче затта сөйләгән булсалар, икенчеләре исә хәзерге заман хикәя фигыльне 3 затта, берлек санда әйтергә тиеш булалар. Текст буенча сораулар, диалоглар төзибез.

Яңа дәрестә укылачак текст балалар өчен таныш түгел, ләкин әзерлек эше алдагы дәрестә үткәрелгән була. Сөйләм эшчәнлеге бу этапта төрле. Татар сөйләмен тыңлап аңлау буенча укучыларда башлангыч күнекмәләр булдыру, эчтәлекне татарча яки русча сөйләтеп бирүне үземә максат итеп куям. Башта тәрҗемәсез генә текстны үзем укыйм. Аннан соң үзлектән укыйлар.

Аңлауларын тикшерү йөзеннән, тексттан кайбер җөмләләрне таптырып укытам. Найди в тексте предложения, где говорится : о сестренке, что у него не получалось, за что его похвалили. Аннан соң аралашуга бәйле репликаларыны кертү максатыннан, –мы-ме сорау кисәкчәләре һәм түгел юклык кисәкчәсен укучылар бер-берсе белән сөйләшкәндә кулланалар.Спроси у соседа по парте помогает ли он маме, как помогает?

Укучыларның иҗади активлыгын камилләштерүне күздә тотып, өйгә эшне иҗади характерда бирәм. “Ә минем әниемнең эше күпме?”- хикәя яз; рәсем яса; әниеңнән интервью ал.

Шәхесне үстерүгә юнәлтелгән технология түбәндәгеләрне күздә тота:

- укучының субъектив тәҗрибәсенә таяну;
- биремнәрне үтәгәндә укучыларның теләкләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алу;
- мөстәкыйльлек, активлык өчен шартлар тудыру.

6 сыйныфта (Р.З.Хәйдәрова дәреслеге) “Көндәлек нигә елый?” хикәясен укыгач укучылар субъектив тәҗрибәләренә таянып үз фикерләрен әйтәләр, тәкъдим иткән фикерләрен анализлыйлар. Алар көндәлекләрен бер-берсенә бирә.”Ә минем көндәлегем елыймы, көләме?”- соравына җавап көтә.Укучылар үзара аңлаша, бер-берсенә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыра. Сорауга җавап биргәндә , сукырларча буйсыну юкка чыга.Димәк, шәхесне үстерүгә юнәлтелгән технология дифференциаль якын килү алымы белән дә тыгыз бәйләнештә тора.

**Йомгаклау.** Укучылар – безнең киләчәгебез. Аларны бүгенге базар мөнәсәбәтләре шартларында көндәшлеккә сәләтле, олы максатларга ирешү юлында информацион технологияләрдән оста файдалана белүче иҗади шәхес итеп тәрбияләү – безнең төп бурычыбыз.

**Әдәбият исемлеге**

1. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – ТР “Хәтер” нәшрияты, 2001 ел.
2. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогик технологияләр:уку ярдәмлеге. – Мәгариф, 2008 – 366
3. Хуҗиәхҗәтов Ә.Н. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә. Казан. Мәгариф. 2001.
4. Интернет сайтлар. Электрон ресурслар.

# МАТЕМАТИКА ФӘНЕННӘН УКУЧЫЛАРНЫ ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЕНӘ ӨЙРӘТҮ

***Хамидуллина Р.М.***
*математика укытучы*
*“Иске Рәҗәп урта гомуми*
*белем бирү мәктәбенең”*
*Иске-Рязап, Татарстан, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, укучыларны фән дөньясына алып керү, кызыксындыру, аларны тикшеренү эшләренә җәлеп итү – заман таләбе. Математик белем бирү юнәлешендә генә эшләмәгән, гомуми мәктәп укучылары өчен бу аеруча мөһим. Ник дигәндә, математика фәне белән кызыксынучы балаларны арадан сайлап ала , аларны күрә белү дә әһәмиятле.

Ә укучыларны эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу бик зур мөмкинлекләр ача. Укучыларның математик билгеләр белән эшләү сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Математикадан фәнни эш белән кызыксындыру аеруча нәтиҗәле. Фәнни-эзләнү эшчәнлеге барышында алынган күнекмәләр укучыга башка фән нигезләрен үзләштерергә, бердәм дәүләт имтиханнарына, олимпиадаларга әзерләнгәндә зур ярдәм булачак.

Соңгы елларда республикада төрле дәрәҗәдәге күптөрле фәнни-гамәли конференцияләр, бәйгеләр еш үткәрелә. Сайлап алынган тема буенча бай мәгълүмат туплаган, тикшеренүләр үткәреп, нәтиҗәләр ясаган баланы андый бәйгедә катнаштыра алу бик уңай күренеш. Укучы үзе өйрәнгән проблеманың никадәр актуаль булуын дәлилли, үз фикерен белдерергә өйрәнә, публика алдында чыгыш ясый белү күнекмәләре дә камилләштерелә, иҗади сәләте үстерелә. Ә баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес буларак тәрбияләү безнең мөһим бурычыбыз булып тора.

Балаларның акыл үсеше, фикерләү дәрәҗәсе, психик һәм рухи дөньясы төрле-төрле, шуңа күрә һәр балага шәхси якын килеп эшләгәндә генә, аның үзенә генә хас булган үсеш дәрәҗәсе үзенчәлекләрен, табигый мөмкинлекләрен билгеләргә һәм сәләтен ачарга мөмкин.

Мәктәптә эшләү дәверендә мин шуңа инандым: һәр сыйныфта да сәләтле, кызыксынучан балалар була, бары тик аларны вакытында барлап, сәләтләрен тиешле юнәлештә үстерүне оештыра белергә генә кирәк.

Бигрәк тә зур сыйныф укучыларына кирәк мондый ярдәм.

Шушы максатны күздә тотып, мин 9 нчы сыйныфта укучы балаларны фәнни-тикшеренү эшенә тартырга уйладым.

Бу эшкә үзе теләк белдергән һәм татар әдәбияты белән кызыксынган, китап укырга яраткан балаларны гына тупладым. Шул рәвешле без бу эш белән шөгыльләнә башладык.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә фәнни оешма зур сыйныф укучыларын математикадан фән эшенә тарту, аларда бу эшкә карата кызыксыну, җаваплылык хисе тәрбияләү, иҗади сәләтләрен үстерү һәм фәнни-тикшеренү

эшенең төрле этапларында башкарыла торган эшләр белән таныштыру, реферат язарга өйрәтү турында сүз бара.

Укучылар, мәктәпне бетереп, югары уку йортларында укый башлагач, фәнни хезмәтләр – докладлар, курс эшләре, төрле проектлар, рефератлар яза башлыйлар. Бу өлкәдә аларга күп төрле чыганаклар белән эш итәргә туры киләчәк, ә мәктәптә укыганда ук бу эшкә өйрәтелгән укучы чыганакларны ничек эзләп табасын, алардан иң кирәкле мәгълүматларны ничек туплыйсын, аннан соң гомумиләштереп, нәтиҗәләрне ни рәвешле ясыйсын белә һәм, әлбәттә, аңа күпкә җиңелрәк булачак. Бу эшнең актуальлеге нәкъ менә шуннан гыйбәрәт.

Шулардан чыгып, фәнни оешма төп бурычларны билгели:

– фәнни хезмәтнең темасын сайлау, максат-бурычларын билгеләү;

– чыганаклар белән эшләү тәртибен аңлату;

– фәнни хезмәтнең кереш, төп һәм йомгаклау өлешләрен язарга өйрәтү;

– аны бәяләргә күнектерү: бәяләмәне кыскача гына тезислар ярдәмендә яза белү күнекмәләрен булдыру;

– фәнни хезмәткә презентация ясау һәм аны якларга өйрәтү.

Фәнни-тикшеренү эшенә керешкәнче, әзерлек эшләре алып барыла, аннан соң, фәнни-тикшеренү эшчәнлеге башлана.

Шундый бер эшемнең планын тәкъдим итәм.

Иң элек мин фәнни-тикшеренү эшен башкару юлларын, кайбер кыен якларын (мәсәлән, чыганакларны эзләп табу, туплау, системага салу), үз фикереңне ачык итеп аңлата белү һәм башка кешеләрнең (галимнәрнең) фикерен үзеңнеке итеп тәкъдим итүнең фән этикасы нормаларына каршы килүе турында төшендерәм.

Алга таба темалар тәкъдим ителә. Һәр теманың чыганаклар белән эшләү мөмкинлекләре, актуальлеге белән танышканнан соң, укучылар үзләренә ошаган теманы сайлап алалар.

Бу эшләрне йомгаклаганнан соң, укучыларны картотека, журнал төпләнмәләре белән эшләргә өйрәтәм. Теманы ачу өчен кирәк булган материалларны табабыз.

Аннан фәнни эшнең планы төзелә һәм материаллар белән танышу башлана.

Алга таба фәнни хезмәтнең кереш өлеше языла: актуальлек, төп максатлар, бурычлар билгеләнә; бу өлкәдә эшләгән галимнәр, аларның хезмәтләре күрсәтелә.

Шуннан соң картотека буенча табылган фәнни хезмәтләрне укып анализлау эше башкарыла. Укучылар тиешле урыннарны билгеләп баралар, аларның кайберләрен язып та алалар (болары аерым фикерләрне раслау һәм конкретлаштыру өчен кирәк булачак), нәтиҗәләр чыгаралар.

Һәр хезмәт шул рәвешле анализлана. Әлбәттә, моңа шактый вакыт кирәк була. Моннан соң һәр көн диярлек укучылар белән эш алып барыла, чөнки бу – озак, дәвамлы эш. Һәр укытучы аны үзе теләгәнчә билгели ала.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Шулай итеп, укылган фәнни хезмәтләр, үзебездә булган материаллар буенча эш башлана: һәр укучыга аерым биремнәр буенча

конкрет эшләр бирелә. Эш төрле юнәлештә бара, шуңа күрә укучылар белән очрашып, тиешле фикерләремне җиткерә барам

Укучылардан эшләгән эшләрен яза баруларын таләп итәм. Һәр атна саен мин биремнәрне тикшереп, киңәшләр бирәм, кайбер урыннарга төзәтмәләр кертергә дә кирәк була.

Математикадан фәнни хезмәт язган чорда бәхәсле мәсьәләләрне дә чишәргә туры килә. Теге яки бу фикер буенча каршылыклар да килеп чыккалый. Мондый ситуацияләр эшне тагын да кызыклырак итәләр. Укытучы фәнни хезмәтнең җитәкчесе буларак, даими рәвештә укучылар белән элемтәдә торырга һәм ярдәм итәргә тиеш.

Төп эшләр башкарылганнан соң, укучылар тупланган материалларны берләштереп, компьютерда җыялар. Шуннан соң да кат-кат тикшереп, аның бизәлешен (титул битенең язылышы, кулланылган әдәбият исемлеге һ.б.) җентекләп караганнан соң гына, эшне төгәлләнгән дип санап була.

Фәнни хезмәтне яклау, кайчакта, аны язуга караганда да кыенрак, диләр кайбер укучылар. Монда беркадәр дөреслек тә бар, әмма укытучы ярдәме белән алар бу эшне дә җиңел башкаралар. Әзер хезмәтнең кереш, төп һәм йомгаклау өлешләреннән төп фикерләрне кыска гына итеп язып алырга туры киләчәк, моны абзацларга бүлеп эшләгәндә тагын да җиңелрәк булачак икәнлеген аңлатам.

**Йомгаклау.** Гомумән, математикадан фәнни хезмәт язарга алынган укучы белән эшләгәндә укытучыдан төгәллек, осталык һәм, әлбәттә, эрудиция таләп ителә. Беркайчан да аның эшенә битарафлык күрсәтергә ярамый. Теманы кулына тоттырып, мә, яз, диеп кенә укучыны фәнни эш эшләргә өйрәтеп булмый. Укучыга вакытында ярдәм итеп, аны эшкә өйрәтсәк кенә, без фәнгә тартылган зыялы шәхес үстерүгә өлеш кертә алачакбыз.

**Әдәбият исемлеге**

1. Развитие исследовательской деятельности учащихся. Методический сборник. – М.: Народное образование, 2001. – 272 с.

2. Савина Н.Н. Организация исследовательской деятельности школьников. Программа курсов повышения квалификации учителей. – Елабуга: Изд-во ЕГПУ, 2008. – 38 с.

3. Лавриненко Т.А. Задания развивающего характера по математике. – Саратов: Лицей, 2002. – 247с

# МЕТОДЫ И ПРИЁМЫ РАЗВИТИЯ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ (ЧИТАТЕЛЬСКОЙ) ГРАМОТНОСТИ КАК ДОСТИЖЕНИЕ МЕТОПРЕДМЕТНЫХ РЕЗУЛЬТАТОВ ОБУЩАЮЩИХСЯ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО И АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА

***Хисамова Р.Р.***
*учитель татарского языка и литературы*
***Абзалилова Э.Ф.***
*учитель английского языка*
*МБОУ «Лицей-интернат»*
*Буинск, Татарстан, Россия*

**Актуальность**. В наш информационный век проблема чтения становится государственной. Исследования, проведенные в разных странах, показывают, что читатели значительно превосходят «нечитателей» в своем интеллектуальном развитии. Россия теряет статус самой читающей страны, в настоящее время наблюдается кризис российской культуры и литературы. Большинство людей пользуются книгами, нужными только для работы или учёбы. Находясь в круговороте мультимедийных информационных источников, которые не требуют серьезных раздумий, напряжений чувств, современные школьники вряд ли назовут чтение художественной литературы одним из любимых развлечений. Современному российскому обществу нужны эффективные граждане, которые могут максимально реализовать свои потенциальные возможности в трудовой и профессиональной деятельности, и тем самым принести пользу обществу, способсвовать развитию страны. Этим объясняется актуальность проблемы развития функциональной грамотности среди школьников.

**Методы исследования.** В данной работе были использованы методы функциональной грамотности. При помощи этих методов был проанализирован образование новых слов, включая заимствование, а также создание сложных и составных терминов на уроках татарского и английского языка. Функциональная грамотность сегодня – это базовое образование личности. Что же такое функциональная грамотность? Функциональная грамотность – уровень образованности, который характеризуется способностью решать стандартные жизненные задачи в различных сферах жизнедеятельности на основе преимущественно прикладных знаний. По определению А.А. Леонтьева, «Функционально грамотный человек -это человек, который способен использовать все постоянно приобретаемые в течение жизни знания, умения и навыки для решения максимально широкого диапазона жизненных задач в различных сферах человеческой деятельности, общения и социальных отношений».

Если мы говорим о формировании функциональной грамотности на уроках, то здесь важно понимать, что на уроках используем практико-ориентированные задания, используем определенные педагогические, методические приемы для того, чтобы сформировать умения школьников

применять эти знания, для решения каких-то проблем, даже самого простого плана. Но, чтобы сформулировать функциональную грамотность в системе, одних уроков для этого конечно мало.

Для успешного формирования функциональной грамотности школьников, достижения ключевых и предметных компетенций на уроках необходимо соблюдать следующие условия:

- обучение должно носить деятельностный характер;
- учащиеся должны стать активными участниками изучения нового материала;
- в урочной деятельности использовать продуктивные формы групповой работы.

Необходимо применять такие образовательные технологии, как:

- проблемно-диалогическая технология освоения новых знаний, позволяющая формировать организационные, интеллектуальные и другие умения, в том числе умение самостоятельно осуществлять деятельность учения;
- технология формирования типа правильной читательской деятельности, создающая условия для развития важнейших коммуникативных умений;
- технология проектной деятельности, обеспечивающая условия для формирования всех видов УУД;
- информационные и коммуникационные технологии, использование которых позволяет формировать основу таких важнейших интеллектуальных умений, как сравнение и обобщение, анализ и синтез;

**Результаты исследования.** Развитие функциональной грамотности требует от каждого учителя овладения методикой преподавания своего предмета, понимания, что законы татарского языка учащиеся воспринимают через призму законов русского языка, а это является причиной многих орфографических, пунктуационных и стилевых ошибок. Атак же у английского языка свои принципы. При организации работы в группах использовать можно одни и те же технологий. Использование различных методов и приёмов развития функциональной грамотности в процессе обучения способствует повышению интереса к языку, созданию необходимого эмоционального настроя на уроке, вовлечению учащихся в активную творческую деятельность, формированию интеллектуально развитой личности, развитию умения самостоятельно решать возникающие в реальной жизни проблемы. Во время проведения уроков татарского языка и литературы или английского языка к числу эффективных технологий можно отнести технологии работы в группах (пары, группы сменного состава и т.д.). Технология обучения в группах позволяет создавать на уроке определенные речевые ситуации, привлекать к организации работы в группе учащихся, которые хорошо владеют татарским языком, что способствует формированию коммуникативной компетенции школьников. Для уроков татарского языка и литературы и английского языка можно использовать проектные уроки, уроки-дебаты, дискуссии, деловые игры и т.д. Метод проектов позволяет развить функциональную грамотность:

- навыки аналитического мышления в процессе анализа информации, отбора необходимых материалов;

- ассоциативное мышление в процессе установления ассоциаций нового учебного материала с ранее изученным;

- логическое мышление, умение выстраивать логику доказательств, внутреннюю логику решаемой проблемы;

- умение рассматривать проблему в целостности связей и характеристик, опираться на ранее изученный материал.

Дискуссия в форме дебатов может быть эффективной в том случае, если обсуждается сложная или противоречивая проблема, мнения участников чётко определены и резко отличаются друг от друга. Цель дискуссии – научить учащихся спокойно, корректно высказывать мнения на лингвистическую тему, приводить аргументы с целью развития функциональной грамотности.

Расскажу о некоторых приёмах и методах, которые применяю на уроках в 5-11 классах для формирования функциональной грамотности учащихся.

Предлагаю обратиться к технологии развития критического мышления через чтение и письмо. Эта технология как нельзя лучше соответствует нашим целям.

Технология критического мышления позволяет решать следующие задачи:

- образовательной мотивации: повышения интереса к процессу обучения и активного восприятия учебного материала;
- культуры письма: формирования навыков написания текстов различных жанров;
- информационной грамотности: развития способности к самостоятельной аналитической и оценочной работе с информацией любой сложности;
- социальной компетентности: формирования коммуникативных навыков и ответственности за знание.

Основная идея технологии- создать такую атмосферу чтения, при которой учащиеся совместно с учителем активно работают, сознательно размышляют, отслеживают, подтверждают, опровергают или расширяют знания.

1. Прием "Инсерт"- чтение с пометками: ученикам дается текст (текст может быть научного или публицистического стиля речи). Читая, учащиеся ставят на полях значки:

- "?" – непонятно,
- "+"- согласен
- "-"-вызывает сомнение,
- "!" – это главное, это удивило...

Далее идет обсуждение прочитанного, на основе чего учитель формирует дальнейшую работу, например, углубиться в "непонятное" и вызвать детей на формулирование темы урока, объяснения нового материала или акцентировать внимание на том, что "вызывает сомнение" – это готовая проблемная ситуация, которая требует обсуждения (форма урока может быть диспут, дискуссия и.т.п.), или использовать фазу "это удивило" и дальше дать ряд упражнений на нужную вам тему

2. Прием – Кластер. «Кластер» – информация, касающаяся какого-либо понятия, явления, события, описанного в тексте, систематизируется в виде кластеров (гроздьев). В центре находится ключевое понятие. Последующие ассоциации обучающиеся логически связывают с ключевым понятием. В результате получается подобие опорного конспекта по изучаемой теме. Приём кластеров («гроздья») может применяться на стадии вызова для систематизации имеющейся информации. На стадии осмысления кластер позволяет фиксировать фрагменты новой информации. На стадии рефлексии понятия группируются и между ними устанавливаются логические связи.

В итоге получается структура, которая графически отображает наши размышления, определяет информационное поле данной теме.

3. Прием – Синквейн – применяются на стадии рефлексии, помогают обобщить изученный или прочитанный материал, сделать выводы

- 1 строка – Существительное – тема синквейна (объект)
- 2 строка – 2 прилагательных описывающие признаки и свойства объекта
- 3 строка – 3 глагола – действия, совершаемые объектом
- 4 строка – Предложение – отношение автора к объекту
- 5 строка – Синоним к первой строчке – суть объекта

4. Прием – Кроссенс. Слово «кроссенс» означает «пересечение смыслов», «крестосмыслица». Основной смысл создания кроссенса – это загадка, головоломка, ребус, задание, которое предназначено для определенной аудитории. В отличие от кроссворда, где все клеточки пусты, в кроссенсе они уже заполнены картинками. Учитель заранее готовит поле с картинками, расставляя их в определенной последовательности. Задача учеников – "разгадать" кроссенс, уловить ассоциативную цепочку и составить рассказ.

5. Прием – Лимерик.Лимерик состоит из пяти строк с рифменной схемой AABBA, причём финальные части первой и последней строк обычно одинаковы. Чаще всего лимерик написан анапестом (1-я, 2-я и 5-я строки– трёхстопным, 3-я и 4-я– двухстопным), требования к рифме достаточно строги. Композиция лимерика подчиняется строгим правилам:

- в первой строке называется литературный персонаж и место его происхождения;
- во второй повествуется о том, что этот персонаж сделал, что с ним случилось или какова его особенность;
- дальнейшее изложение рассказывает о последствиях его действий или свойств.

**Заключение.** При использовании на уроках татарского и английского языка указанных форм и методов работы у обучающихся формируются навыки мышления и рефлексии, которые являются важными составляющими понятия «функциональная (читательская) грамотность». В заключении хочу отметить, что эффективность данной работы зависеть прежде всего от педагога, задача которого, выступая организатором учебной деятельности, стать заинтересованным и интересным соучастником этого процесса.

Таким образом, деятельность, направленная на воспитание функциональной грамотности школьников, может быть проведена в разных формах. Эти мероприятия способствуют формированию у обучающихся общих, и в то же время достаточно цельных представлений о процессах, связанных с экономикой, бизнесом, ресурсами и их разумным потреблением, формированию успешной личности каждого ученика.

**Список литературы**

1. Козлова, М.И. Повышение функциональной грамотности как необходимость современного образования / М.И. Козлова // Сборник статей II Международного учебно-исследовательского конкурса. – Петрозаводск, 2020. – с. 116-125.
2. Развитие критического мышления на уроке: пособие для учителей общеобразоват.учреждений / С.И. Заир-Бек, И.В. Муштавинская.-2-е изд.дораб. – М.: Просвещение, 2019.
3. Развитие функциональной грамотности обучающихся начальной школы: методическое пособие для педагогов / Под общей редакцией Л.Ю. Панариной, И.В. Сорокиной, О.А. Смагиной, Е.А. Зайцевой. – Самара: СИПКРО, 2019.
4. Г.А. Цукерман, Г.С. Ковалева, М.И. Кузнецова. Хорошо ли читают российские школьники? // Вопросы образования. № 4, 2007, с. 245.
5. https://web.telegram.org/k/#@funkgram2022

# РУС МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Хуснуллина З.М.***
*ф.ф.к., татар теле укытучы*
*Казан мәгълүмат технологияләр*
*һәм элемтә техникумының*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, мәктәпләрдә башка милләт укучыларының татар телен өйрәтү сәләтен үстерү мәсьәләсе зур әһәмияткә ия. Ә моның өчен тиешле шартлар булдыру- укытучының мөһим бурычы.Бүгенге җиһан катлаулы, тиз үзгәрүчән. Шуның белән бәйле рәвештә мәгарифнең дә яңа шартларда яшәргә сәләтле кеше тәрбияләүдәге җаваплылыгы арта бара. Социаль-тарихи һәм мәдәни процессның шундый субъекты булып һәрьяктан камил, рухи яктан үскән шәхес тора. Ул шул мохиттә яшәргә сәләтле булу белән бергә анда актив эшләү күнекмәләренә дә ия булырга тиеш. Хәзерге шартларда «мәгариф» дигән төшенчә үзе дә үзгәрә башлады. Ул элегрәк мәктәптә укыту процессы белән генә тиңләштерелсә, хәзер киңрәк мәгънә ала бара. Хәзер безнең илдә мәгариф тирәлегенә юнәлтелгән яңа мәгариф системасы урнаша бара. Бу эш педагогик фәнгә һәм укыту-тәрбия процессына сизелерлек үзгәрешләр кертә. Белем эчтәлеге яңа күнекмәләр белән баетыла, мәгълүмат белән эш итү сәләте үстерелә, белем бирү программалары индивидуальләштерүгә юнәлтелеп, фән һәм икътисад үсеше проблемалары хәл ителә. Укытучының укучылар белән шәхси юнәлешле аралашуы – педагогик процессның мөһим состав өлеше булып тора. Шәхесне рухи яктан тәрбияләүгә, кешенең әхлакый йөзен формалаштыруга зур әһәмият бирелә.

Телгә өйрәнү – ул тел турында кагыйдәләр өйрәнү генә түгел. Телгә өйрәтү – сөйләм эшчәнлегенең һәрбер төренә – сөйләшергә, тыңлап аңларга, укырга, язарга өйрәтүне күз алдында тотарга тиеш.

Болай укыту заманча укыту процессына куелган төп таләпләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә: укытучы аралашуны оештыручы көч буларак эшли; дәрестә аралашу процессына якын торган күнегүләр файдаланыла; грамматик форма һәм аның сөйләмдәге функцияләрен өйрәтү янәшә алып барыла: проблемалы бурычлар куелып, алар хәл ителә; күмәк эш формалары кулланыла; укытучы белән укучы арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнаша; шәхеснең үзенчәлекләрен истә тотып эшләү аның эчке резервларын активлаштыра һәм укыту эшчәнлегенең нәтиҗәле булуын билгели [1, Б 43].

Телгә өйрәтүнең эчтәлегенә тел материалы белән эшләү кагыйдәләрен белү дә керә. Димәк, күпмедер күләмдә телдәге кагыйдәләрне белү дә кирәк. Ләкин кагыйдәләр өйрәнеп кенә телне белеп, сөйләшергә өйрәнеп булмый. Телгә өйрәнүнең төп максаты – алган белемнәр нигезендә сөйләм күнекмәләре формалаштыру.

Сөйләм күнекмәләренә ия булганда тел аңлы рәвештә кулланыла. Тиз җавап биргәндә, сөйләм тотрыклы булганда, аңлы рәвештә эшләгәндә, ситуация үзгәреп күнекмә үзгәртелә алганда, күнекмәләр формалашкан дип санала ала.

Күнекмәләр һәм алган белемне файдалану нигезендә телне белү барлыкка килә. Телне белгәндә генә, коммуникатив максатлары хәл ителә: сөйләшә, тыңлап аңлый, укый һәм яза ала торган кешене “телне белүче” дип әйтәләр.

Рус телендә сөйләшүче баланы татар теле белән кызыксындыру өчен, укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүе, аның иҗади эшләү күнекмәләренә ия булуы таләп ителә. Эш барышында татар теленең матурлыгын күрә, тоя белүе, укучы алган белемнең даими рәвештә тулылана, байый баруы, әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнүе укытучының игътибар үзәгендә булырга тиеш [3, Б 67].

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә рус телле балаларга татар телен укыту вакытында бәйләнешле сөйләм үстерү чаралары киң кулланыла. Әдәбият дәресләрендә рус балаларын татар телендә бәйләнешле итеп сөйләргә, үз фикерләрен эзлекле итеп әйтеп бирергә өйрәтүне максат итеп куям. Шушы юнәлештә алып барылган эшемне билгеле бер предмет турында, тәкъдим ителгән тема буенча тәмамланган бер фикерне әйтергә өйрәтүдән башлыйм. Аның өчен, билгеле, укучыларның сүз байлыгы булырга тиеш. Шуңа күрә һәр дәрестә шушы мәсьәләгә һәм тәрҗемә эшләренә дә зур урын бирәм. Чөнки рус теленнән татар теленә дөрес итеп тәрҗемә итү бәйләнешле сөйләмнең барлык формаларына ия булуны сорый.

Гомумән, татар телен аралашу чарасы буларак өйрәткәндә, укучыларның диалогик сөйләмен табигый сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү максатын куям. Шушы максатка ирешкән очракта гына өйрәнелгән сөйләм күнекмәләрен гамәли кулланырга мөмкин дип саныйм.

Бүгенге көндә “Үзенең дәресләрен ничек кызыклы, мавыктыргыч итеп, ничек укучыларны үз дәресең белән кзыксындыру, ничек итеп һәр укучыга уңыш ситуациясе булдыру” турында уйланмаган бер генә укытучы да юктыр. Һәм бу очраклы гына уйланулар түгел. Чөнки бүгенге укытуның төп максаты булып – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Рус телле балаларга татар телен укытуда шәхескә якын килү технологияләрен кулланып эшләгәндә куелган максатка ирешеп була. Аның асылы – укучы шәхесенә хөрмәт белән карау, аның ирекен чикләмәү, укытуның укытучы күрсәтмәләренә сукырларча буйсынудан ераклашу. Аның урынына үзара аңлашу, ихтирамлылык мөнәсәбәте, укытучы белән укучының демократик, гуманлы, эзләнүчән һәм иҗади эш стилен булдыру; информацияне аңлы рәвештә кабул итәргә әзер булган, табигый сәләтен уңышлы файдалана белгән, төрле тормыш шартларында кулланырлык тәҗрибәгә ия шәхес тәрбияләү.

Шәхескә юнәлтелгән технологиянең төп принциплары – ул укучының уйлану һәм иҗат итү сәләтен үстерү. Иҗат эшчәнлегендә бала үзенең нәрсәгә сәләтле икәнлеген сизә, аңарда үзенә карата уңай караш тәрбияләнә. Шул

максаттан дәресләремдә төрле ситуацияләр бирү, алардан чыгу юлларын эзләү, укыган әсәрләрдә кемнең хаклы яки хаклы булмавын ачыклау, аларга киңәшләр бирү, бу мәсьәләгә үз фикерләрен белдерү кебек алымнарны еш кулланам. Укучыларга бигрәк тә татар халык мәкальләре нигезендә кечкенә ситуатив хикәяләр уйлап язу бик ошый.

**Йомгаклау.** Гомумән, фәннәрне укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Йомгак лап шуны әйтергә кирәк, әгәр укытучы дәресләрендә күрсәтмәлекне җитәрлек дәрәҗәдә кулланса, төрле уен ситуацияләре, сөйләм күнегүләре, коммуникатив һәм инновацион технологияләрне дөрес файдалана алса, ул, һичшиксез, эшендә уңышка ирешәчәк.

**Әдәбият исемлеге**

1. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. – Казан: Мәгариф, 1998. – 151 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2001. – 432 б.

3. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татарский язык. Интенсивный курс. – Казан: Хәтер, 1999. – 231 б.

4. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 272 б.

# ОСОБЕННОСТИ ПЕРЕВОДА ЮРИДИЧЕСКИХ ДОКУМЕНТОВ: КОНТРАКТЫ, СОГЛАШЕНИЯ, ДОВЕРЕННОСТИ

***Хуснутдинов Р.Р.***
*студент*
***Демидкина Д.А.***
*к.филол.н.*
*Казанский государственный энергетический университет*
*Казань, Россия*

**Актуальность.** Перевод юридических документов относится к высокорискованным видам переводческой деятельности, где каждое слово может иметь правовые последствия. Ошибки приводят не только к недопониманию, но и к финансовым потерям, отказу в регистрации документов, судебным спорам или признанию сделки недействительной. В условиях активного трансграничного взаимодействия и удалённого документооборота растёт потребность в переводах контрактов, соглашений и доверенностей, которые должны соответствовать нормам применимого права, требованиям к форме и терминологической точности, а также учитывать традиции деловой переписки и судебной практики в соответствующей юрисдикции.

**Методы исследования.** Использованы методы сравнительного правового и лингвистического анализа, изучение аутентичных двуязычных образцов документов, практики нотариального удостоверения и легализации, а также типовых требований к оформлению. Опора делается на нормативные документы по транслитерации, правила оформления реквизитов, источники по теории перевода и корпоративные глоссарии.

**Результаты исследования.** Результаты представлены в виде систематизированных рекомендаций по переводу юридических документов трёх ключевых типов – контрактов, соглашений и доверенностей – с детальной проработкой терминологии, структуры, реквизитов и процедурного сопровождения. Ниже приведены основные выводы и практические инструкции для переводчика-практика.

**1. Общие принципы перевода юридических текстов.** Юридический стиль характеризуется точностью, однозначностью и формально-логической связностью. Переводчик обязан: (а) сохранять структуру и нумерацию разделов/пунктов; (б) поддерживать единообразие терминов в пределах документа; (в) избегать толковательных перефраз и разговорных оборотов; (г) корректно передавать модальность («shall», «must», «may») и условные конструкции. Особое внимание уделяется разделу определений (Definitions) – каждый определённый термин должен переводиться неизменно и выделяться так же, как в оригинале. Внутренние ссылки («см. раздел 5.2») необходимо проверять после завершения перевода, чтобы исключить «битые» кросс-референсы.

**2. Контракты (договоры).** Критично сохранять: предмет, цену/вознаграждение, порядок расчётов, сроки, гарантии и ответственность,

условия расторжения, применимое право, подсудность/арбитраж, конфиденциальность и права ИС. Формулы обязательности («обязан(а)», «подлежит», «вправе») подбираются по функции: «shall» – «обязан(а)/подлежит», «may» – «вправе», «will» – для декларативных положений. Определения должны предшествовать употреблению; сокращения – выноситься в начало или приложение. В двуязычных договорах фиксируйте приоритет языка и соблюдайте единообразие терминов. Единицы, валюты и округления – строго по оригиналу; цифровые значения перепроверяйте.

**3. Соглашения (NDA, MoU, допсоглашения).** В NDA важны определения конфиденциальной информации, исключения, срок обязательств и режим возврата/уничтожения материалов. Отличайте «раскрытие», «предоставление доступа», «использование», «передачу». Меморандумы о взаимопонимании могут не создавать юридически обязывающих обязательств – мягкие формулировки должны сохраняться. В допсоглашениях корректно передавайте ссылки на изменяемые пункты, даты вступления в силу и условие о неизменности прочих положений.

**4. Доверенности.** Обязательны реквизиты доверителя и доверенного лица, объём полномочий, срок, место, подпись и, при необходимости, нотариальное удостоверение/апостиль. Сохраняйте перечень полномочий списком, используйте инфинитивы («подписывать», «подавать», «получать»). Транслитерацию персональных данных ведите по правилам, указанным в документе; несоответствия могут привести к отказу в регистрационных действиях. Печати/штампы описывайте скобками («[печать]», «[штамп]»), переводя содержательную часть.

**5. Терминология и стилистика.** «Consideration» – «встречное предоставление», «severability» – «делимость соглашения», «best efforts» – «все возможные усилия» (vs «разумные усилия»). Избегайте ложных друзей переводчика («actual» – «фактический», «entity» – «организация/юридическое лицо»). Минимизируйте канцеляризмы, используйте простые конструкции без потери правового смысла.

**6. Структура и кросс-ссылки.** Сохраняйте многоуровневую структуру и форматирование заголовков. Кросс-ссылки проверяйте после финальной вычитки. Приложения именуйте последовательно; ссылки на них унифицируйте.

**7. Двуязычные тексты и приоритет языка.** Закрепляйте приоритет одной версии (часто – английской). Формулировка должна быть однозначной и размещаться в разделе «Прочие условия» или в преамбуле.

**8. Имена собственные, адреса, номера.** Имена – по документам; адреса – в формате страны назначения; регистрационные номера – транслитерируются, с пояснением при первом упоминании. Даты приводите в несомненном формате (например, «2025-03-15»).

**9. Заверение, легализация, апостиль.** Точность подтверждается подписью переводчика/штампом бюро или нотариальным удостоверением – по требованиям адресата. Для зарубежного использования может потребоваться апостиль (Гаагская конвенция 1961 г.) или консульская легализация. Формулы

нотариального удостоверения переводите полностью; реквизиты нотариуса передавайте строго по документу.

**Заключение.** Качество перевода юридических документов опирается на терминологическую точность, сохранение структуры и модальности, корректную передачу реквизитов и соблюдение процедур заверения и легализации. Системный подход с глоссарием и двойной вычиткой позволяет снижать правовые риски и повышать доверие к переводам в деловой практике.

**Список литературы**

1. Гражданский кодекс Российской Федерации. Части первая–четвёртая. – Текст: непосредственный.

2. Комиссаров В.Н. Теория перевода (лингвистические аспекты). – М.: Высшая школа, 1990. – 253 с.

3. ГОСТ 7.79–2000 (ИСО 9:1995). Правила русской транслитерации латиницей. – Текст: нормативный.

4. Швейцер А.Д. Современная переводческая теория. – М.: Наука, 1988. – 215 с.

5. Redfern & Hunter on International Arbitration. – Oxford University Press, 2015. – 800 p.

# ОСОБЕННОСТИ СТИЛИСТИКИ ТЕХНИЧЕСКИХ ИНСТРУКЦИЙ И СПЕЦИФИКА ИХ ПЕРЕВОДА

***Чудакова А.М.***
*студент*
***Демидкина Д.А.***
*к.филол.н., доцент*
*Казанский государственный энергетический университет*
*Казань, Россия*

**Актуальность.** Технические инструкции являются важным элементом коммуникации в профессиональной среде инженеров, техников и пользователей различного оборудования. Они служат источником подробной информации о правилах эксплуатации, мерах предосторожности и особенностях обслуживания устройств. Неправильное толкование или некорректный перевод таких инструкций может привести к ошибкам в работе оборудования, финансовым потерям и даже угрозе здоровью персонала. Именно поэтому важность правильного и точного перевода технических инструкций нельзя недооценивать.

Статья посвящена исследованию специфики стилистики технических инструкций и особенностям их перевода на русский язык. Особое внимание уделяется вопросам сохранения точности и ясности изложения при передаче информации на иностранный язык. Рассматриваются характерные черты структурирования и лексического наполнения таких документов, а также факторы, влияющие на качество и адекватность их перевода.

Разберем значение слова «перевод» в том смысле, что имеется определенный результат в виде получения текста в варианте языка, отличного от оригинального. Важность верного понимания данного понятия обусловлена спецификой переводческой деятельности, где переводчик выступает посредником между различными культурами и языками. Правильно понятое определение перевода обеспечивает правильное восприятие результатов труда переводчика и облегчает оценку качества выполненных переводов.

То есть, обозначение самого переведенного текста (например, в предложениях: «Это – очень хороший перевод романа Диккенса», «Недавно вышел в свет новый перевод поэмы Байрона «Паломничество Чайльд Гарольда» на русский язык», «Он читал этого автора в переводе» и т.п.) [1, С. 192].

Перевод технических инструкций представляет собой сложную задачу, поскольку требует от специалиста владения специальным языком, глубокого знания предмета описания и способности передавать информацию точно и ясно. Основная трудность заключается в необходимости соответствовать международным стандартам, обеспечивать правильность использования терминов и сохранять единый стиль изложения материала. Нарушение любого из этих условий может повлечь серьезные последствия, вплоть до аварийных ситуаций.

В отличие от художественных произведений или публицистических текстов, технический документ отличается особой точностью формулировок,

четкостью структуры и лаконичностью изложения. Любое отклонение от установленных правил может вызвать недопонимание или затруднить выполнение предписанных действий.

Стилистика технических инструкций определяется несколькими факторами: необходимостью обеспечить однозначное понимание содержания, минимизацию вероятности ошибок при эксплуатации оборудования и соблюдение норм международного стандарта оформления подобной документации. Требования к оформлению инструкций различаются в зависимости от отрасли промышленности и типа оборудования, что усложняет работу переводчиков и авторов оригинальных текстов.

Эти требования накладывают отпечаток на структуру документа, выбор терминологии и синтаксиса предложений. Особенно важны стандартизация формата, последовательность изложения, использование единой терминологической базы и единообразие обозначений.

**Методы исследования.** Для изучения стилистики технических инструкций обратимся к варианту анализа текста путем выполнения определенных задач, чтобы более емко понять смысл написанного. Использование специально разработанных методик позволяет глубже проникнуть в суть текста и выявлять скрытые закономерности и особенности, которые трудно заметить при поверхностном прочтении.

К примеру:

- восстановление пропущенных элементов предложения;
- замена выделенных словоформ в предлагаемых предложениях синонимами, подобранными из анализируемого текста;
- упрощение текста до минимального количества предложений.
- перевод предложений с родного языка на русский с использованием специализированной лексики [4, С. 394].

Использование подобных техник помогает лучше разобраться в структуре и содержании текста, выявить типичные ошибки и разработать рекомендации по улучшению качества перевода.

**Результаты исследования.** Основные трудности при переводе технических инструкций связаны с межкультурными различиями в восприятии информации, особенностями национального менталитета и уровнем детализации представления сведений. Изучение конкретных случаев показывает, насколько сильно влияние культурных факторов на понимание и обработку технической информации.

Рассмотрим некоторые ключевые моменты подробнее.

Одна из главных проблем заключается в отсутствии точного соответствия между техническими терминами разных языков. Различия в структурах языков и разные подходы к формированию научной терминологии создают дополнительные препятствия для эффективного перевода. Даже опытные специалисты сталкиваются с трудностями, когда речь идет о сложных технических устройствах или инновационных технологиях.

Это особенно актуально для новых областей науки и техники, где международное сообщество ещё не выработало общепринятых стандартов

терминологии. Решением данной проблемы может стать регулярное обновление глоссариев и сотрудничество переводчиков с инженерами и специалистами соответствующих отраслей.

Для решения данной проблемы рекомендуется применять методы сопоставительного анализа и создавать глоссарии специальной лексики [3, С.4], что позволит повысить точность и согласованность перевода.

Ещё одной проблемой является необходимость точной передачи смысла исходного текста. Многозначность слов и разнообразие возможных вариантов перевода приводят к возникновению трудностей в понимании исходного материала. Многие языки отличаются способами построения высказываний, что влияет на форму подачи информации. Например, английские инструкции часто используют повелительное наклонение («turn on the switch»), тогда как русские предпочитают инфинитивные конструкции («включите выключатель») [2, С. 78,79]. Понимание этих тонкостей позволяет избежать двусмысленности и обеспечить точность перевода.

Важно учитывать эти различия при переводе, сохраняя изначальное значение и стиль оригинала. Правильный подбор лингвистических средств гарантирует, что переведенный текст будет легко восприниматься целевым аудиторией и не приведет к путанице или неправильному применению.

Таблицы и рисунки представляют особый интерес при переводе. Хотя сами визуализации обычно имеют универсальный характер, важно правильно интерпретировать надписи и подписи, чтобы исключить любые сомнения относительно значения символов и показателей. Локализация иллюстраций включает адаптацию единиц измерения, перевод подписей и легенд, а также учет местных предпочтений в оформлении схем и чертежей.

Несмотря на универсальность форматов отображения данных, важно соблюдать правила локализации изображений, адаптировать единицы измерения и обозначения к требованиям принимающей культуры. Например, стилевые особенности китайских научных текстов подчеркивают важность научно обоснованных выводов и тщательного подбора терминологии [5, С.69].

**Заключение (выводы).** Таким образом, изучение стилистики технических инструкций и решение вопросов их качественного перевода требуют комплексного подхода, учитывающего как языковые, так и культурные аспекты взаимодействия между автором и читателями. Качество перевода оказывает непосредственное влияние на безопасность и надежность работы оборудования, а потому должно находиться под пристальным вниманием специалистов и организаций.

Профессиональному переводчику необходимо владеть методами обработки специального текста, понимать назначение каждого элемента структуры документа и иметь чёткое представление о назначении перевода. Только сочетание теоретических знаний и практических навыков способно гарантировать высокое качество перевода технических инструкций и снижение риска возникновения негативных последствий вследствие неправильного понимания.

**Список литературы**

1. Бархударов, Л.С. Язык и перевод (Вопросы общей и частной теории перевода). – Москва: Междунар. отношения, 1975. – 240 с.

2. Верещагин, Е.М. Язык и культура : Лингвострановедение в преподавании русского языка как иностранного / Е.М. Верещагин, В.Г. Костомаров; Редактор Г.Г. Яроцкая, Художественный редактор Л.А. Бабаджанян, Технические редакторы В.А. Павлова, С.С. Якушкина, Корректор С.А. Никольская. – 2-е издание, переработанное и дополненное. – Москва : Русский язык, 1976. – 248 с. – EDN JYAPNN

3. Гринев, С.В. Сопоставительное терминоведение: современное состояние / С.В. Гринев // Вестник МГПУ. Серия: Филология. Теория языка. Языковое образование. – 2017. – № 1(25). – С. 68-75. – EDN YJGTJH

4. Маркарян, К.А. Особенности и средства анализа технического текста / К.А. Маркарян // Язык и культура (Новосибирск). – 2013. – № 8. – С. 77-81. – EDN REFCVZ

5. Син, Ю. Стилевые и грамматические особенности научного стиля в современном китайском языке / Ю. Син // Гуманитарные, социально-экономические и общественные науки. – 2014. – № 9. – С. 392-397. – EDN SQSBSD

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КУШМА СҮЗЛӘР ЯСАЛЫШЫ

***Чукурова Л.И.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*“124 нче мәктәбе”*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге** сыйфат ясалышын өйрәнүдә кайбер мәсьәләләрнең, башлыча *сыман, төсле* бәйлекләре белән, сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчү ысулы белән сыйфат ясалышына бәйле фикер каршылыклары булу, бу төр лексик берәмлекләрнең сүзлекләрдә теркәлеше чикләнгәнлек һәм кушма сыйфатларның орфографиясе проблемалары белән билгеләндә. Сүз ясалышы бүлеге, татар тел гыйлеменең мөстәкыйль бер тармагы буларак формалашып, аерым фән итеп өйрәнелә башлаганнан соң, бу өлкәгә караган тикшеренүләр бермә- бер артты. Аеруча татар теле, гомумән төрки телләр өчен шактый катлаулы һәм каршылыклы булган кушма сүзләр (саф, кушма, тезмә, парлы) ясалышы галимнәрнең игътибар үзәгендә. Татар теле белемендә кушма сүзләр ясалышын, беренчеләрдән булып, шактый тирәнтен Г. Алпаров яктырта. В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева, Ф.М. Хисамова кебек галимнәребезнең хезмәтләрендә дә бу мәсьәләгә зур урын бирелә. Монграфик планда бу өлкә, күренекле галим- морфолог, үзенең фәнни эшчәнлеге белән татар теле сүз ясалышы бүлеген мөстәкыйль фән дәрәҗәсенә күтәргән Ф.Ә. Ганиев тарафыннан өйрәнелә.

Кушма сүзләр ясалышы күпчелек академик һәм гамәли грамматикаларда, традицион рәвештә, синтаксик ысул дип бирелә. Ф.Ә. Ганиев беренче тапкыр бу ысулга бәйле кушма сүзләр ясалышында өч юл барлыгын күрсәтә: сүзләр (нигезләр) кушылу, сүзтезмә лексикалашу, сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчүе.

Безнең эшебез татар телендә кушма (саф кушма, тезмә, парлы) сыйфатлар, аерым алып сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчү юлы белән сыйфат ясалышын тикшерүгә багышлана.

**Тикшерү ысуллары.** Әлеге эштә татар телендә синтаксик
(сүз кушу) ысулы белән сыйфат ясалышы тора.

Сүз ясалышы турындагы өйрәтмә озак вакытлар морфология эчендә карала килде, чөнки ул грамматиканың аерым бер бүлеге булып аерылып чыгарлык дәрәҗәдә үсмәгән иде әле. Аның мөстәкыйль тармак булып китүенә алшартлар күптән туса да, ул XX гасырның 80 елларында гына грамматиканың аерым бер бүлеге булып формалашып җитә. Хәзерге вакытта сүз ясалышы татар тел белеменең үзенә генә хас өйрәнү объекты һәм өйрәнү предметы, максат бурычлары булган мөстәкыйль тармагы булып тора.

Татар телендә”сүз ясалышы” термины ике мәгънәдә кулланыла:

1) телнең үз чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы, ягъни махсус сүз ясалыш процессы;

2) яңа сүзләрнең һәм типларның ясалыш закончалыкларын һәм ясалыш ысулларын өйрәнә торган лингвистик дисциплина.

Телнең сүзлек составын баетуда төр чара буларак, барлык сүз ясалыш ысулларын бер системада һәм бай фактик материал җирлегендә җентекләп өйрәнү телнең байлыгын һәм аның үсеш мөмкинлекләрен ачыклауда сүз ясалышы фәне мөһим юнәлеш булып тора.

Күренекле галим – морфолог Ганиев Ф.Ә [1, с 26] фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар теле сүз ясалышы татар теле гыйлеменең мөстәкыйль бер тармагы дәрәҗәсендә үсеп формалашты. Сүз ясалышы үзенең күп яклары белән тел белеменең лексикология, грамматика һәм башка тармаклар белән тыгыз бәйләнгән булуына карамастан, анда һәм грамматикага, һәм лексикологиягә хас булмаган үзенчәлекләр шактый. Сүз ясалыш процессларын грамматик күренешләргә генә кайтарып калдыру мөмкин түгел, чөнки лексик-семантик һәм фонетик ысуллар белән сүз ясалышы бөтенләй грамматикага карамыйлар.

Татар теленең сүзләре ясалу- ясалмавы ягыннан ике зур төркемгә: 1) ясалма булмаган (тамыр, тамырлашкан, алынма); 2) ясалма (татар теленә хас

булган барлык төр сүз ясалыш ысулларына нигезләнеп ясалган сүзләр) сүзләргә аерып өйрәнелә.

Структур, ягъни составы ягыннан татар сүзләре синтетик (гади),аналитик (кушма) һәм кыскартылма төрләргә бүленә [1, с 40].

Кушма сүз (композит) термины барлык төр аналитик сүзләрне атау өчен кулланыла. Шуңа бәйле кушма сүзләр үз эчендә 1) саф кушма; 2) тезмә;

3) парлы сүзләргә аерыла.

Татар теленең академик грамматикасында кушма (аналитик) сүзгә түбәндәгечә билгеләмә бирелә: икедән дә ким булмаган тулы мәгънәле мөстәкыйль морфемалардан яки берсе тулы мәгънәле, икенчесе тулы мәгънәле булмаган сүздән гыйбарәт сүзләр аналитик сүзләр дип атала, аларны икенче төрле кушма сүзләр дип тә йөртәләр [1, с 134].

Кушма сүзләр, ягъни композиторлар, татар телендә, гомумән тюркологиядә,галимнәрнең зур игътибар үзәгендә. Бу өлкәгә караган фәнни тикшеренү нәтиҗәләре булган күп сандагы хезмәтләрнең дөнья күрүенә карамастан, хәл ителеп бетмәгән проблемалар кала бирә: 1) кушма сүзгә (композитка) билгеләмә бирү; 2) кушма сүзләрне классификацияләү; 3) кушма сүзләрнең ясалу ысулларын билгеләү; 4) кушма сүзләрне диахроник (тарихи) һәм синхроник (тасвирлама) планда тикшерү; 5) кушма сүзләр орфографиясе һ.б.

Татар телендә, гомумән тюркологиядә, кушма сүзгә билгеләмә бирү мәсьәләсенә зур игътибар бирелә.

Күренекле тел белгече Гыйбад Алпаров татар телендә кушма сүзләрне тикшерүгә зур урын бирә. Үзенең “ Татар телендә кушма төрләр” дип исемләнгән мәкаләсендә галим аларга билгеләмә бирү, аларның төзелү максатларын, мәгънәви яктан нинди элементлар кушылып ясауларына, үзара – бер-серенә бәйләнү рәвешләренә карап, әйтелешләре һәм басым интонациясе ягыннан төрләргә аера.

Шунысы кызыклы, алга таба кушма сүзләр ясалышына бәйле хезмәтләрдә урын алган мондый төр сүзләргә хас барлык төр сүзләргә хас барлык төр классификацион билгеләр Г.Алпаров хезмәтенә нигезләнеп башкарыла [1,с 34].

“Башта ук шуны әйтеп китәргә кирәк:”кушма төрләр”дигән атаманы мин монда шартлы бер мәгънәдә кулланам. Мин монда кушма төрләр дип, телебездәге ике сүздән, яки берничә сүздән кушылып, янәшә тезелеп, бергә оештырылып әйтелгән күренешләрне алам. Кушма төрләр җөмлә эчендә грамматик бер бөтен булып йөриләр. Мәгънәләре ягыннан кушма төрләр эченә кергән аерым сүзләрнең берсе үзенең туры мәгънәсен бөтенләй яки кисәкчә югалтып, икенчесе ярдәмче булып килгән була. Аларның икәвеннән яңа утак бер мәгънә яки яңа бер мөнәсәбәт аңлана. Җөмлә эчендә кушма төрләр эчендәге аерым сүзләрне, гадәттә, башка тәртиптә китереп әйтергә яки аларның арасына җөмләнең башка бер кисәген кертеп әйтергә мөмкин булмый: аларның тәртибен, төен үзгәртү,бер-береннән аеру теләнгән мәгънәнең үзгәреп китүенә сәбәп була [2,с 78].

**Йомгаклау.** Татар телендә сүз ясалышы озак вакытлар дәвамында морфология эчендә каралып килә, ул XX гасырның 80 нче елларында гына грамматиканың аерым бер бүлеге булып формалашып җитә. Монда иң элек Г. Алпаров, В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева, Ф.Ә. Хисамова кебек күренекле тел галимнәренең бу өлкәдәге махсус тикшеренүләрен, теоретик хезмәтләрен атап үтәргә кирәк.

Структур, ягъни составы ягыннан татар сүзләре синтетик (гади), аналитик (кушма) һәм кыскартылма төрләргә бүленә.

Кушма сүз (композит) термины барлык төр аналитик сүзләрне атау өчен сүзләргә аерыла.

Татар теленең күпчелек академик һәм гамәли грамматикаларында кушма сүзләрнең синтаксик ысул белән ясалышы билгеләп үтелә. Ф.М. Хисамова традицион рәвештә синтаксик ысул дип йөртелгән бу сүз ясалыш ысулының соңгы вакытта татар телендә һәм тюркологиядә сүз кушу “словосложение” дип аталуын билгели. Ф.Ә. Ганиев үзенең кушма сүзләрне тикшерүгә багышланган монографик хезмәтендә синтаксик ысул җирлегендә өч ысул аерып чыгара : 1) сүзләрне кушу, 2) сүзтезмә лексикалашу, 3) сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчүе.

Татар теленең академик грамматикасында кушма (аналитик) сүзгә түбәндәгечә бигеләме бирелә: икедән дә ким булмаган тулы мәгънәле мөстәкыйль морфемалардан яки берсе тулы мәгънәле, икенчесе тулы мәгънәле булмаган сүздән гыйбарәт сүзләр аналитик сүзләр дип атала, аларны икенче төрле кушма сүзләр дип тә йөртәләр.

Татар телендәге кушма сүзләр ясалышы гаять җентекле татар телендә сүз ясалышы бүлеген фәнни-теоретик яктан эшкәрүгә иң зур көч куйган һәм өлеш керткән галим Ф.Ә. Ганиев тарафыннан өйрәнелә. Галим кушма сүзләрне төрле аспектларга нигезләнеп классификацияли: 1) компонентларның мәгънәви доминантлыгы ягыннан; 2) компонентларның сүз төркеме ягыннан; 3) компонентара синтаксик мөнәсәбәтләре ягыннан; 4) семантик принцип буенча (идиоматик яки идиоматик булмаган); 5) компонентларның генезисы буенча (парлы сүзләргә генә карый) һ.б.

**Әдәбият исемлеге**

1. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр (Татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). – Казан: Татгосиздат,1945. – 330б.

2. Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.А. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе / З.М. Вәлиуллина һ.б. – Казан, 1972. – 206б.

3.Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. Төзәт. 2 нче басма / Ф.Ә. Ганиев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 271б.

4. Курбатов Х. Татар телендә кушма сүзләр язылышы // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан,1959. – 123 – 131 б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮДӘ ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ РОЛЕ

***Шайдуллина Ч.М.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*“2 нче мәктәбенең”*
*Альметьевск, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, бүгенге җиһан катлаулы, тиз үзгәрүчән. Шуның белән бәйле рәвештә мәгарифнең дә яңа шартларда яшәргә сәләтле кеше тәрбияләүдәге җаваплылыгы арта бара.

Мәгарифне инновацион үстерү-республикабыз һәм илебез киләчәгенең нигезе. Шуңа күрә белем бирүдә инновацион юнәлешне үстерү-төп бурычларның берсе.

Яңа нәтиҗәләргә ирешү, конкурентлыкка сәләтле, социаль яктан җаваплы, инициативалы һәм компетентлы гражданнар тәрбияләү-инновацион белем бирүнең төп бурычлары шулар.

Соңгы унъеллыкта җәмгыятебездә барган үзгәрешләр белем бирү системасын да читләтеп үтмәде. Педагогик тәрбия һәм тәҗрибә заманча таләпләргә җавап бирергә тиеш.Укучыга булган мөнәсәбәт белән бергә,укытуның эчтәлеге дә үзгәрергә тиеш. Мәктәпләрдә, белем бирүнең традицион формалары белән беррәттән, укытуның сыйфатын сизелерлек дәрәҗәдә күтәрүче яңа (инновацион) технологияләр дә уңышлы файдаланыла.

Социаль-тарихи һәм мәдәни процессның шундый субъекты булып һәрьяктан камил, рухи яктан үскән шәхес тора. Ул шул мохиттә яшәргә сәләтле булу белән бергә анда актив эшләү күнекмәләренә дә ия булырга тиеш. Хәзерге шартларда «мәгариф» дигән төшенчә үзе дә үзгәрә башлады. Ул элегрәк мәктәптә укыту процессы белән генә тиңләштерелсә, хәзер киңрәк мәгънә ала бара. Моңа мәгълүмати технологияләр дә нык тәэсир итә. Бүгенге мәгълүмати технологияләргә нигезләнгән мәгарифнең нәтиҗәлелеге файдаланыла торган технологияләрнең төренә генә түгел, ә бәлки педагогик эшнең сыйфатына да бәйле. Технологик инновацияләр педагогик метод һәм алымнар эчтәлегенең баюына китерә, шуның белән бергә алар педагогика үсешенә тулаем тәэсир итә.Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану яңа метод һәм алымнарны үстерүгә укытучыларга, эш стилен үзгәртеп, яңача эшләргә, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу исә педагогик процессны оештыруга һәм аның белән идарә итүгә үзенчәлекле бурычлар куя. Татар телен инновацион технологияләр белән укыту-уку процессын яңача оештыру дигән сүз. Аның мөһим мәсьәләләре булып өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уяту, танып-белү активлыгын үстерү, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү тора [1,Б37]

Заман уку-укыту эшчәнлегенең барлык тармагына да үзгәрешләр кертә, безгә, укытучыларга да, яңа таләпләр куя. Сыйфатлы белем бирү өчен, мәгариф өлкәсендә модернизацияләү кирәклеген аңлап, без дә дәресләребездә

инновацион технологияләр кулланып эшләргә тиеш. Тәрбияле, белемле, бар яктан булган шәхес, ягъни көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү өчен заман белән бергә атлау, укучыларны кызыксындырырлык яңа технологияләр кулланып эшләү мөһим [2,Б29]

Татар теле – халыкара мәйданда зур абруйлы телләрнең берсе. Шулай булгач, ул үзен саклаган, хөрмәт иткән халкына дәүләт теле буларак хезмәт итәрлек тулы көчкә ия. Туган телебезне камилләштерү, үстерү–дәүләт күләмендәге җитди һәм әһәмиятле бурычларның берсе. Татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтүнең, аны үзләштерүне тиешле дәрәҗәгә күтәрүнең төп юлы –рус мәктәпләрендә укучыларга татар теле һәм әдәбиятын сыйфатлы, нәтиҗәле итеп укыту.

Соңгы елларда безнең илебездә компьютер тормышыбызның бөтен өлкәләренә дә үтеп керде. Укытучы профессиясе дә уку эшчәнлегендә компьютер технологияләреннән файдалануны таләп итә. Информацион технологияләрнең зур тизлек белән үсүе яшь буынның белемле, иҗади фикер йөртүгә сәләтле булуын таләп итә.

Компьютер технологияләре белем бирүнең эчтәлеген, методларын, оештыру формаларын сыйфатлы итеп үзгәртә, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен, танып белү сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Хәзерге вакытта дәресләрдә мультимедиа чараларын еш кулланабыз. Бу мультимедиа технологияләрен куллану яңалыклар белән кызыксыну теләге уята. Беренчедән, укучыларның белемнәре формалаштырыла, икенчедән, сөйләм һәм мультимедиа чаралары белән эшләү күнекмәләре формалаша.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә яңа технологияләрне куллануның төрле алымнары кулланыла. Мультимедия технологиясе слайд- иллюстрацияләр күрсәтергә, читтән торып экскурсия үткәрергә мөмкинлек бирә. Укучыларның татар телендәге информация белән кызыксынулары татар әдәбияты дәресләрендә компьютер куллануның бик күп мөмкинлекләрен ача.

1. Интеренет – татар әдипләренең әсәрләрен һәм танылган язучыларның сирәк басмалары белән таныша алу.

2. Компьютер ярдәмендә укыту тиз һәм нәтиҗәле итеп үткән материалны актуальләштерә ала.

3. Укучыларның белем һәм күнекмәләрен бәяләүдә ярдәм итә.

4. Әдәбият дәресләрендә иллюстрацияләр, сәнгатьле уку күнекмәләре бирү һәм шагыйрьләрнең көйгә салынган җырларын тыңларга мөмкин. Дәреснең төрле этапларында материал мультимедия аша бирелә.

Практика күрсәткәнчә, дәресләрдә компьютер куллану белем бирүдә традицион методлардан өстен булуын раслый, укучы дәресләрдә актив катнашучы була. Компьютер программалары укытуны индивидуальләштерүгә ярдәм итә, укучыларның мөстәкыйль эшләүләрен оештырырга мөмкинлек бирә [3,Б31]

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Яңа технологияләр буенча эшләү укытучының дәресләрдә төрле позициядән чыгып эшләвен күз алдында тота. Ул режиссёр да, укытучы да, укучы да, билгеле бер эшнең оештыручысы да була.

Мәктәптәге традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган дәресләр үткәрү укучыларның хәтерендә ныграк кала.

**Йомгаклау.** Ялкыткыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә,иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану мөһим.

**Әдәбият исемлеге**

1. Балобанова А. Компьютер технологияләрен кулланып // Мәгариф – 2004. – № 6. – 96 б.
2. Газизуллина Р. Мәгълүмәти технологияләрдә файдаланып // Мәгариф. – 2007. – № 12. – 96 б.
3. Четвинарсова О. Дәресләрдә яңа педагогик технологияләрне кулланып // Мәгариф . – 2007. – № 11. – 96б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ АЛГАН БЕЛЕМНӘРНЕ ГАМӘЛИ КУЛЛАНУ

***Шакирова М.Г.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Сафиуллина Л.Н.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*«186 нчы лицей»*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, җәмгыятьнең башка өлкәләреннән аермалы буларак, мәгариф эшчәнлеге киләчәккә юнәлтелгән. Ул яшәешебезнең киләчәккә үсешен тәэмин итәргә тиеш. 10-15елдан соң илебез нинди булыр? Бүгенге укучы үз урынын таба алырмы? Менә бу, беренче карашка,гади генә тоелган сорауга җавап табу, һичшиксез, мәгариф системасын модернизацияләүнең алшарты булып тора. Бу өлкәдә һәр укытучыга караган төп юнәлешләрнең берсе- белем эчтәлеген яңарту, фикерләүне үстерү аша укучыны тормышка әзерләү, һәр яктан камил булган зыялы шәхес тәрбияләү.Ә ул, үз чиратында, туган телебезне яратучы, үз халкының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш .

Мәктәптә баланы яшәргә, кешеләр белән аралашырга, теге я бу ситуациядә үз-үзен ничек тотарга өйрәткән предмет -әдәбият. Нәкъ менә тел һәм әдәбият тормыш-чынбарлыкны, кешеләргә очрый торган вакыйга-каршылыкны, кешенең психологиясен һәм төрле шартларда үз-үзен тотышын күрсәтә, әдәби геройларның күңел матурлыгы турында сөйләп, әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үз җаннарында ничек итеп матурлык һәм яхшылык йөртүен аңлата. Әдәбият аша укучы башкаларга игътибарлы булырга, кеше күңелен яраламаска, җәмгытьтә үз урынын табарга өйрәнә. Әсәрләр ничек яшәргә һәм нинди булырга юл күрсәтә. Аларда кешелекнең тормыш тәҗрибәсе, рухи эзләнүләре, фикер, акыл байлыгы саклана. Мәктәптә әдәбият шушы тәҗрибәне бүгенге яшьләргә җиткерергә, аны хәзерге яшәеш белән берләштерергә, файдаланырга өйрәтергә тиеш.

Әдәбият дәресләре- эстетик төркемгә керүче предметларның берсе. Ул дөньяны,тормышны,тарихны һәм бүгенгене, кешенең үз-үзен тотышын, психологиясен аңлауга ачкыч ролен үти. Бу турыда Габдулла Тукай: “Балаларыбызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә,вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә иялэшсен. Кечкенәдән үк гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә лэтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр”,-дигән.Аныңча,киләчәкнең яңа кешесе физик яктан сәламәт, рухи яктан камил булырга, туктаусыз тырышырга тиеш.

Эстетик культура төшенчәсе үз эченә тормыштагы, сәнгатьтәге, табигатьтәге, көнкүрештәге, хезмәттәге, эш-гамәлләрдәге матурлыкка һәм ямьсезлеккә билгеле бер мөнәсәбәт булуны һәм үзеңнең хисләреӊ белән идарә итә алуны, сәнгатьнең һәм чынбарлыкның камиллеген, матурлыгын аңлауны

һәм белүне, сәнгать әсәрләрен бәяли алуны, тормышны матурлык законнарына таянып кору теләгән ала.

Әдәбият эстетик тәрбиянең төп чарасы булып тора. Ул кешедә ләззәтләнү, соклану уята, аны матурлыкка якынайта, аның рухи халәтен матурлыкны аңлау дәрәҗәсенә күтәрә. Әдәбият дәресләрендә гүзәллекне һәм ямьсезлекне, югары һәм түбән хисләрне, камиллекне һәм җитешсезлекне аера һәм аларга карата үз фикерләрен әйтә белергә өйрәтү сәнгать әсәренең асылына үтеп керергә ярдәм итә, югары әдәби зәвык тәрбияли. Бу, үз чиратында, тормышка, кешеләргә карата, хезмәт эшчәнлегендә, гомумән, һәр адымда эстетик мөнәсәбәтләр булдыруга ярдәм итәргә тиеш.

Туган ил, туган тел... Бу ике сүзне һәркем хөрмәт белән әйтә, алар – аваздаш булып ишетелә. Бу ике сүз күңелләрдә якынлык, кардәшлек хисе, туган илеңә һәм халкыңа тирән мәхәббәт тойгысы уята. Үз туган теленә, тарихына хөрмәте булмаган кешенең башка телләргә дә, үз ата-анасына, үз Ватанына, үз халкының әхлак нормаларына, халыкның мәдәниятенә һәм сәнгатенә, тарихына да хөрмәте булмый. Туган телен кадерләгән халык кына кадерле, абруйлы халык була.

Менә ни өчен дә телне, туган телне – ана телен яхшы белергә, аның бөтен нечкәлекләрен өйрәнергә һәм өйрәтергә кирәк.

Татар теле – татар халкы өчен уртак милли тел, бу телдә миллионлаган татар халкы үзара аңлаша, аралаша ала, үзенең тарихын өйрәнә, төрле фәннәрне үзләштерә, мәдәни байлыгы белән таныша, үз эшендә алардан иҗади файдалана ала.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә татар теле дәресләрендә алган белемнәрне гамәлгә ашыру юллары турында сүз бара. Ана телен яхшы белү укучыларның яңа белемнәрне үзләштерүдә, гомуми үсеш дәрәҗәләрен күтәрүдә, фикер йөртү сәләтләрен үстерүдә, киләчәктә җәмгыять тормышында актив катнашырга әзерләүдә һәм сайлап алган хезмәтләрендә уңышларга ирешүдә мөһим шарт булып тора.

Тел-җәмгыятьнең, һәрбер аерым шәхеснең берни белән дә алыштырып булмый торган рухи байлыгы.Ул халыкның акыл хәзинәсен, гореф-гадәтен, иң яхшы традицияләрен, дөньяга карашын, мәдәниятен борынгы заманнардан түкми-чәчми безнең көннәргә алып килгән.

Бүген мәктәптә ана теле укытуның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үз халкына, аның әдәби теленә, тарихына һәм мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү;

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Ана телен, аның грамматик төзелешен үзләштергән, грамматик, стилистик һәм орфографик яктан дөрес сөйләм һәм язу күнекмәләренә ия булган, орфоэпик, орфографик һәм пунктуацион яктан тулы белемле, тел чараларыннан уңышлы файдалана белүче һәм сәнгатьле уку күнекмәләре алган кешеләр әзерләү.Бу-мәктәптә укытуны тормыш белән бәйләү дигән сүз. Укучы алган белемне гамәлдә,үзенең эшендә куллана белергә өйрәнсен.Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, тел материалын өйрәтү белән бергә, әдәби тел нормаларына туры китереп, укучыны сөйләргә һәм язарга,

йөгерек, сәнгатьле һәм аңлы укырга докладлар сөйләргә, чыгышлар ясарга, эш кәгазщләре язарга,гомумән,үз фикерләрен сөйләмә һәм язма рәвештә бирә белергә өйрәтү таләп ителә. Мәктәпне тәмамлагач та укучы кайда гына эшләсә дә яки укыса да, анда алган белемен файдалана алсын;

Укучыларның сүзлек хәзинәсен баету;

Үз фикерләрен ана телендә, сөйләмә һәм язма рәвештә, эзлекле, җыйнак, төгәл һәм матур итеп бирергә өйрәтү, логик фикерләү сәләтен үстерү.

“...Халыкның зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән,өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән”,-дип язган Гомәр Бәширов. Шушы хәзинәне баету һәм алдагы буыннарга тапшыру безнең һәм без укыткан укучыларның бурычы. Шунысы хак: бер телне камил белгән кеше, бүтән телләрне дә хөрмәт итә, мөмкин булганча өйрәнә.Туган телен белмәгән, белергә теләмәгән кеше ата-бабаларыбыз истәлегенә тап төшерәдер кебек миңа. Без татар телендә сөйләшә, укый, яза, фикер йөртә белми торган бала үстерәбез икән,безнең милләтебезнең киләчәге юк дигән сүз. Сүземне халык шагыйре Равил Фәйзуллин сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

**Йомгаклау.** “Күп телләрне белү яхшы шөгыль Туган телең үги калмаса. Җаның салып әйткән әнкәң сүзен Синең аша балаң аңласа. Киләчәкнең башы бүгенгедә Нинди шатлык картлык көнеңдә Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә, Матур итеп туган телендә.“

**Әдәбият исемлеге**

1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. - “Раннур” китап нәшрияты,2000.

2. Гәрәева Н.Г., Максимов Н.Г., Зыятдинова Ә.Ә. Тел-белемнең ачкычы. “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

3. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укытуметодикасы. “Мәгариф” нәшрияты,2004.

4. Ибраһимов И.М. , Заһидуллина Д.Ф. , Хәсәнова Ф.Ф., Ширмән Х.Х. , Нуриев В.В. XXI гасыр татар әдәбияты, татар әдәби теленең сакланышы һәм үсеш тенденцияләре (Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең 75еллыгы уңаеннан үткәрелгән фәнни-гамәли конференөия материаллары). Казан, 2 ноябрь, 2009 ел.

5. Исмәгыйлова С.Г., Исмәгыйлова Ф.М. Тәрбия хәзинәләре. Чаллы “КАМАЗ” нәшрияты, 1992.

6. Сәмигуллин Г.Х., Кәримова Ф.С. Татар әдәбиятын системалы укыту: эзләнүләр һәм тәҗрибә. Яр Чаллы, 2006.

7. Трофимова С.М., Сәнгатов Г.М., Гәлләмова Р.В. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына. “Яңалиф” нәшрият йорты.

УДК 811.111:81`373.45

# МЕХАНИЗМЫ ЗАИМСТВОВАНИЯ И АДАПТАЦИИ ИНОСТРАННЫХ СЛОВ В СОВРЕМЕННОМ АНГЛИЙСКОМ

***Шигабутдинов А.А.***
*магистрант*
*Научный руководитель – к.п.н., доцент*
***Айтуганова Ж.И.***
*Казанский государственный*
*энергетический университет*
*Казань, Россия*

**Актуальность.** Английский язык на протяжении всей своей долгой истории, начиная с древнеанглийского периода и вплоть до наших дней, непрерывно расширял свой лексический состав, принимая заимствования из разных языков. В основе этого процесса, несомненно, лежат исторические и торговые связи между народами, культурное влияние и технологический прогресс. Современные информационные технологии и глобальная коммуникация также играют важную роль в увеличении количества заимствованных слов. Именно поэтому исследование механизмов их интеграции в систему английского языка является интересной и актуальной темой для изучения. Использование заимствованной лексики – важный аспект развития и пополнения словарного запаса любого языка. Благодаря международному статусу, а также своему широкому распространению английский язык особенно открыт для данного процесса в настоящее время. В предложенной статье анализируются пути проникновения иноязычных слов в английский язык и их последующая адаптация. Также в процессе работе мы старались учитывать воздействие культурных, общественных и языковых аспектов на данный процесс.

Данная статья опирается на комплексный методологический подход, включающий анализ лингвистических источников, посвященных заимствованиям, изучение конкретных примеров, иллюстрирующих различные этапы их ассимиляции в английском языке. Ключевыми методами являются сравнительный анализ, исторический метод и детальное описание процессов адаптации и интеграции заимствованных терминов.

На сегодняшний день существует огромное количество различных классификаций заимствованных слов. Светлана Евгеньевна Груенко в своей статье выделяет девять разделений [2], а в заключении, проанализировав и обобщив всю полученную с различных источников работ, выводит свой вариант (рисунок 1).

Когда мы говорим о самом процессе, то он включает три основных этапа: контакт (т.е., первоначальное знакомство с иностранным словом) – адаптация (т.е., изменение формы и значения слова для соответствия правилам

принимающего языка) – интеграция (т.е., полное включение слова в активный словарь). Рассмотрим каждый из них отдельно.




Рисунок 1 – Типы заимствований по С.Е. Груенко

Первый этап – контакт. Он может происходить различными путями: международная торговля, туризм, иммиграция, культурный обмен, а также благодаря интернету и социальной сети. Например, слово «sushi» проникло в английский язык благодаря росту популярности японской кухни в западных странах в начале XX века [3].

Второй этап – адаптация. Данный процесс предполагает фонетическое, грамматическое и семантическое переоформление слова. Например, французское слово «café» трансформировалось в английское «coffee». Первоначальное произношение [kafe] постепенно эволюционировало, приняв современное звучание [kɔfi] [1, С.74].

И, наконец, третий этап – интеграция. Здесь идет речь об активном использовании слова и в письменной, и в устной речи. Например, итальянское слово «pizza» занимает прочное место в английском языке [1, С.231].

Немаловажно отметить и факторы, влияющие на заимствование слов. Сюда входят частота контакта (чем чаще используется слово, тем быстрее оно интегрируется), необходимость (присутствует ли срочная необходимость в новом термине), структура языка (открытые языки легче воспринимают заимствования) и социальные факторы (преобладание определенных групп населения, занимающихся использованием заимствованного термина). Например, японское слово «emoji» укоренилось в английском языке благодаря постоянному использованию мобильных устройств и социальных сетей [3].

Мы выявили, что заимствование слов в английский язык происходит в три стадии: **контакт**, когда слова проникают через международные связи, торговлю, культуру и современные средства коммуникации; **адаптация**, в ходе которой слова изменяются фонетически, морфологически и семантически, чтобы соответствовать нормам английского языка; и **интеграция**, когда слово становится частью активного словарного запаса, активно употребляясь в устной и письменной речи. Также были определены факторы, влияющие на скорость и глубину заимствования: частоту взаимодействия, потребность в новом термине, особенности структуры языка и социальные аспекты. Глобализация, развитие

СМИ, технологий и интернета значительно ускоряют эти процессы в современном мире.

Сегодня в век глобализации процесс заимствования значительно ускорен. Средства массовой информации, цифровые технологии способствуют стремительному распространению новых терминов и фраз. А процесс, посредством которого английский язык принимает и адаптирует иностранные слова, является многогранным и зависит от целого ряда условий. Исследование этого процесса дает ценное представление о развитии современного английского языка и его взаимосвязях с другими языками. Таким образом, понимание механизма и стадий заимствования критически важно для осмысления эволюции английского языка и его взаимосвязей с другими языками. Изучение этих явлений позволяет глубже понять лингвистические трансформации и культурные обмены в современном обществе.

**Список литературы**

1. Арнольд И.В.Лексикология современного английского языка: учеб. пособие / И.В. Арнольд. – 2-е изд., перераб. – М.: ФЛИНТА: Наука, 2012 – 376 с. – Текст: непосредственный.

2. Груенко С.Е. К вопросу классификации заимствованной лексики // Наука о человеке: гуманитарные исследования. – 2016. – №1 (23) [электронный ресурс] – Режим доступа. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/k-voprosu-klassifikatsii-zaimstvovannoy-leksiki (дата обращения: 04.10.2025). – Текст: электронный.

3. Лифт Л. 15 слов, которые пришли в английский из японского: от эмодзи до боевых искусств // Skyeng Magazine. – 2025. – [электронный ресурс] – Режим доступа. – URL: https://skyeng.ru/magazine/15-slov-kotorye-prishli-v-anglijskij-iz-yaponskogo-ot-emodzi-do-boevyh-iskusstv/?ysclid=mgevhspp95361872581 (дата обращения: 06.10.2025). – Текст: электронный.

# РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРДА ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП ТУГАН ТЕЛДӘ АРАЛАШУ КҮНЕКМӘЛӘРЕН БУЛДЫРУ

Шигабуддинова Р.Р.
*татар теле укытучысы*
*“83нче лицей”*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, соңгы елларда укытучыга кайсы дәреслек, методика, технология нигезендә укыту, электив курсларны үзеңә сайлап алу хокукы бирелде.Икенче яктан, җәмәгатьчелекнең аңа таләпәре артты. Хәзерге шартларда сыйфатлы белем бирү төп бурыч булып тора. Ә рус телле балалар белән эшләүче татар теле укытучыларының төп бурычы – укучыларны татарча аралашырга өйрәтү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

– җөмләләрне тыңлагыз. Ничә сорау, хикәя, өндәү җөмлә барлыгын әйтегез;

– тыңланган сөйләмдә орфоэпик хатаны табыгыз;

– җөмләләрне тыңлагыз. Алардагы сүзтезмәләрне аерып әйтегез;

Тыңлап аңлау күнегүләрен телнең төрле аспектларын нәтиҗәле үзләштерү өчен дә кулланып була. Укучылар лексик берәмлекләрне, грамматик калыпларны укып кына түгел, ишетеп тә аңларга тиешләр.

Ишетеп аңлау укыту-тәрбия процессында телгә өйрәтүнең бер чарасы буларак катнаша һәм төп коммуникатив рольдән тыш та икенчел, педагогик вазифаларга ия булып тора. Ул укучыларның сөйләм теленә стимул була, телгә өрәтү процессы белән идарә итүне тәэмин итә, укучыларны яңа тел, сөйләм һәм татар халкының милли – тарихи вакыйгалары, күренешләре белән таныштыра, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру чарасы булып тора, укытучы белән укучы арасында үзара бәйләнешнең нәтиҗәлелеген күтәрә. Шуңа күрә ишетеп (тыңлап) аңлауга өйрәтүне дөрес оештыру, коммуникатив методикага нигезләнеп эшләнгәндә, телне уңышлы өйрәтүнең иң төп шартларыннан берсе булып тора [1,Б.146]

Билгеле булганча, укыту процессында кулланылган барлык күнегүләр, эш төрләре укучыларның тел күнекмәләрен генә түгел, фикерләү сәләтен, хәтерен, игътибарын да үстерә. Тыңлап аңлауга өйрәткәндә, моны истән чыгармаска кирәк. Шул исәптән үстерелешле укыту алымнарын истә тотып, укучыларга түбәндәге биремнәрне эшләтергә дә мөмкин.

1. Җөмләләрне тыңлагыз. Аларга туры килгән рәсемнәрне күрсәтегез.
2. Җөмләләрне тыңлагыз. Хәрәкәтләр ярдәмендә мәгънәләрен аңлатыгыз.
3. Җөмләләрне логик эзлеклелектә урнаштырыгыз.
4. Укытучы артыннан кабатлап, диалогны ятлагыз.
5. Укытучы артыннан кабатлап, сүзләрне истә калдырыгыз.
6. Укытучы артыннан җөмләләрне кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.
7. Укытучы артыннан бер үк грамматик калыплы җөмләләрне кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.
8. Укытучы әйткән һәм карточкага язылган җөмләләрне чагыштырыгыз. Нинди лексик яки грамматик аермалар барлыгын әйтегез.
9. Текстның башын тыңлагыз, ахырын уйлап бетерегез (киресенчә дә мөмкин)
10. Ике текстны тыңлап, аларның уртак һәм аерылып торган якларын әйтегез.
11. Текстны тыңлагыз һәм аңа исем уйлап табыгыз.
12. Текстны тыңлагыз. Эчтәлеген берничә җөмлә белән генә сөйләп бирегез.
13. Тыңланган диалогны монологик формада сөйләгез һ.б.

Күргәнебезчә, аерым сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр, бәйләнешле текстлар белән эшләү күнегүләре күп санлы һәм күп төрле. Укыту шартларыннан чыгып, аларның иң кулаен сайлап алу һәм системалы рәвештә эшләтү укучыларны татарча сөйләмне тыңлап аңарга өйрәтә ала. Кызганычка каршы, бу төр күнегүләрне эзлекле рәвештә кулланмыйбыз, шуңа күрә дә рус

укучылары бары тик укытучының сөйләмен генә аңларга күнегәләр; башка бер кеше шул ук сорау белән мөрәҗәгать итсә югалып калалар [1,Б. 124]

Рус телендә сөйләшүче балаларны татар сөйләмен аңларга һәм татарча сөйләргә өйрәтү төрлечә көч куюны, практикага төрле вакыт сарыф итүне сорый, ә инде эш алымнары һәм системасының төрледән –төрле булырга тиешлеген әйтеп тә торасы юк.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Тыңлау өчен материал биргәндә, билгеле бер эзлеклелек сакланырга тиеш. Әйтик, рус мәктәбендә, татар теленең алдагы дәресләрендә, беренче сыйныф баласында механик хәтер өстенлек итүен исәпкә алып, телдән үтелгән материалга таянып төзелгән җөмләләр бирергә мөмкин.

Аңлау өчен бирелә торган хәбәрләр күләме этаптан этапка арта бара.Шуның белән бергә укытучының хәбәре баштарак, нигездә, телдән үтелгән материалга, таныш лексикага корылса, соңга таба таныш түгел сүзләр кертелгән текстлар бирелергә мөмкин, ләкин шуны истә тотарга кирәк, тыңларга бирелгән материал күләме бик аз булырга тиеш.

Тыңлау материалының тәкъдим ителү сыйфатына да зур таләпләр куелырга тиеш. Башлангыч сыйныфларда ишетеп (тыңлап) аңлау материалы булып укытучы сөйләме тора. Укытучының татарча сөйләве – рус укучысы дәрестә зиһененә ала торган беренче өлге ул. Бу өлге тел атмосферасы тудыра, шуннан укучының татарча сөйләмне аңлау күнекмәләре формалаша. Татар теленең грамматик төзелмәләрен башлангычта үзләштерү укытучы әйткән өлге буенча бара [2,Б.218]

**Йомгаклау.** Хәзер безнең илдә мәгариф тирәлегенә юнәлтелгән яңа мәгариф системасы урнаша бара. Бу эш педагогик фәнгә һәм укыту-тәрбия процессына сизелерлек үзгәрешләр кертә. Белем эчтәлеге яңа күнекмәләр белән баетыла, мәгълүмат белән эш итү сәләте үстерелә, белем бирү программалары индивидуальләштерүгә юнәлтелеп, фән һәм икътисад үсеше проблемалары хәл ителә. Укытучының укучылар белән шәхси юнәлешле аралашуы – педагогик процессның мөһим состав өлеше булып тора. Шәхесне рухи яктан тәрбияләүгә, кешенең әхлакый йөзен формалаштыруга зур әһәмият бирелә. Мондый шартларда укытучы күптөрле инновацион технологияләренә, идеяләргә юнәлеш тотарга тиеш була. Педагогик яктан грамоталы белгеч булу өчен заман педагогик технологияләрен белү һәм аларны нәтиҗәле файдалану сорала.

**Әдәбият исемлеге**

1. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре. - Казан:Мәгариф,1998. - 342б.

2. Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы. - Казан:Мәгариф,2001. - 318б.

3. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә тел культурасы. - Казан,1965. - 158.

4. Хәсәнова М.К. 3 нче класста уку һәм сөйләм үстерү дәресләре. Казан.Татарстан китап нәшрияты, 1991. - 136б.

5. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан:Тат.кит.нәшр., – 1987. - 248б.

# ТАТАР ТЕЛЕН ЧИТ ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘТҮНЕҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

***Вәлиева Д.Д.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Хәйруллина Э.Һ.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*"186нчы лицей"*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып торган милли мәгариф системасын без киләчәк буынны гаилә, балалар бакчасыннан алып, югары мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту буларак күз алдында тотабыз. Баланың дөньяга карашы, үз-үзен тотышы, дусларына, туган теленә мөнәсәбәте гаиләдә формалаша башласа, мәктәптә дәвам итә.

Соңгы вакытларда татар теле һәм әдәбияты укытуларына күп кенә шелтәләү сүзләре ишетергә туры килә. Янәсе, нәтиҗәләр юк диярлек, мәктәпне тәмамлаучыларның бик азы гына үзләренең фикерләрен татарча әйтеп бирә алалар. Рус мәктәбендә рус телле балалар белән эшләүнең актуаль проблемалары чыннан да бар һәм аларның кайберләрен атап, аларның чишү юлларын күрсәтү кирәкле дә, уңышлы да булыр.

Сер түгел, укытканда өстенлек грамматикага бирелә. Болай эшләгәндә телнең төп – коммуникатив функциясе тормышка ашырылмый, ә бары тик мәгълүмати гына булып кала. Дәреслектә бирелгән текстның эчтәлеген укучы бик яхшы сөйләр, ә инде тормышта алынган берәр хәл турында сөйли алмаска да мөмкин.

Без укучыларны сөйләм теленә өйрәтергә тиеш, моңа шул телдә сөйләшеп кенә ирешеп була. Балаларны ана булмаган телгә өйрәткәндә кызыксындыру формалаштыруның дидактик шартларыннан берсе – аралашуны уку эшчәнлегенең төп төре итеп куллану. Башкачарак әйтсәк, без телнең коммуникатив функциясен үтәргә тиеш. Ләкин аралашуны эш вакытында сөйләшү итеп түгел, ә эшне башкару өчен сөйләшү итеп карарга кирәк. Әгәр без аралашмасак, алдыбызга куйган бурычны үти алмаячакбыз. Шуны онытмасак иде: сөйләм бер үк вакытта бер яктан мотивлаштыру, икенче яктан "корал" – тел чаралары куллану булса гына барлыкка килә. Димәк, бу проблемаларның тагын берсе дигән сүз. Әйтергә кирәк: мотив дигәннән без субъектны күз алдына китерәбез, аның омтылышларын, объектын, уйларының кайсы якка юнәлешен, шартларын аңлыйбыз.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә татар теле дәресләрендә килеп чыккан актуаль проблемалар турында сүз алып барыла.Татар телен һәм әдәбиятын чит тел буларак өйрәткәндә, туган тел белән уртак якларны һәм аермалыкларын күрсәтеп өйрәтү уңышлырак була. Бу очракта укытучы сөйләмне татарча булырга тиеш булса да, укучыга материалны рус телендә аңлатырга туры килә.

Вакытны өлешләп бүлсәк, сөйләмгә күпме вакыт каласын күз алдына китерәсездер.

Телнең коммуникатив функциясе үтәлсен өчен, укучы фикерен туплап, башкалар аңларлык итеп әйтсен. Ә моны тормышка ашыруда уен куллану отышлы санала. Дәресләрдә дидактик уеннар балаларны бер-берсе белән аралашырга өйрәтә. Мин үземнең дәресләремдә еш кына уеннар кулланам. Чөнки, төрле уеннар куллану, укуга кызыксынуны арттыра.

Рус мәктәбендә рус телле балалар белән эшләүче укытучыларның татар теле һәм әдәбиятын укытканда булган проблемаларның тагын берсе – төркемдәге бала санының 15 тән артык булуы. Мондый очракта, гадәттә, һәр укучы белән эшләргә вакыт җитми. Укытучы сыйныфны төркемнәргә бүлә, коммуникатив биремнәр бирә. Һәр төркем эшкә керешкәч, шаулаша башлый. Укучылар нидер әйтергә телиләр, җавап бирергә тырышалар кебек. Мондый эшчәнлекнең үзәгендә укытучы түгел, ә укучы булырга тиеш икәнне беләбез дә кебек, ләкин шуны һич бутарга ярамый: бу эш характерындагы шау-шумы, әллә тәртип бозумы? Икенче очрак булса, эш төрен үзгәртергә кирәк.

15 тән артык укучы булган төркемнәрдә мин белемне тест ярдәмендә тикшерүне тәкъдим итәр идем. Бигрәк тә, ачык төрдәге тест биремнәрен компьютер ярдәмендә тикшереп булмый, без аларның кәгазь вариантын гына карап объектив бәя бирә алабыз. Ябык сораулардан торган биремнәр исә укучы өчен җавап бирергә, укытучы өчен тикшерергә уңайлы.

Татар теле һәм әдәбияты укытуның тагын бер актуаль проблемасы – татар балаларының татарча белмәве. Шуңа бәйле рәвештә, укытучы татарча алып барылырга тиешле дәресне русча, тәрҗемә рәвешендә алып барырга тиеш була. Туган телебезнең аралашу, укучының шәхесен формалаштыру, шул максат белән төрле фәннәргә өйрәтү чарасы булуын онытмаска иде.

Укыту процессында дәреслек белән программаның туры килмәве дә актуаль проблема булып тора. Хәзер, дәреслекләрдә бу әсәр яисә тема булмаса да, программа буенча бару таләп ителә. Әлбәттә, бу укучылар өчен дә, укытучы өчен дә бик авырга туры килә. Укытучы сөйләве буенча гына әдәби әсәрне анализлау өчен күпме тырышырга кирәк!

Татар әдәбиятын укытуда тагын бер проблема – хәзерге чор язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре дәреслекләрдә сирәк күренә. Балалар язучыларыннан Г.Тукай, Д.Аппакова, Ш.Галиев һ.б. әсәрләрен балалар бик яратып укыйлар, ләкин укучыларны башка атаклы язучылар белән дә таныштырасы килә.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Гомумән, татар телен укыту кирәкме соң? Әлбәттә, ләкин бу укыту балага телне бәйләү, интектерү рәвешендә бармаска тиеш. Ничек эшләргә соң? Башта, бәлкем, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, аларның аралашу сфералары, оештыра алырлык лингвистик материалны сайларгадыр. Ләкин, эчтәлек сайлаганда сөйләм материалының күләмен билгеләү өчен, балаларның психофизиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур.

**Йомгаклау.** Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, татар теле укытуның проблемалары күп, ләкин әлегә алар, күпмедер күләмдә, чишелеп килә. Татар

телен укытуда да уңышларга ирешелә. Балаларны укыту, тәрбияләү укытучының эше, ләкин әлеге функцияләрне ата-ана да башкарырга тиеш. Бергә эшләгән очракта гына, билгеле бер дәрәҗәләргә ирешергә мөмкин. Туган теленнән, туган нигезеннән – Татарстаннан читләшү, туган телне махсус өйрәнмәү балаларыбызны милли үзаңнан, кешелек горурлыгыннан, туган халкыбызның әхлак чишмәләреннән мәхрүм итә, саф чишмә кебек җырлап-чыңлап торган телебезгә колагын томалый, туң күңелле тупас адәм булып үсүенә юл ача . Моны булдырмау бездән, җәмгыятьтән тора.

**Әдәбият исемлеге**

1. Актуальные проблемы преподавания татарского языка и литературы, русского и английского языков: сборник материалов Республиканской научно-практической конференции (20 декабря 2012 года). В 2-х частях. Часть 1. – Казань: РИО ГБУ «РЦМКО», 2013. – 402с.

2. Исмәгыйлова С.Г. Туган тел – очар канат: методик ярдәмлек / С.Г. Исмәгыйлова. – Чаллы, “КАМАЗ” нәшрияты, 1993. – 63б.

3. Хәйдәрова Р.З. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләрдә татар теле укыту программасы: 1-4 сыйныфлар (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Ә.Г.Әхәтова. – Казан: Мәгариф, 2009. – 60б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕН КЫЗЫКЛЫ АЛЫМНАР КУЛЛАНЫП УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Җәләлиева Л.Р.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
***Төхвәтуллина Л.Р.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*“144нче мәктәбе”*
*Казань, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып торган милли мәгариф системасын без киләчәк буынны гаилә, балалар бакчасыннан алып, югары мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту буларак күз алдында тотабыз. Баланың дөньяга карашы, үз-үзен тотышы, дусларына, туган теленә мөнәсәбәте гаиләдә формалаша башласа, мәктәптә дәвам итә.

Соңгы вакытларда татар теле һәм әдәбияты укытуларына күп кенә шелтәләү сүзләре ишетергә туры килә. Янәсе, нәтиҗәләр юк диярлек, мәктәпне тәмамлаучыларның бик азы гына үзләренең фикерләрен татарча әйтеп бирә алалар. Рус мәктәбендә рус телле балалар белән эшләүнең актуаль проблемалары чыннан да бар һәм аларның кайберләрен атап, аларның чишү юлларын күрсәтү кирәкле дә, уңышлы да булыр.

Сер түгел, укытканда өстенлек грамматикага бирелә. Болай эшләгәндә телнең төп – коммуникатив функциясе тормышка ашырылмый, ә бары тик мәгълүмати гына булып кала. Дәреслектә бирелгән текстның эчтәлеген укучы бик яхшы сөйләр, ә инде тормышта алынган берәр хәл турында сөйли алмаска да мөмкин.

Без укучыларны сөйләм теленә өйрәтергә тиеш, моңа шул телдә сөйләшеп кенә ирешеп була. Балаларны ана булмаган телгә өйрәткәндә кызыксындыру формалаштыруның дидактик шартларыннан берсе – аралашуны уку эшчәнлегенең төп төре итеп куллану. Башкачарак әйтсәк, без телнең коммуникатив функциясен үтәргә тиеш. Ләкин аралашуны эш вакытында сөйләшү итеп түгел, ә эшне башкару өчен сөйләшү итеп карарга кирәк. Әгәр без аралашмасак, алдыбызга куйган бурычны үти алмаячакбыз. Шуны онытмасак иде: сөйләм бер үк вакытта бер яктан мотивлаштыру, икенче яктан “корал” – тел чаралары куллану булса гына барлыкка килә. Димәк, бу проблемаларның тагын берсе дигән сүз. Әйтергә кирәк: мотив дигәннән без субъектны күз алдына китерәбез, аның омтылышларын, объектын, уйларының кайсы якка юнәлешен, шартларын аңлыйбыз.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә татар теле дәресләрендә килеп чыккан актуаль проблемалар турында сүз алып барыла.Татар телен һәм әдәбиятын чит тел буларак өйрәткәндә, туган тел белән уртак якларны һәм аермалыкларын күрсәтеп өйрәтү уңышлырак була. Бу очракта укытучы сөйләмне татарча булырга тиеш булса да, укучыга материалны рус телендә аңлатырга туры килә.

Вакытны өлешләп бүлсәк, сөйләмгә күпме вакыт каласын күз алдына китерәсездер.

Телнең коммуникатив функциясе үтәлсен өчен, укучы фикерен туплап, башкалар аңларлык итеп әйтсен. Ә моны тормышка ашыруда уен куллану отышлы санала. Дәресләрдә дидактик уеннар балаларны бер-берсе белән аралашырга өйрәтә. Мин үземнең дәресләремдә еш кына уеннар кулланам. Чөнки, төрле уеннар куллану, укуга кызыксынуны арттыра.

Рус мәктәбендә рус телле балалар белән эшләүче укытучыларның татар теле һәм әдәбиятын укытканда булган проблемаларның тагын берсе – төркемдәге бала санының 15 тән артык булуы. Мондый очракта, гадәттә, һәр укучы белән эшләргә вакыт җитми. Укытучы сыйныфны төркемнәргә бүлә, коммуникатив биремнәр бирә. Һәр төркем эшкә керешкәч, шаулаша башлый. Укучылар нидер әйтергә телиләр, җавап бирергә тырышалар кебек. Мондый эшчәнлекнең үзәгендә укытучы түгел, ә укучы булырга тиеш икәнне беләбез дә кебек, ләкин шуны һич бутарга ярамый: бу эш характерындагы шау-шумы, әллә тәртип бозумы? Икенче очрак булса, эш төрен үзгәртергә кирәк.

15 тән артык укучы булган төркемнәрдә мин белемне тест ярдәмендә тикшерүне тәкъдим итәр идем. Бигрәк тә, ачык төрдәге тест биремнәрен компьютер ярдәмендә тикшереп булмый, без аларның кәгазь вариантын гына карап объектив бәя бирә алабыз. Ябык сораулардан торган биремнәр исә укучы өчен җавап бирергә, укытучы өчен тикшерергә уңайлы.

Татар теле һәм әдәбияты укытуның тагын бер актуаль проблемасы – татар балаларының татарча белмәве. Шуңа бәйле рәвештә, укытучы татарча алып барылырга тиешле дәресне русча, тәрҗемә рәвешендә алып барырга тиеш була. Туган телебезнең аралашу, укучының шәхесен формалаштыру, шул максат белән төрле фәннәргә өйрәтү чарасы булуын онытмаска иде.

Укыту процессында дәреслек белән программаның туры килмәве дә актуаль проблема булып тора. Хәзер, дәреслекләрдә бу әсәр яисә тема булмаса да, программа буенча бару таләп ителә. Әлбәттә, бу укучылар өчен дә, укытучы өчен дә бик авырга туры килә. Укытучы сөйләве буенча гына әдәби әсәрне анализлау өчен күпме тырышырга кирәк!

Татар әдәбиятын укытуда тагын бер проблема – хәзерге чор язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре дәреслекләрдә сирәк күренә. Балалар язучыларыннан Г.Тукай, Д.Аппакова, Ш.Галиев һ.б. әсәрләрен балалар бик яратып укыйлар, ләкин укучыларны башка атаклы язучылар белән дә таныштырасы килә.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Гомумән, татар телен укыту кирәкме соң? Әлбәттә, ләкин бу укыту балага телне бәйләү, интектерү рәвешендә бармаска тиеш. Ничек эшләргә соң? Башта, бәлкем, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, аларның аралашу сфералары, оештыра алырлык лингвистик материалны сайларгадыр. Ләкин, эчтәлек сайлаганда сөйләм материалының күләмен билгеләү өчен, балаларның психофизиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур.

**Йомгаклау.** Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, татар теле укытуның проблемалары күп, ләкин әлегә алар, күпмедер күләмдә, чишелеп килә. Татар

телен укытуда да уңышларга ирешелә. Балаларны укыту, тәрбияләү укытучының эше, ләкин әлеге функцияләрне ата-ана да башкарырга тиеш. Бергә эшләгән очракта гына, билгеле бер дәрәҗәләргә ирешергә мөмкин. Туган теленнән, туган нигезеннән – Татарстаннан читләшү, туган телне махсус өйрәнмәү балаларыбызны милли үзаңнан, кешелек горурлыгыннан, туган халкыбызның әхлак чишмәләреннән мәхрүм итә, саф чишмә кебек җырлап-чыңлап торган телебезгә колагын томалый, туң күңелле тупас адәм булып үсүенә юл ача . Моны булдырмау бездән, җәмгыятьтән тора.

**Әдәбият исемлеге**

1. Актуальные проблемы преподавания татарского языка и литературы, русского и английского языков: сборник материалов Республиканской научно-практической конференции (20 декабря 2012 года). В 2-х частях. Часть 1. – Казань: РИО ГБУ «РЦМКО», 2013. – 402с.

2. Исмәгыйлова С.Г. Туган тел – очар канат: методик ярдәмлек / С.Г. Исмәгыйлова. – Чаллы, “КАМАЗ” нәшрияты, 1993. – 63б.

3. Хәйдәрова Р.З. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләрдә татар теле укыту программасы: 1-4 сыйныфлар (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Ә.Г.Әхәтова. – Казан: Мәгариф, 2009. – 60б.

# ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУНЫҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

***Сөнгатова Г.З.***
*татар теле һәм әдәбияты укытучы*
*“Күәм урта гомуми белем мәктәбе”*
*Кубян, Татарстан, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, сонгы елларда татар телен өйрәтү методикасының үткәнен һәм бүгенгесен яктыртуга багышланган хезмәтләр байтак кына дөнья күрде. Тел төп аралашу чарасы буларак кешеләргә хезмәт итсә, сөйләм төп аралашу ысулы булып тора. Шунлыктан бүгенге көндә һәрбер телне мәдәниятара һәм шәхесара аралашу-аңлашу чарасы буларак укыту иң мөһим мәсьәләләрдән санала.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсе һәм «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы» Закон (1992) нигезендә татар һәм рус телләре – тигез хокуклы дәүләт телләре. Күп милләтле Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә. Татарстанда татар теле барлык урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләрендә төп укыту фәннәренең берсе булып тора, күп кенә югары уку йортларында да булачак белгечләр рус теле белән беррәттән татар теленнән белемнәрен тирәнәйтәләр. Республикабызда телләр сәясәтенең киләчәктә үсеш алуы, татар теленең гамәли һәм интеллектуаль тормышта урын алу-алмавы аны мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укыту дәрәҗәсенә дә бәйле. Мондый шартларда татар теленә өйрәтү методикасын камилләштерү җитди бурычларның берсе булып тора. Татар телен аралашу чарасы буларак укыту өчен, иң нәтиҗәле методик алымнарны куллану, информацион-коммуникатив технологияләрдән киң файдалану аеруча зур әһәмияткә ия.

Соңгы елларда республикабызда әлеге өлкәдә җитди адымнар ясалды: татар теленә өйрәтү методикасының үткәнен һәм бүгенгесен яктыртуга багышланган фәнни монографияләр дөнья күрде; мәктәп программалары һәм дәреслекләре яңартылды; укытучылар өчен методик кулланмалар, уку-укыту ярдәмлекләре һәм дидактик әсбаплар, төрле сүзлекләр төзеп бастырылды, электрон дәреслекләр, онлайн-курслар, интерактив тестлар эшләнде һәм укыту практикасында киң кулланыла башлады. Татар теленә өйрәтүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләр үткәрелеп тора, шушы өлкәдәге алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу һәм аны тарату эше дә игътибардан читтә калмый. Димәк, бай тарихка ия булган татар лингвометодикасы заман таләпләреннән чыгып үсеш ала, үзгәрә һәм камилләшә дип әйтә алабыз.

Хәзерге вакытта мәктәпләрдә татар телен аралашу чарасы буларак укыту, шулай ук тел ярдәмендә укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның коммуникатив культурасын формалаштыру бурычы куела. Татар телен гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә, укучылар көндәлек тормышта, полиэтник

җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булырга тиешләр.

Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә, шулай ук башка милләттән булган укучыларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайта, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, толерантлык кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәргеч ясый. Федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә татар теленә өйрәтүнең төп максатлары түбәндәгечә билгеләнә: укучыларның аралашу даирәсен, тормыштагы аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча аларда коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы) формалаштыру; укучының танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү; укучыларны мәдәниятара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру.

Лингвометодикада коммуникатив компетенциянең берничә төре билгеләнгән: лингвистик, социолингвистик, дискурсив, стратегик, социаль-мәдәни, социаль компетенцияләр [2, Б. 9]. Татар телен коммуникатив нигездә укыту, беренчедән, балаларда *тел компетенциясе* булдыруга китерә, чөнки алар, тел берәмлекләрен гамәли үзләштереп, сөйләмдә кулланырга күнегәләр; икенчедән, аларның *сөйләм компетенциясе* үсеш ала, чөнки тел аралашу аша үзләштерелә; өченчедән, тел һәм сөйләм берәмлекләре аша татар дөньясы турындагы мәгълүматны үзләштереп, алар *социаль-мәдәни компетенциягә* ия булалар.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә телгә өйрәтүнең иң заманча коммуникатив юнәлешләр турында сүз бара. Хәзерге вакытта телгә өйрәтүнең иң заманча юнәлешләре булып коммуникатив һәм эшчәнлекле методлар санала. Татар теленә өйрәтүнең төп принциплары шушы юнәлешләрнең нигезен тәшкил итәләр. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: коммуникативлык принцибы (телгә өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынайту); индивидуальләштерү принцибы (укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру); телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы (аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе); телне функциональ төстә өйрәнү принцибы (лексик-грамматик материалның коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнүе); ана теле үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы (балаларның ана теленнән белемнәренә таяну һәм аның аермалы якларын исәпкә алу). Моннан тыш, укыту процессында сөйләм эшчәнлеге төрләрен үзара бәйләнештә үзләштерү, аңлылык, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принциплары да истә тотыла.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларыннан чыгып, татар теленә өйрәтүнең әһәмиятле бурычларын түбәндәгечә билгелиләр:

– милләтләр, мәдәниятләр төрлелегенә карамастан, дөньяны бердәм һәм бербөтен итеп кабул итү нигезендә шәхесләрнең гражданлык тиңдәшлеген формалаштыру;

– кешеләргә карата игелеклелек, ышаныч һәм игътибарлылык, ярдәм күрсәтергә әзер булу, ихтирам, әңгәмәдәшне тыңлый һәм ишетә белү, кешеләрнең үз фикеренә хокукы барлыгын таный белү нигезендә аралашу һәм хезмәттәшлек итү өчен, психологик шартлар формалаштыру;

– әхлаклылык һәм гуманизм, гаилә һәм мәктәп, коллектив һәм иҗтимагый кыйммәтләрне хөрмәт итү һәм аларны үтәүгә омтылу, этик һәм эстетик хисләр формалаштыру нигезендә шәхеснең кыйммәти-мәгънәви даирәсен үстерү;

– үзлегеңнән белемеңне арттыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү нигезендә, үз эшчәнлегеңне оештыра алу осталыгын булдыру;

– үз-үзен актуальләштерү шарты буларак, шәхеснең мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын үстерү.

Татар теленә өйрәтүнең төп эчтәлегенә килгәндә, ул фонетик, лексик, грамматик белемнәрне гамәли үзләштерүдән; татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен истә тотып, телдән яки язмача аралаша белү, диалогик һәм монологик сөйләмне логик яктан эзлекле итеп оештыра алу, әңгәмә барышында тел “кытлыгын” җиңеп чыгу, татар телендәге мәгълүматны сәнгатьле итеп һәм аңлап укый белү күнекмәләрен үстерүдән гыйбарәт.

Алга таба хәл ителәсе актуаль методик мәсьәләләргә килгәндә, безнең карашка, иң әһәмиятлесе – укучыларның татар телен белү дәрәҗәләрен тикшерү системасын заман таләпләренә туры китереп яңарту, чөнки тикшерү-бәяләү эшләре белем бирү процессының мөһим бер өлешен тәшкил итә. Педагогик тикшерү билгеле бер дидактик функцияләрне үти: *өйрәтү функциясе* (татар телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү); *диагностик функция* (укучыларның әзерлек дәрәҗәсендәге кимчелекләрне ачыклау һәм аларны киметү, укыту процессын камилләштерүгә юнәлтелгән карарлар кабул итү); *тәрбияви функция* (укучыларның үзтикшерү һәм үзбәяләү күнекмәләрен активлаштыру, белем алуга өстәмә этәргеч булдыру); *гомумиләштерү функциясе, прогностик функция* һ.б [3, Б. 26].

Хәзерге вакытта лингводидактикада күп төрле тикшерү алымнары кулланыла, яңа технологияләр гамәлгә кертелә. Шуларның иң мөһимнәре: 11 нче сыйныфта татар теленнән Бердәм республика имтиханын (БРИ) үткәрү; 9 нчы сыйныфны тәмамлаучылар өчен татар теленнән яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясен уздыру. Әлеге тикшерү эшләре укучыларның коммуникатив күнекмәләрен объектив рәвештә бәяләргә, уку-укытуның нәтиҗәлелеген тулырак күзалларга мөмкинлекләр бирә. Тикшерү барышында балаларның белем дәрәҗәсе белән беррәттән укытучының методик эшчәнлеге дә сынала, кулланыла торган укыту чараларының ни дәрәҗәдә уңышлы булуы да ачык күренә.

Билгеле булганча, чит телләргә өйрәтү методикасында укучыларның тел белүләрен өч дәрәҗәгә бүлеп бәялиләр: 1) телне элементар белү дәрәҗәсе (*A*); 2) телне мөстәкыйль рәвештә куллана алу дәрәҗәсе (*B*); 3) телне ирекле рәвештә куллана алу дәрәҗәсе (*C*). Аларның һәрберсе, үз чиратында, тагын икегә бүленә, һәм барлыгы алты дәрәҗә күрсәтелә (*A1, A2; B1, B2; C1, C2*) . Әлеге концепция авторлары әйтүенчә, теге яки бу телне өйрәнүчеләрнең белем дәрәҗәләре халыкара стандартлар нигезендә тикшерелергә тиеш. Шулай эшләгәндә генә, төрле урыннарда, төрле дәреслекләр белән телне өйрәнүчеләрнең белем дәрәҗәләренә объектив бәя биреп була [1, Б .102].

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Бүгенге көндә татар теленә өйрәтү өлкәсендә фәнни-методик эзләнүләр һәм тикшеренүләр дәвам итә, укыту системасының уңышлы һәм җитешсез яклары даими күзәтелеп бара, яңадан-яңа уку-укыту ярдәмлекләре дөнья күрә, информацион-коммуникатив технологияләрне куллануга зур игътибар бирелә. Аларны гамәлгә кертү – заман таләбе. Шундый проектларның берсе – “АНА ТЕЛЕ” онлайн-мәктәбе. Моннан тыш, татар теле белән кызыксынучыларга тагын бер дистанцион курс тәкъдим итәргә мөмкин. Ул да булса, tatar.ile порталындагы татар теле курсы. Ул башлап өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә .

**Йомгаклау.** Һәр укытучы заманча алымнар куллануга, методик осталыгын һәм иҗади активлыгын арттыру, гамәли эшчәнлеген камилләштерүгә омтылса, моның белән беррәттән белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итсә, татар теленә өйрәтүнең сыйфатын яхшыртуга ирешеп булыр дип ышанабыз. Шулай эшләгәндә генә, һәрберебез татар телен саклап калу, аны үстерү һәм дөньяда таныту эшенә үз өлешен кертә алыр.

**Әдәбият исемлеге**

1. Общеевропейские компетенции владения иностранным языком: Изучение, обучение, оценка. – М.: МГЛУ, 2005. – 247 с.
2. Соловова Е.Н. Методика обучения иностранным языкам: Базовый курс лекций. – 2-е изд. – М.: Просвещение, 2003. – 239 с.
3. Тестирование в обучении русскому языку как иностранному: современное состояние и перспективы / По ред. Т.М. Балыхиной. – М.: МГУП, 2003. – 189 с.
4. Фәтхуллова К.С. Юсупова Ә.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н.Татарча сөйләшик . – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 311 б.
5. АНА ТЕЛЕ онлайн-мәктәбе// URL: http:// anatele.ef.com
6. «Татарский язык для всех» онлайн-курсы // URL: http://tatarile.org

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНУ

***Хәбибуллина И.С.***
*башлангыч сыйныф укытучысы*
*"Норма мәктәбе" филиалы*
*"Чапшар башлангыч мәктәп-балалар бакчасы"*
*Чапшар, Татарстан, Россия*

**Теманың актуальлеге.** Билгеле булганча, тормышның төрле өлкәләрендәге казанышлары мәктәп тормышына да үзгәрешләр кертә.Әзер белем биреп чыгару уку процессында төп бурыч булудан туктады, укытуны традицион формада оештыру актуальлеген югалтты. Заманча белем бирү системасы үзенең ориентирларын традицион модельдән үстерешле укыту системасына күчерә. Хәзер сүз белем бирү процессын компьютерлаштыру гына түгел, ә төрле педагогик, шул исәптән мәгълүмати технологияләр кертү турында бара. Шуңа да укытучылар алдында төп проблема булып белем бирү эчтәлеге һәм процессы сыйфатын үстерү тора. Ә бу исә үз чиратында укытучыларга яңа информацион технологияләрдән хәбәрдәр булуны, аларны гамәлдә нәтиҗәле куллана белүне зарур итә.Белем бирүнең нәтиҗәлеген күтәрү укыту процессының яңа, тагын да нәтижәлерәк технологияләрен эзләүне таләп итә. Укыту-тәрбия өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар, чаралар гамәлгә керә, таныш булган метод -алымнар үзгәреш кичерә, камилләшә.

Хәзер мәктәп, укыту һәм тәрбия системасы

бала шәхесендәге эшчәнлеккә кирәкле сыйфатлар булдыру мәсьәләсе белән тирәнтен шөгыльләнә. Укытучының педагогик осталыгының торган саен әһәмияте арта баруы шуның белән аңлатыла да инде. Моны хәл итү өчен, укытучыдан актив педагогик эзләнү, аның эш тәҗрибәсендә үстерешле укыту технологиясе принцибына нигезләнгән билгеле бер методик система булдыру таләп ителә. Бу системаның төп максаты – шәхес тәрбияләү, бәләкәйдән үк баланы шәхес итеп күрү, аның сәләтен күрә белү, аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү.

Яңача эшләргә омтылу – һичшиксез уңай күренеш. Максатка ирешү өчен, иң элек теге яки бу "яңа" системаның концепциясен һәм теориясен өйрәнү таләп ителә. Укытучы әлеге система турында махсус мәкаләләр, хезмәтләр белән танышырга, шул системада эшләүче укытучылар белән фикерләшергә, аларның эш тәҗрибәсен өйрәнергә тиеш. Заманча фикерләүгә омтылган укытучы гына укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп тәрбияли ала.

Бүгенге көндә педагогик технологияләр, мәгълүмати – коммуникатив технологияләр мөмкинлекләре еш кулланыла. Технология ул – ниндидер эштә, сәнгатьтә, осталыкта кулланылучы алымнар җыелмасы.

Соңгы елларда тормышның барлык өлкәләренә дә компьютер үтеп керде. Шул ук вакытта уку-укыту системасына да. Заман мәктәбенең тормышын да информацион технологияләрдән башка күз алдына китереп булмый.

Укучыларда уку процессына кызыксыну уяту өчен стандарт методлар белән генә чикләнергә ярамый. Укыту процессын информатизацияләү мәгариф өлкәсендә гаять зур мөмкинлекләр тудыра, чөнки аны белем бирүдә бик нәтиҗәле итеп кулланып була. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә компьютер технологияләрен максатка туры китереп кулланырга мөмкин. Укытуның бу төр яңа технологияләрен урынлы куллану укучыларның шәхси үзенчәлекләрен искә алырга, укытучы белән укучыларның бердәм эш алымнарын камилләштерергә, белем бирүнең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек тудыра. Компьютер сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала [3, Б 7].

Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Мәктәп баласы булган өйдә компьютер булмыйча калмый. Алай гына да түгел, хәзер кайбер балалар бакчасында да заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Шуңа да еш кына укучы бүген укытучыга караганда да күбрәк белә. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга – шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш.

Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы. Яңа төр эшчәнлек, компьютерда эшләү бәрабәренә укытуның сыйфатын күтәрүгә ирешү–компьютер технологиясенең иң өстенлекле ягы. Дәресләрдә компьютер куллану укучыларның актив һәм аңлап эшләвен тәэмин итүнең яңа алымы буларак дәресне тагын да күрсәтмәле итә.

Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстенлек алган була. Менә шушы вакытта нәкъ компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Презентацион программаларны төзегәндә, укытучы аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр кертә.

Мондый программа белән танышканда , укучы үзен кино караучы итеп хис итә. Чөнки ул аның алдында бер-бер артлы кадрлар булып чыга.

Презентацион материалларны класстан тыш уку дәресләрендә, әдәбият дәресләрендә язучының тормыш юлын, иҗатын өйрәнгәндә дә кулланырга мөмкин.Дәрес өчен презентацияләрне укучылардан ясату да белем сыйфатын күтәрүдә уңай нәтиҗә бирә.

Дәрестә компьютер технологияләрен кулланып мин укыту эшчәнлеген тагын да баетырга тырышам.Бу технологиялэр ярдәмендә шулай ук тест эшкәртүнең заманча системалары укыту процесын кызыклы, нәтиҗәле һәм ижади итеп оештырырга мөмкинлек бирүен истә тотып эшлим.Нәтижәдә балалар мәгълүмат ташкынында иркен аралашырга өйрәнә, мәгълүмат алу ысулларын үзләштерә, аларда алгоритмик һәм операцион фикерләү алымнарын булдырыла.

Белем бирүдә проектлар методын файдаланам.Бу метод балага шәхси якын килеп укытуда нәтиҗәле технологияләрдән санала.Проект төзү эшчәнлеге укучының акыл һәм рухи үсешен камилләштерергә ярдәм итә; анда максатчанлык, кызыксынучанлык, башлаган эшне ахырына җиткерү омтылышы тәрбияли.Ул мөстәкыйль фикерләүне үстерү, мәгълүмат таба белү, фаразлау, стандарт булмаган карарлар кабул итү осталыгына ия булуны күздә тота. Проеклаштыру ысулы төрле өлкәгә караган белемне интегральләштерергә һәм аларны, яңа идеяләргә баетып, тормышта кулланырга мөмкинлек бирә. Бу проект методикасы уку дәресләрен, сыйныфтан тыш уку дәресләрен оештыруда зур урын алып тора.Язучы, шагыйрь иҗатын, биографиясен өйрәнгәндә дә отышлы метод булып тора.Бала язучы турында тирән мәгълүмат туплый, аның язмышы белән кызыксына, өйрәнә һәм нәтиҗәдә башкаларга җиткерерлек белем туплый. Мәсәлән, Габдулла Тукайның «Туган авыл» шигырен өйрәнгән дәрескә укучы шагыйрьнең туган җирен, торган урынын, ни өчен шагыйрьнең бу шигыре туу турында проект эшләп, үзен кызыксындырган сорауларга җавап кына табып калмый, иптәшләре белән дә уртаклаша ала [ 1,Б 8 ].

Мультимедиа технологияләре электрон белешмәлекләр, энциклопедияләр, күләмле мәгълүмат чыганаклары белән эшләүгә юл ача. Бу технологияләрне дөрес файдалану дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, белем дөньясына җәлеп итә, татар теле һәм әдәбият фәннәре буенча өлгереш күрсәткечен һәм укыту сыйфатын яхшырта. Дәресләр өчен ясалган презентацияләр проблемалы ситуацияләр тудыру, белемнәрне актуальләштерү, яңа белемнәрне ачуда; зур экранда сурәтләнгән материал яңа дәресне тиз үзләштерергә ярдәм итә. Шулай ук алгоритмнар төзү, кагыйдәләр чыгару өстендә эшләгәндә, эталон буенча тикшерүләр уздырганда да бик уңайлы технологияләрдән санала.

Татар телендә хатасыз язу укучыга бик зур авырлык белән бирелә. Орфографик грамоталылыкны формалаштыру өчен орфографик хәтерне генә түгел, ә күрү һәм ишетүне дә үстерергә ныгытырга кирәк. Татар теленең орфографик кагыйдәсен ятлату гына көтелгән нәтиҗәне бирми. Дәрестә мультимедиа технологияләре бу кимчелек өстендә эшләргә зур мөмкинлек ачты. Бер орфограммага кагыйдә чыгару өчен күнегүләр өстендә эшләгәндә сыйныф тактасын ничә сөртеп, каплап торырга туры килер иде. Башка эш төрләре уздырганда да вакытны отарга, күбрәк белем алырга мөмкинлек бирә. Мисал өчен, күчереп язарга кирәк булган очракта, экранда түбәндәге алгоритм торса, бала хатаны җибәрми.

Ничек итеп хатасыз язарга:

1.Сүздә орфограмманы тап.

2. Хәрефләрне беләсеңме, юкмы билгелә

3. Беләм – яз Белмим – калдырып тор

4. Тикшер

- иҗекләп укы
- орфограмманы тап
- хатаңны төзәт

Укучыларның үзара ярдәмләшүен активлаштыруга юнәлтелгән эш формасы буларак эшчәнлекне төркемнәрдә оештыру уңай нәтиҗәләр бирә. Укучылар бер – берсе белән аралашып, бер – берсенең фикерен тыңлап, үз – үзләрендә үзүсешкә ирешә. Укучыларның үзлегеннән эзләнү эшчәнлеген стимуллаштыру нәтиҗәле гамәлгә ашырыла. Моңа башлангыч сыйныфта биремнәрне репродуктив төрдән иҗади төргә кадәр акрынлап катлауландыра бару, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен башка фәннәр белән фәнара бәйләнеш фрагментларыннан, милли төбәк компонентыннан нәтиҗәле файдалану юлы белән ирешелә.

Укучы белән актив диалог алып бару катнашучы өчен дә, тыңлаучылар өчен дә бер үк дәрәҗәдә файдалы. Балаларның коммуникатив эшчәнлеге активлаша: табигый сөйләм формалары кулланып сөйләшүдә катнашу, нидер сорау яки әңгәмәдәшеңә җавап бирү ихтыяҗы туа.

**Тикшерү ысуллары.** Мәкаләдә башлангыч сыйныф укучыларына татар телен укытканда кулланыла торган яңа мәгълүмат технологияләре турында сүз бара. Проблемалы укыту технологиясе куллану нәтиҗәсендә балаларның фикерләү сәләте камилләштерелә. Бу очракта белемнәрне үзләштерү диалог режимында проблемалы ситуацияләр тудыру ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

Шулай ук эшчәнлегемдә төрле дәрәҗәдәге укыту, дифференцияле якын килү, рольле, эшлекле уеннар, хезмәттәшлек, сәламәтлек саклау технологияләрен уңышлы гына кулланып киләм.

Мин үзем татар теле дәресләрендә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган технологияләрне кулланырга тырышам. Профессор Ә.Рәхимовның "Иҗади үсеш технологиясен" дәресләрдә куллану да уңай күренеш. Бу технология өч өлештән тора. Беренчесе – төшенчәнең эчтәлеген һәм аңа билгеләмә бирү буенча эш итү ысулын гомимиләштерү, икенчесе – укучылар эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, өченчесе модельләштерү.

Модельләр, схемалар белән эш итәргә даими өйрәткәндә, фәнни сөйләм кыскара, автоматлаша һәм фикергә әверелә. Шул рәвешле, тыштан материальләшкән чара укучыларның фикерләү чарасы булып хезмәт итә башлый.

Модельләштерү дәреснең аерым бер этабы буларак кертелә. Модель төзү – иҗади эш. Аның аша укучылар төшенчәнең үзенчәлекле билгеләрен һәм эчке бәйләнешләрен ачалар. Шул нигездә, ул белем алуга кызыксыну уяту чарасы да булып тора.

Модельләштерү дәрестә төшенчә өстендә эш белән нык бәйләнгән. Төшенчә формалаштыру – дәреснең мөһим этабы. Чөнки төшенчә -логик фикер йөртүнең төп формасы булу белән бергә укучыларда фәнни белемнәр булдыруның төп чарасы да. Төшенчә формалаштыру дигәндә, аның эченә кергән мөһим билгеләр җыелмасын табу һәм төшенчәгә кергән предметларның күләмен ачу күз алдында тотыла. Мәсәлән, мин "Сүз ясагыч кушымчалар" темасын өйрәнгәндә, модель төзү һәм төшенчәгә билгеләмә бирүне түбәндәгечә башкарам:

1нче бирем. Ясалма сүзләрнең моделен төзергә (төркемләп һәм тактада эшләү).

2нче бирем. Модельгә таянып, ясалма сүзләр билгеләмәсен чыгарырга һәм бер-береңә, үз-үзеңә әйтергә.

3нче бирем. Укучылар төзегән билгеләмәнең дөреслеген дәреслектә бирелгән билгеләмә белән чагыштыру, тулыландыру. Нәтиҗә чыгару.

Күргәнебезчә, билгеләмәнең тулылыгын анализлаганда, модель укучыларга күзәтү материалы аша табылган барлык мөһим билгеләрнең кереп бетү- бетмәвен ачыкларга нык ярдәм итә. Аннан соң, дәреслек белән чагыштырып, билгеләмә камилләштерелә һәм модельгә дә өстәмәләр кертелә.

**Тикшерү нәтиҗәләре.** Иҗади фикерли белү исә – иң кыйммәт бәяләнүче сыйфат.

“Иҗадилык – үз шәхесеңне, фикерләвеңне, аң һәм интеллектыңны даими камилләштерү. Иҗади эшчәнлектә кеше үсә, махсус тәҗрибә туплый, үзенең табигый сәләтен һәм мөмкинлеген ача, ихтыяҗын канәгатьләндерә. Шул рәвешчә, иҗадилык кеше тормышын алга илтүче төп көчкә әверелә”, – ди “Иҗат психологиясе” дигән китабында Әхмәт Зәки улы Рәхимов. Балада мондый үсешне аны шәхес итеп караганда гына күреп була. Яңача укыту технологиясенең нигезендә нәкъ шул – укучы һәм укытучы арасында яңача мөнәсәбәт тора. Укытучы укучыны үзе белән тигез шәхес итеп карарга тиеш. Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә шатлык – бәхет алып килергә, дәрестән бала ниндидер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Моны бары тик яңача фикерләүгә омтылган укытучы гына булдыра ала. Ул укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп кабул итә ала [2, Б12].

**Йомгаклау.**Татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Өстәп шуны әйтер идем: әгәр дә укытучы дәрестә күрсәтмәлекне житәрлек дәрәҗәдә кулланса, төрле уен ситуацияләре, сөйләм күнегүләре,инновацион технология элементларыннан дөрес файдалана белсә, ул, һичшиксез, эшендә уңышка ирешәчәк. Бары тик бер урында таптанып торырга гына кирәкми.

**Әдәбият исемлеге**

1. Искәндәрова С.И. Инновации в преподавании татарского языка и литературы [электронный ресурс] Режим доступа^www// proshko.ru/user/sufia 116/ blog/ 458

2. Нәзирова Ф.В. Сыйфатлы белем һәм тәрбия бирүдә укытучы эшчәнлеге: кулланма. – Казан, 2010 – 12 б.

3. Сәгъдиева Т.И. Башлангыч мәктәптә инновацион эшчәнлек // Сыйфатлы белем бирүдә информацион технологияләр куллану. – К , 2010 – 7 б

# ENTRE MONDIALISATION ET SAVEUR NATIONALE: LE LANGAGE DU TOURISME CONTEMPORAIN

***Kuzmina E.K.***
***Golubeva M.A.***
*PhD, Professeur assistant*
*Université d'innovation de Kazan*
*nommée d'après V.G. Timiryasov*
*Kazan, Russie*

Le discours touristique, en tant que domaine particulier de la communication, vise à attirer, informer et former une image positive des clients potentiels. Dans le contexte de la mondialisation et de l'internationalisation du Tourisme, la langue de ce domaine est activement complétée par des emprunts en langue étrangère, principalement de l'anglais comme langue de communication internationale. La pertinence de ce sujet est due à la nécessité d'étudier les mécanismes et les fonctions pragmatiques que les emprunts exercent dans une communication efficace avec un public multiculturel.

À l'heure actuelle, la communication touristique est devenue un système Linguistique en plein développement, combinant des éléments d'activité publicitaire, de communication internationale et de relations de marché. La tâche principale d'un tel discours n'est pas simplement de transmettre des informations, mais de créer une réponse émotionnelle chez le public et de former une image attrayante des produits et des destinations touristiques.

À l'ère de la mondialisation de l'industrie touristique, il y a une introduction active de mots étrangers, principalement anglophones. Cette tendance a deux aspects: d'une part, elle témoigne d'un processus d'intégration dans la communauté mondiale, d'autre part, elle peut conduire à un encrassement excessif de la langue et à une diminution de sa compréhension pour les locuteurs.

Les normes internationales en matière d'hospitalité et de Tourisme établies par les principaux acteurs du marché (chaînes hôtelières comme Marriott et Hilton, systèmes de réservation Pegasus et Amadeus, compagnies aériennes) exigent l'utilisation d'une terminologie unifiée. Des termes tels que «check-in», «booking», «All inclusive» et «no-show» sont devenus des concepts professionnels généralement acceptés, compréhensibles par les spécialistes de tous les pays du monde. Cette harmonisation contribue à normaliser les processus, à améliorer les interactions entre les acteurs du marché et à faciliter la communication avec les clients.

Le développement rapide des technologies numériques change radicalement le visage de l'industrie du voyage et forme un nouveau vocabulaire professionnel. De nombreux termes technologiques viennent directement de l'anglais, car il n'y a pas d'équivalents bien établis.

Des concepts tels que «e-ticket» (billet électronique), «mobile app» (application mobile), «online booking» (réservation en ligne), «blockchain» (blockchain) et «smart destination» (destination de voyage intelligente) font déjà

partie intégrante du vocabulaire professionnel et reflètent les changements fondamentaux dans l'industrie.

Les termes empruntés dans le domaine du Tourisme peuvent être systématisés selon différents critères, ce qui permet de mieux comprendre les mécanismes de leur intégration dans le langage professionnel.

Il est important de souligner que les termes internationaux («hôtel», «transfert», «guide») sont souvent utilisés dans les documents touristiques et les communications destinées aux visiteurs étrangers. Cela facilite grandement la compréhension de l'information pour les invités de différents pays.

Les emprunts sont souvent plus concis et permettent de transmettre plus précisément les nuances de la signification des concepts existants, ce qui est particulièrement important dans la communication professionnelle.

L'engouement injustifié pour les termes étrangers dans le domaine du Tourisme conduit à de graves problèmes de communication:

- Difficultés de perception de l'information parmi certaines populations. Les personnes âgées ou celles qui ne parlent pas anglais peuvent avoir du mal à comprendre.
- Contradictions stylistiques dans la Description des itinéraires culturels et historiques.
- Excès dans le vocabulaire, lorsque des mots étrangers sont utilisés à la place des analogues existants.

Il ne faut pas une lutte totale, mais une optimisation raisonnable de l'utilisation des emprunts. Il est important de trouver un équilibre entre la norme internationale et la saveur nationale.

Le phénomène de l'emprunt dans le discours touristique est un phénomène complexe lié aux processus de mondialisation, de développement technologique et de stratégies de marketing. L'abandon complet des termes étrangers dans l'industrie touristique moderne n'est pas pratique, car ils remplissent d'importantes fonctions de communication.

La tâche principale n'est pas d'interdire les emprunts, mais de les réglementer correctement:

